КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мәдәни җомга

№3 (130)
16 гыйнвар
1998 ел

...ының июленнән
...башлап чыга

Атналык гәзит

بسم الله الرحمن الرحيم

Бүгенге санда:

2 **Рафис ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН.** Безнең базар үзенчә: анда барысы да чит илләрдән китерелгән, кайсыдыр илнең икътисадын яхшыртуга, шул илне баетуга корылган.

6 **Гаял МОРТАЗИН.** Русия пасуз территориясендә Русия паспортларыннан баш тарткан республикаларның паспортлары йөрүен тыя алмый, чөнки "федерация" дип аталган дәүләтнең җимерелүе бар.

8 **Фәүзия БӘЙРӘМОВА.** Күңелдә һаман кара урманнар шаулый, татар милләтчесе һаман ирек даулый, гавам дәверләр капкасы каршында басып тора...

14 **Әбрар КӘРИМУЛЛИН.** Халкыбызның дөрес тарихын торгызу, аны дөньякүләм таныту иң мөкатдәс бурычыбыз бит.



Дөнья матур, дөнья шундый гади,
Янәшәңдә булса әти-әни!..

Мөхәррир мөнбәре

Беркөнне телевизордан хәбәр иттеләр: искиткеч тырыш, эшлекле халык яшәгән Көньяк Корея дә, ни гаҗәп, чит ил банкларына муеннан бурычка баткан икән. Өстәвенә, әлеге бурычтан хөкүмәт үзе генә котылырлык хәлдә дә түгел, ди. Әмма илнең дөнья алдындагы элеккеге абруен саклап калыр өчен ниләр генә уйлап чыгармый бу Будда токымнары?! Аңа ышанмаслык хәл ич: мәмләкәтнең хәлләрен халкы, тота да, алтын-көмеш әйберләрен казнага тапшырыр өчен, банкларга килеп чиратка баса. Ә бит заманында әлеге илнең президентын, бурычта гаепләп, хөкемгә дә тарткан иде. Ләкин халык барыбер дә дәүләт җитәкчеләренең намуслы булуына иман тота, аларга ышана, күрәсең. Без генә ул угрылык — егетлеккә, ә намуслы яшәү булдыксызлыкка саналган илдә җан асрап яткан булабыз...

Газинур МОРАТ

Мин әйттем

Рафис ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН

КАРГЫШ

Поляк язучысы, мөгаллим, бөек гуманист Януш Корчакның шундыйрак сүзләре бар: илнең байлыгы ул урнашкан мәйдандагы урман-сулар, файдалы казылмалар гына түгел, аның төп байлыгы – балалар.

Шушы хакыйкатькә җаны-тәне белән инанган Януш Корчак үзенең "Урман балалары", "Балаларны ничек яратырга" исемле әсәрләрендә дә, тормышта да шуңа тугрылыклы булып калган – гитлерчы-фашистлар тоткынлыгында да балаларның бәхетле киләчәге өчен көрәшкән һәм үзе тәрбияләгән 200 бала белән бергә җәзалап үтерелгән үлемсез каһарман ул.

СССР дип аталган илдә дә, бүленмәс Русия дип аталган хәзерге мәмләкәттә дә без әле дә төп байлыгыбыз дип шул ук очсыз-кырыйсыз урман, диңгезләрне, җир асты казылмалары булган алтын-көмешне, нефть-газны атыйбыз. Кичә генә коммунист булган, төн чыкканчы йон чыккан дигәндәй, бүген инде демократка әйләнгән түрәләр хакимлек иткән бу илдә әле дә булса балалар игътибардан читтә кала килә. Ә теге байлыкларыбыз түрәләр, аларның яраннары тарафыннан сатыла, чит илләргә озатыла тора. Ә ил хуҗалары аннан килгән майлы калҗадан күбрәк эләктереп калыйм дип, үзара тарткалаша, сугыша. Аларда балалар кайгысымы соң?!

Дөрес, элегрәк: "Иң яхшысы – балаларга!" – дигән ялтыравыклы шигырь бар иде. Һәм, ни генә әйтмәсеннәр, ул күпмедер дәрәҗәдә тормышка да ашырыла торган иде. Җәйләрен балаларыбызны ял итәргә дип бушлай пионер лагерьларына, санаторийларга озатырга мөмкин иде. Бөтен җирдә үк булмаса да, мәктәпләрдә бушлай туклану да оештырыла торган иде. Ә хәзер балаларыбыз акча түләп "Лаеш шулпасы"н чөмерә. Итемае исә мәктәп юлында югала тора...

Әйе, бүгенге балалар турында уйласаң, чәчләрең үрә тора. Язмыш иркенә ташланган балалар саны көннән-көн арта бара. Статистика мәгълүматларына караганда, өен, әтисен-әнисен ташлап качкан балалар бүгенге көндә Русиядә 3 миллионнан артып китә икән. Шулайдыр, үзебезнең радио-телевидение тапшыруларында да, матубгат битләрендә басылган язмаларда да бу хакта еш күрсәтелә, еш сөйләнә. Җәйләрен сукбай балаларның чардакларда качып-посып яшәүләре, көннәр салкынайткач, подвалларга төшеп, тычкан-күселәр арасында йоклап ятулары һәммәбезгә дә мәгълүм бит. Казан һәм башка шәһәрләребез урамнарында хәер сорашып йөрүче малайларны-кызларны күрү дә гадәти күренешкә әверелеп китте. Балигъ булмаган кыз балаларның фахишәлек белән шөгыльләнүләре дә яңалык түгел.

Үзгәртеп корабыз, демократик дәүләт төзибез, дип дәртләнеп башланган изге гамәл ни өчен безгә гел-гел яман якларын гына күрсәтә тора? Моның асылында ил җитәкчелегенең, гәрчә, алар халык тарафыннан сайланып куелды дип саналсалар да, аларга хезмәт итәсе урында тәхет өчен астыртын, кайчак ачыктан-ачык бугазга-бугаз килеп чәкәләшеп ятулары, укыту-тәрбия эшенең үзагымына куелуы ята. Ягъни, элегрәк яшәп килгән "Иң яхшысы – балаларга!" дигән мәгълүм шигарьнең асылы "Иң яхшысы – түрәләргә!" дип үзгәрүендә. Моның шулай икәнен хәбәрдар укучым меӊ дә бер төрле мисаллар аша белә, үз җилкәсендә татый.

Балалар, дибез. Аларның язмышы әти-әниләренә, укытучыларына бәйле.

Базар шартларына күчәбез дип башлаган эш аклы-каралы яклары белән безнең тормышка үтеп керә бара. Әйе, без базар шартларында яшибез. Мәгълүм хакыйкать: базарда кемдер ота, кемдер оттыра. Шунсыз мөмкин дә түгел, чөнки базар базар инде ул. Тик безнең базар гына кешенекенә охшамаган, үзгә, нәкъ үзебезчә. Анда барысы да чит илләрдән китерелгән, кайсыдыр илнең икътисадын яхшыртуга, шул илне баетуга корылган. Чөнки моңа кадәр гөрләп эшләгән, халык хуҗалыгы тауарлары чыгарган завод-фабрикаларның күбесе ябылды, анда эшләүчеләр урамга куып чыгарылды. Балаларын туендыручы, киендерүче әти-әниләр кирәксез мәхлукларга әверелде. Шуңа да балаларын туендыра, киендерә алмаучы әти-әниләре яныннан – туган йорт-нигезләрен ташлап чыгып китүче, хәер сорашучы, җинаять кылучы балаларның көннән-көн арта баруы табигый хәл.

Балалар язмышы мәктәпләргә-укытучыларга да бәйле, дигән идек. Бүгенге мәктәпләребезгә кереп караучылар белә булыр: хәзер укытучылар белән укучылар арасындагы мөнәсәбәт эт белән мәченекен хәтерләтә. Айлар дәвамында хезмәт хакы ала алмый җәфаланган мөгаллим-мөгаллимәләрнең йөзләре кара янган. Ач кешенең ачуы яман, дигәндәй, аларның бирешесе балаларга тәрбия, белем бирәсе урында акыру-кычкыру, сүгенү, юлында очраган баланың якасыннан тотып стенага кысу белән шөгыльләнә. Ямаулы күлмәк-ыштан кигән, яңак сөякләре тырпаеп чыккан бала исә дәресен ташлап качу ягын карый. Калганнары исә дәрес тыңлау урынына кесәсенә тыгып килгән презервативын шар урынына кабартып югары чөя. Парта астыннан кулын сузып янәшәсендә утыручының итәк астын каезлый. Йә булмаса дәрестән чыгып тәмәке пыскытып керә. Боларына да һич гаҗәпләнәсе юк, чөнки телевидение тапшырулары көне-төне чит илләрнең шундый эчтәлектәге арзанлы тасмаларын әйләндерә. Гәзит-журналларда секс пропагандалана.

Инде сүз бу эшкә өйрәтүне рәсми рәвештә мәктәпләрдә алып баруны кертүгә кадәр килеп җитте. Аннан соң "ачык дәрес"ләр үткәрүгә дә ерак калмаячак...

Янә статистика мәгълүматларына әйләнеп кайтыйк әле. Җиң сызганып эшлисе урында чит илләрне, чит җирләрне яулап алу, сугышу, ягъни кеше җитештергәнне талап үз корсагына тутыру белән генә шөгыльләнгән Русия дәүләте үзенең әхлакый, икътисади үсеше ягыннан алга киткән илләрдән 20-25 елга артта сөйрәлә.

Үз халкын эш белән тәэмин итәсе урында завод-фабрикаларына, үз белгечләрен тибәреп, чит ил "белгечләре"н китереп тутырган "хокукый дәүләт" бүгенге хәленнән чыгарга теләп читлектәге ерткыч кебек чәбәләнә. Ары бәрелә, бире сугыла. Моңа кадәр эшләгән җитәкчеләрнең булдыксызлыгын хурлап-яманлап берара абруй казанган бүгенге партократ-демократлар үзләренең халык алдында кылган ахмаклыкларын яшереп калырга омтылып, инде акны карадан азмыкүпме аера башлаган халыкны тынычландырмакчы булып көн саен вәгъдәләр бирә, юмалый, үгетли, өметләндерә...

Әмма инде буш вәгъдәләргә ышанмый башлаган, өметсезлеккә бирелгән халык бу билгесез мәхшәрдән чыгуның башка юлларын эзли. Ачлы-туклы яшәүче, акчасыз гаиләләр җимерелә, балалар туу елдан-ел кими. Стресс хәлендә яшәүче ачлы-туклы, торыр җире булмаган гаиләләрдә туган балаларның күбесе психик яктан авыру, гарип.

Әйе, гарип, инвалид балалар саны ягыннан Русия беренчелекне беркемгә дә бирми. Моның белән ул чын-чынлап мактана, горурлана ала.

Әлеге дә баягы статистика мәгълүматларына караганда, бездә барлыгы 20 миллионга якын инвалид исәпләнә. Боларны Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Чехословакиядә, Венгрия, Әфганстан, Чичәнстанда һәм тагын әллә кайларда үзләренең "интернациональ бурыч"ларын үтәүчеләр, элеккеге совет армиясендә, бүгенге Русия армиясендә хезмәт итүчеләр, Чернобыль, Чиләбе, Арзамас һәм тагын без белмәгән әллә нинди "ябык" шәһәрләрдә шартлаган хәрби заводларда, атом электр станцияләрендә эшләүчеләр тәшкил итә. Арада илнең төп байлыгы булып саналырга тиешле исәпсез-сансыз бер гөнаһсыз сабыйлар, балалар да бар.

Башкалабыз Казанның үзендә генә дә 16 яшькә кадәрле гарип балаларның саны 3742гә җитә. Аларга ярдәм итүдән, булышудан, кызганыч, һәрвакыттагыча, акча юклыкны сылтау итеп, хөкүмәт читтә калырга тырыша. Нигездә, бу эш белән җәмәгать башлангычында оешкан "Таяныч", "Ярдәмче", "Ярдәм", "Шәфкать" һ.б. шундый оешмалар шөгыльләнә. Нигә әле болай каты бәреләсең, диярләр бәгъзеләр. Җөмһүриятебездә ел саен инвалидлар ункөнлекләре үткәрелә, бу декада вакытында аларга һәртөрле ярдәм күрсәтелә, бүләкләр өләшенә, диярләр. Сүз дә юк, хак сүзләр. Русия Федерациясенең 1998-2000 елларга караган "Инвалид балалар", "Чернобыль балалары" дип аталган программасы кабул ителүе дә хуплауга лаек. Анда нинди генә чаралар билгеләнмәгән дә, ниләр генә вәгъдә ителмәгән. Кызганыч, эшләр хәзергечә барса, аларның үтәләчәгенә генә ышаныч юк. Төп байлыгыбыз булган балалар язмышы әлегә Алла кулында.

Иле нинди – халкы шундый, диләр... Хак сүзләр. Бездә, моңа кадәр күрелмәгән эчкечелек, наркомания, фахишәлек чәчәк аткан илдә, ташландык, гарип, ятим балалар саны котточкыч тизлек белән арта бара. Яңа интернат-мәктәпләр ачыла. Аларның күбесендә яшәү, уку өчен гап-гади шартлар да юк. Еракка барырга да кирәкми, Казанның Киров районында урнашкан 3 нче интернат-мәктәптә хәтта радио белән телевизор да юк. Балалар кысан, салкын бүлмәләрдә тереклек итәләр. Шушындый ук хәл Казанның Дәрвишләр бистәсендә урнашкан ятим балалар йортына да хас. Хәер, саный китсәңме...

Соңгы вакытларда Америкадан һәм башка чит илләрдән килгән калын кесәле ханым, әфәнделәрнең Дәрвишләр бистәсендә урнашкан ятим балалар йортыннан, Казанның 1 нче, 2 нче балалар йортыннан, Чаллы, Яшел Үзән, Лаеш балалар йортларыннан интегеп, җәфаланып яшәп ятучы балаларны үзләренә тәрбиягә алып китүләре хакында хәбәрләр булды. Телевидение тапшыруларының берсендә хәтта ул балаларның анда ничек яшәп ятуларын да күрсәттеләр. Сүз дә юк: муп, тук тормышта яшиләр. Бу тапшыруны карагач, интернатларда, балалар йортларында тәрбияләнүче сабыйлар гына түгел, әти-әниләре янында ачлы-туклы, ялангач яшәүче балалар да көнләшкәндер һәм күбесе: "Их! Безне дә бу каргышлы илдән шунда алып китсәләр иде!" – дип хыяллангандыр, өметләнгәндер. Ә минем байлыгыбыз саналган нефть-газ, алтын-көмешләрнең генә түгел, Януш Корчак әйткәнчә, төп байлыгыбыз булырга тиешле балаларның да чит илләргә таралуына җан әрнеп, йөрәк сыкрап куйды. Тик нишләмәк кирәк?! Иле нинди – халкы шундый, диләр бит...

ВАКЫЙГАЛАР ХӘБӘРЛӘР ЯҢАЛЫКЛАР

Җидегән 5 6 7 1 2 3 4

Яңа елны яңачамы?!

Юк, яңача түгел. Әлеге дә баягы, Ислам бабай таягы дигәндәй, без аны Дед Морозлар, Снегурочкалар белән каршыладык. Теге замандагыча, урысчалатып. Урамнардагы Чыршы бәйрәмнәре дә, театр, мәдәният йортларындагы бәйрәмнәр дә "олы туган"ыбыз телендә узды. Мәсәлән, данлыклы М.Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет академия театрындагы бәйрәмнәр дә, тамашалар да урысча барды, балалар әйлән-бәйләндә "В лесу родилась елочка"ны җырлаганнан соң "Щелкунчик"ны карадылар һәм аннан тиз арып, байтагы көйсезләнеп кайтып киттеләр. Цирк бинасындагы Яңа ел тантанасында да Мәскәү артистларыннан торган Дед Морозлар әвәрә килде. Шул 12 көнлек каникулларда татар тамашасы оештырып булмый идеме?

Милләтебезнең киләчәген формалаштыруга хезмәт итүче Казан курчак театры да сирәк-мирәк кенә татар әсәрләре куя. Ә күбрәк тамаша урыс телендә бара. Дөрес, ниһаять, татар яшьләр театры бу эшкә җиң сызганып алынды. Аларның яңа елга "Мисс, убырлы!" әсәре сәхнәгә куелды. К.Тинчурин театрында да балалар өчен "Мыгыр-мыгыр мыгырдык" дигән әсәр әзерләделәр. Әмма Яңа ел кичәләре, Чыршы бәйрәмнәре Казан, Татарстан буйлап үтте ич!

Казанда сценарий язарга татар әдипләре юк дисәң, аларның саны да ике йөздән артып китә. Режиссерларга да кытлык кичермибез бугай. Чөнки Казанда мәдәният, сәнгать академиясе ел саен режиссерлар әзерләп чыгарып тора.

Эш нәрсәдә соң?

Узган ел үзебезнең чын, ихлас, милли бәйрәмебезне үткәрү – Җөмһүрият көне – конгресс көннәренә туры килде. Шушы олы бәйрәмебезнең сценариен кем әзерләде дип уйлыйсыз. Мәскәүдән килгән, татар дөньясына һичнинди катнашы булмаган кеше – режиссер эшләде. Әстәгъфирулла. Нигә без үз кешеләребезгә ышанмыйбыз һәм ни өчен үз мөмкинлекләребездән тиешенчә файдаланмыйбыз? Мәскәүләр төкереп бирә синең милли тойгыхисләреңә, аларга каерып алырга акча гына булсын.

Башкалабыздагы Яңа ел бәйрәме дә Мәскәү режиссерлары эшен хәтерләтте.

Сәрмәдия СӨЛӘЙМАН.

"Татарстан"да яңа мөхәррир

"Татарстан" журналы редакциясе коллективы баш мөхиррир Рафаэль Мостафинны хөрмәтләп ялга озатты. Журналның җитәкчесе итеп моңа кадәр "Мәгърифәт" гәзите баш мөхәррире булган Рифат Фәттахов билгеләнде.

Коръән уку бәйгесе

Казанның Нурулла мәчетендә мәдрәсә шәкертләре арасында Коръән сүрәләрен уку бәйгесе уздырылды. Егетләр арасында М.Әхмәдуллин, И.Имамиев, В.Гариев җиңүче дип табылды. Асия, Салиха, Мәрьям Яруллиналар исә Изге Китапны иң сәнгатьле укучы кызлар булды.

Экранда – базар кешеләре

Казанлы Сергей Архипов үзенең геройларын Мәскәү районы базарларында таба һәм төшергән фильмын РТВ каналында күрсәтелә торган "Сам себе – режиссер" тапшыруына тәкъдим итә. Аның максаты – беренче бүләкне алу.

Болак үзгәртеп корыла

Белгечләр, экологлар, проектлаучылар Болак тарихын тирәнтен өйрәнеп, башкалабызның элеккеге гүзәл каналын үзгәртеп корырга дигән карарга килделәр һәм инде эшләр башланып та китте. Ул пычрактан, ләмнән чистартылып, икенче биеклеге яшел чирәм белән капланачак. Киләчәктә Болак сулы булыр һәм анда кечкенә көймә станциясе эшләр дип уйланыла.

"Рамазан" бәйрәме

Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбле 2 февраль көнне Г.Камал исемендәге театр бинасында "Рамазан" дип аталган концерт-тамаша күрсәтә.

Үзешчән сәнгать турында кайгырту

Казанда 26 гыйнврдан 1 февральгә кадәр татар үзешчән сәнгатен үстерүгә багышланган XYI төбәкара семинар узачак. Анда Русия төбәкләреннән, күрше Башкортстаннан мәдәният хезмәткәрләре килү көтелә.

Чистай курантлары

Чистай сәгать заводы узган ел ахырында башнялар өчен курантлы сәгатьләр ясауга керешә. Ихтыяҗ да зурдан икән. Мәсәлән, Тольяттидагы АвтоВАЗ 100 данә сәгатькә заказ биргән.

Гыйнварда магнитлы көннәр

16 гыйнвар (8-10 сәг.), 19 гыйнвар (9-11), 21 гыйнвар (19-21), 26 гыйнвар (22-24), 29 гыйнвар (7-9 сәг.).

Объявление

Городской клуб ветеранов в городе Казани ликвидирует спортивную школу "ВАДО".

Тел.: 36-12-87.

Әйткән сүз – аткан ук

Миңнур РӘХИМОВА, пенсионер (Казан):

"Шәһәр башлыгының бернинди законга да нигезләнмәгән карары буенча ваклап сатуда халыктан 8 көн дәвамында (!) салым тотып калынды. Мондый баштаклык инде болай да акчасызлыктан интеккән кешеләребезне көпә-көндез кычкыртып талау, дәүләт күләмендәге рэкет түгелме? Туган башкалабызда яшәүчеләрне ничек шулай оятсызларча мыскыл итәргә мөмкин? Әллә кайбер җитәкчеләребез мәктәп баласы кадәр дә уйлый белмиләрме? Бездә вак-төяк кесә каракларына җәза бирәләр, ә миллионнан артык кеше яшәгән шәһәрне талаучыларга... Кыскасы, алдын-артын уйламыйча эшләнгән мондый акылсыз гамәлләр югары җитәкчеләребезгә булган халык хөрмәтен какшатуга китерә".

Хезмәтенә күрә хөрмәте

Озак еллар нәтиҗәле фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнгән, югары квалификацияле медицина кадрлары әзерләүдәге һәм халык сәламәтлеген саклаудагы уңышлары өчен Казан дәүләт медицина академиясе кафедрасы мөдире, укыту эшләре буенча проректор **НИЗАМОВ Илдус Галирзин улы Татарстан Республикасының Мактау грамотасы** белән бүләкләнде.

***

Мәдәният өлкәсендәге уңышлары өчен Казан дәүләт университетының геология-минералогия музее директоры **ФОМИЧЕВА Надежда Леонидовнага "Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре"** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Дәүләт хакимияте һәм идарә органнарында озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен Татарстан Президенты каршындагы дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты җитәкчесе урынбасары **ГАНЧУРИН Валентин Павлович Татарстан Республикасының Мактау грамотасы** белән бүләкләнде.

Татарстан Президенты Указы нигезендә Русия Фәннәр академиясенең Казан биология институты лабораториясе мөдире **ҖӘЛАЛОВ Габдуллаҗан Абдулкадыйр улы**на; Казан дәүләт университетының тарих кафедрасы мөдире **ШӘРИФҖАНОВ Измаил Ибраһим улы**на **"Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе"** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татар мәдәнияте өлкәсендәге уңышлары өчен Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе режиссеры **ХӘМЗИН Алмаз Наил улы**на **"Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре"** дигән мактаулы исем бирелде.

Җомгадан – җомгага

ҖӨМҺҮРИЯТ ЕЛЪЯЗМАСЫНА ҖӨМЛӘЛӘР

Татарстан Президенты М.Шәймиев яңа ел башыннан Казанда ашыгычлык белән 3-5 процентка бәяләр күтәрүне "Ваклап сатудан салым алуны тәртипкә салу чаралары турында"гы Указы белән ваклап сатуга салым салу буенча тиешле норматив хокук актлары эшләнгәнче һәм кабул ителгәнче Татарстан Республикасы территориясендә туктатты.

Татар халкының күренекле галиме һәм мәгърифәтчесе Ш.Мәрҗанинең тууына 180 ел тулу уңаеннан Татарстан Фәннәр академиясе һәм Тарих институты 26-27 гыйнварда "Ш.Мәрҗани мирасы һәм хәзерге заман" дигән темага халыкара конференция уздыра.

Татарстан Президенты М.Шәймиев республиканың Бөгелмә, Баулы, Чаллы районнарында булып, күп кенә тантаналарда катнашты.

Татарстан Профсоюзлар федерациясе рәисе Ф.Гайнуллинаның "Парламентская и непарламентская деятельность профсоюзов РТ" дигән монографиясе басылып чыкты.

Композитор И.Мәҗитовның 28 җыры тупланган ике альбомы дөнья күрде.

М.Горький музеенда язучы М.Скороходовка багышлганган күргәзмә эшли.

Танылган шахматчы, шушы көннәрдә генә Һолландиядән дөнья беренчелеген дәгъвалаучылар бәйгесендә җиңеп кайткан Алисә Галләмова республиканың Физкультура, спорт һәм туризм дәүләт комитетында матбугат конференциясе уздырды.

Күренекле дирижер, профессор, Тукай исемендәге бүләк иясе, Русиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Казакъстанның һәм Татарстанның халык артисты Ф.Мансуровка 70 яшь тулды.

Сәхифәбездә редакциябез журналистлары, авторларыбыз, "Татар-информ" һәм башка чыганаклар хәбәрләре файдаланылды.

Беренче биттә – **Н.ТУГАНОВ** фотосы.

"Мәдәни җомга" вәгъдәсендә тора

Хөрмәтле укучыларыбыз! Хәтерегездәдер: 1998 елның беренче ярты еллыгына "Мәдәни җомга" гәзитенә язылучыларга без Исламият галиме Шәйх Вәхид Габдессәлимнең "Җен вә шайтаннан саклану догалары" исемле китабын бушлай җибәрергә вәгъдә биргән идек. Вәгъдә – иман, дип искәрткән элгәреләребез. Гәзитебезнең быелгы 3 нче саны белән бергә Сезгә ниятләнгән шушы бүләгебезне һәм, өстәп, стенага ябыштырыла торган календарь да юллыйбыз. Редакциябезнең китаплар чыгаручы иҗат төркеме киләчәктә сезнең игътибарга Ислам кануннарына һәм әхлагына кагылышлы башка кызыклы басмалар да тәкъдим итәргә уйлый.

Сезгә үтенечебез дә бар: "Мәдәни җомга"га язылырга өлгермәгән туганнарыгызга, күршеләрегезгә, танышларыгызга әйтсәгез икән: әгәр 14 февральгә кадәр почта бүлекләренә барып рәсмиләштерсәләр, аларга гәзитебез 1 марттан килә башлар. Дүрт айга язылу бәясе – нибары 18 сум.

Күзгә-күз карап

Җир ышанычлы кулларга бирелер

Президент Минтимер ШӘЙМИЕВнең телевидение журналистлары сорауларына җаваплары

– Минтимер Шәрипович! Сез узган елның 26 декабрендә Мәскәүдә уздырылган түгәрәк өстәл эшендә катнаштыгыз. Җир мәсьәләсен хәл итүдә уртак фикергә килү өчен нинди шартлар үтәлергә тиеш дип уйлыйсыз?

– Иң беренче Русия Дәүләт Думасында Җир кодексы проектын практик кулланырлык итеп үзгәртү кирәк. Хәзерге хәлендә ул гамәлгә кертелә алмый, чөнки Русия Федерациясе Конституциясенә, аның Гражданлык кодексына каршы килә. Проектның иң зур кимчелеге – анда җир сату һәм сатып алу тәртибе каралмауда. Шуңа күрә Борис Ельцин аны үз вакытында кире какты да инде.

Аннары кодекс проектында җирне мираска бирү яисә бүләк итү, күчеп китә калганда, кешегә үз җирен сатып китү, яңа урында җир сатып алу хокукын тыю да дөрес түгел. Кодекс җир астында инженерлык яисә башка коммуникацияләр үтә торган участокларны сатуны да тыя. Димәк, шәһәрләр һәм промышленность районнарындагы җирләр беркайчан да шәхси милек була алмый дигән сүз. Бу исә икътисадка турыдан-туры аяк чала.

Икътисади реформалар әйбәтрәк барсын өчен, җир җәмгыятькә "эшләсен", файда китерсен өчен хәзер компромисс табу зарур. Минемчә, Русия Федерациясе субъектлары һәркайсы, урындагы шартлардан һәм мәнфәгатьләрдән чыгып, үзләренең җир кодексын яисә законын кабул итсен. Бер үк вакытта шулар нигезендә тулаем гомумрусия кодексы да эшләнсен иде.

– Элек күмәк хуҗалыкныкы булган җирләрне бүлү ничек барырга тиеш? Әгәр крәстиән үзенә тигән 5 гектар җиргә өстәп янә шул кадәр сатып алырга теләсә, ул финанс мәсьәләсен ничек хәл итәргә мөмкин? Бу максаттан махсус кредитлау булырмы? Әлеге реформаны уздыруда кайсы банк ярдәм итәргә алынып дип уйлыйсыз?

– Кемгә, кайда, нинди, күпме җир бирүне урындагы хакимият һәм идарә органнары ярдәмендә авыл кешеләре, килешеп, үзләре хәл итәләр. Узган ел республикабызда, социаль өлкәдә эшләүчеләрне дә кертеп, 460 мең граждан җиргә хосусый милек хуҗасы булу таныклыгы алды. Алар кулына 2,7 млн. гектар җир бушлай бирелде. Бездә һәр гаиләгә уртача 5-6 гектар җир туры килә. Җир алган гражданнарның 60 проценты килешүләр нигезендә үз пайларын төрле крәстиән берләшмәләренә, авыл хуҗалыгы оешмаларына тапшырдылар. Гомумән, җир биләү хокукын гражданнар төрлечә тормышка ашыра алалар. Җирдә үзләре эшләп, фермер хуҗалыгы төзи алалар. Җирне авыл хуҗалыгы предприятиесе, аерым бер оешма яисә крәстиән белән килешү нигезендә, арендага бирергә дә мөмкин. Бусы бигрәк тә пенсионерлар өчен уңай.

Авылда яшәүчеләрнең һәрберсе үз җирендә продукция җитештерә ала дип әйтеп булмый. Бу социаль өлкәдә эшләүчеләргә, пенсионерларга кагылырга мөмкин. Ләкин шундый байлыгың була торып, аннан файдаланмау зур хуҗасызлык булыр иде. Димәк, ул кеше үз паен йә арендага бирә, йә тормыш итәр өчен җирдән файдалануның башка юлын эзли. Киләчәктә сата да алачак.

Берәү саткач, сатып алучы да булырга тиеш бит инде. Аның бу эшкә акчаны банктан алуы да мөмкин. Кайсы банктан дигәндә, минем уемча, коммерция банкларыннан. Ә киләчәктә безнең махсус Җир банкы булырга тиеш. Башка дәүләтләрдә шулай ич. Ссуда күләме, аңа салым процентлары да махсус каралыр дип саныйм. Ничек кенә булмасын, бу эшнең төп максаты шунда: җир хуҗасына җәмгыятькә файдалы эш итәр өчен бөтен мөмкинлекләр тудырылырга тиеш.

– Җир сатыла икән, ул кемнәргә сатыла? Сату таләпләре бер үк булачакмы? (Чит ил кешесе алырга теләсә, Русия кешесе, шәһәр кешесе, авыл кешесе?..)

– Бу мәсьәләдә республикабыз Конституциясенә, законнарына һәм Җир кодексына таянырга кирәк булачак. Аны караганда, халык депутатлары теләгән истә тотып, Татарстан гражданлыгы турында законны да кабул итәсе иде.

Җирне саткан очракта аннан файдалану юнәлешен үзгәртмәү шарт. Сөрүлек җире сөрүлек җире булып калсын. Асфальтта икмәк тә, яшелчә дә үсми. Кемдер авыл чигендә җир алып, яисә элекке хуҗасыннан сатып алып, йорт-каралты булдырырга тели икән, рәхим итсен. Ул аны якыннарына мирас итеп тә калдыра алсын. Тиешле салымнарны түлә дә – төзе, яшә.

Җирне сату-алуда авыл кешесенең хокуклары турында сүз булды инде. Бүтән берәү сатып алырга җыена икән, моннан нигә куркырга? Продукция җитештерсен, салым түләсен, җирен арендага биргән кешеләр белән исәп-хисапны тиешенчә эшләсен. Читтән килеп, авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнергә теләүчеләр алай күп булмас дип уйлыйм. Авыл халкы – сак халык. Кемдер үз паен сата калганда башкалар, җирле хакимият һәм идарә органнары белән берлектә, бу мәсьәләне инәсеннән җебенә кадәр тикшерәчәкләр бит. Һәм җирне ышанычлы кулларга гына бирәчәкләр.

Чит ил кешеләренә килгәндә, әлегә аларга җирне вакытлыча арендага бирү мәсьәләсе генә карала. Бу Русиядә дә шулай.

– Татар халкы, бүгенге авыл кешесе үзенә тиешле җирне юк кына бәягә кемгәдер сатып җибәрер дә, соңыннан үзе үк шул кешегә ялланып эшләргә мәҗбүр булып, үз җирендә батракка әйләнеп калыр дип курка.

– Бу эшне закон нигезендә эшләүне урындагы дәүләт органнары катгый күзәтчелек астында тотачаклар, дип әйттем инде.

"Батрак" дигән мәсьәләгә килсәк, мин шуны әйтим: беркем дә җир хуҗасын үз паен сатарга мәҗбүр итми бит. Теләмисең икән, сатмыйсың, җирдән табыш алып яшисең. Әгәр анда эшли алмасаң? Ул чагында махсус килешү нигезендә син җиреңне арендага бирә аласың, шуның хисабына яшисең. Дөрес, бу очракта синең табышың үзең эшләгәннән кимрәк булачак. Нишләмәк кирәк, буш җиреңә карап утырудан тамак туймый бит.

Сез "ялчы" дисез. Әлегә кадәр колхозчы кем иде соң?

Дәүләт ялчысы түгелмени? Үз хезмәте нәтиҗәләренә ул үзе хуҗа була ала идемени? Гомер-гомергә крәстиән җир хуҗасы булырга омтылган, тик була алмаган. Ниһаять, андый мөмкинлек туа. Тулы хуҗа булсын, эшләсен, тормышын матур итеп рәткә салсын.

Авыл җирендә татарлар күбрәк яши, алар ялчы хәлендә калыр дип курку урынсыз. Татар халкы һәрвакыт хезмәт сөючән, уңган булган. Җирнең чын хуҗасына әйләнгәч, нишләп ул шушы сыйфатларны югалтсын икән?! Мин дә татар улы, аңа начарлык теләмим һәм туган халкымның яңача, мул яши башлаячагына ихлас күңелдән ышанам.

Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 180 ел

Мәрҗани һәм халкыбыз язмышы

"Шиһабетдин Мәрҗанинең шәкерт чагы". Рәссам Чыңгыз Әхмәров эше. Портрет язучы Әмирхан Еники гаиләсендә саклана.

М.ШАКИРҖАНОВ фотокүчермәсе.

Шиһабетдин Мәрҗани заманында, бөтен колониаль һәм үз дәүләтләре булмаган халыклар алдындагы кебек үк, татар халкы алдында да Русия шартларында үз-үзен ничек саклап калырга дигән проблема торган. Шундый шартларда үз-үзен саклап калу өчен татарлар заманга яраклашкан һәм урыслар белән ярыша алырлык дәрәҗәдәге заманча халык булырга тиеш иде.

Нәрсә дигән сүз ул – заманча халык? Заманча халык – ул, минемчә, бер яктан гомумдөнья цивилизациясе казанышларына ия һәм шул ук вакытта үз милли мәдәниятен, ягъни үз милли йөзен дә югалтмаган халык булырга тиеш.

Цивилизация күзлегеннән караганда, Петр I заманына кадәр татар урыстан калышмый, чөнки урыс та, татар да башка дөньядан аерылып, бер патриархаль-феодаль җәмгыять эчендә яшиләр. Ләкин урыслар Петр I реформалары белән дөнья цивилизациясенә таба йөз тота башлыйлар. XIX гасырның урталарында аларда буржуаз мөнәсәбәтләргә таба борылыш башлана.

Татар җәмгыяте исә ул заманда нигездә татар-ислам кабыгы эченә бикләнеп яши. Мондый кадими тормышның үзенә күрә өч принциптан торган идеологиясе дә булган: аурупалашмаска, хатын-кызларны укытмаска, урыс телен өйрәнмәскә.

Нәкъ менә шушы заманда Ш.Мәрҗани, реформатор буларак, татар халкының дөнья цивилизациясеннән артта калуын сизеп ала. Бу – татарлар өчен куркыныч хәл була, чөнки үз дәүләтсез халык, цивилизациядән дә артта калса, башка халык тарафыннан мотлак йотылачак. Шуңа күрә Ш.Мәрҗани татарларны дөнья цивилизациясен үзләштерергә, ягъни Аурупа фәннәрен, техниканы, музыканы өйрәнергә, хатын-кызларга белем бирергә һәм кирәгенчә урысча өйрәнергә өнди.

Ләкин галимебез милләтнең икенче нигез баганасын да, ягъни, ислам белән береккән милли мәдәниятне дә онытмый. Ш.Мәрҗани фикеренчә, татарлар гомумдөнья цивилизациясе җимешләрен үзләштерергә тиешләр, ләкин бу эш мәдәният исәбенә эшләнергә тиеш түгел.

Минемчә, бу бик дөрес фикер, чөнки цивилизация безгә фәкать белем, мәгълүмат кына бирә, ә милли мәдәният исә безне татар итеп тәрбияли, безне иманлы, милли идеаллы итә.

Бу җәһәттән Ш.Мәрҗани сүзләрен китерәсем килә. Ул болай дигән: "Дөньядагы төрле телләрне белергә, белем тупларга ислам дине каршы түгел. Ислам дине һәртөрле гыйлемнәргә кызыктыра. Фәкать иң элек исламны яхшы аңларга иманны ныгытырга кирәк. Иман нык булса, урысча уку гына зарар итмәс. Мөселманча белмәенчә, урысча укып калу гына ярый торган эш түгел".

Ш.Мәрҗани, татарлар, урыс мәдәнияте тарафыннан йотылуга дучар булмасын өчен, күп гасырлык мөселман мәдәниятен үз кулларында бер калкан иттереп тотарга тиеш, ди. Шуның өчен ул, яңа күзлектән карап чыгылган ислам мәдәни мирасын халыкка кайтарырга тырыша. Аннары аның идеяләрен XX гасыр башында җәдитчеләр куәтләп җибәрәләр һәм нәтиҗәдә татарлар шактый нык һәм сәламәт акыллы бер милләт булып оеша башлый.

Хәзерге заманга килгәндә шуны әйтергә кирәк: татар халкы, Мәрҗани заманындагы кебек үк, хәзер дә дәүләтсез бер халык булып яши. Ләкин элек Ш.Мәрҗани күтәргән мәсьәлә, ягъни, урыс мохите эчендә татарга татар булып сакланып калу мәсьәләсе элекке заманнарга караганда да кискенрәк тора.

Хәзерге татар милләте үзенең XX гасыр башындагы үсеш дәрәҗәсенә әле һаман ирешә алмый. Бер генә мисал китерим. Революциягә кадәр татар телендә ике махсус икътисади журнал чыга. Болар – Самарадагы "Икътисад" һәм Казандагы "Русия сәүдәсе" журналлары иде. Хәзерге вакытта исә икътисад буенча татар телен[...] гомумән бер журнал да юк.

Чыннан да, татарлар дөнья цивилизациясе ка[...]занышларын урыс теле аша гына үзләштерер[...] баралар. Мәсәлән, кампитрларда эшлиләр, икъти[...]сад, техника буенча урысча диссертацияләр яза[...]лар, Татарстан белән урыс теле ярдәмендә идар[...]дә итәләр.

Әмма милли мәдәниятебез бик зәгыйфь хәлд[...] Милли университет һаман юк, чын мәгънәсенд[...] тулы канлы, ягъни, көненә 18 сәгать эшли тор[...]ган милли телевидениебез юк, автономиябез югарылыгында милли приоритетлар һәм идеаллар һаман билгеләнмәгән.

Минемчә, Татарстанда татар мәдәнияте исәбенә ачыктан-ачык урыс телле цивилизация үстерелә. Шул уңайдан бер генә факт китерәсем килә. Мәсәлән, 7 миллионлы татар халкының телен үстерүгә Татарстан бюджетыннан 1998 елга 6 миллиард сум гына акча каралган, ә "Ак барс" хоккей командасына – 30 миллиард сум акча бүленгән. Димәк, татар телен үстерүгә һәр татар кешесенә ел саен фәкать 850 сум акча туры килгәндә, "Ак барс" командасында хоккей уйнаган өчен һәр урыс җегетенә – 1,5 миллиард сум туры килә.

Элек мондый сәясәтне Мәскәүгә сылтыйлар иде, хәзер сылтамыйлар инде, кирәге юк, чөнки "урысча цивилизованный" һәм "татарча тынак" булган татар халкы эндәшми. Бу хәлләр Ш.Мәрҗани идеяләренең татар җәмгыятендә һаман да бик актуаль булганын күрсәтә.

Рафаэль МӨХӘММӘТДИНОВ,
Татарстан Фәннәр академиясенең Тарих институты өлкән фәнни хезмәткәре.

РЕДАКЦИЯДӘН. Ш.Мәрҗани юбилее уңаеннан әзерләнгән язмаларны гәзитебезнең алдагы саннарында укырсыз.

ВАКЫЙГАЛАР, ХӘЛЛӘР, ЯҢАЛЫКЛАР
турында
хәбәр итү өчен
телефон:
32-60-11

Чынлы чишмәләре

Чынлы суы җәелеп ага,
Язгы ташкыннар килсә...
М.НОГМАН

Чүпрәле-Бездна калкулыгыннан агып чыккан Кече Чынлы инеше, үз юлында 50-60 чакрым басу-кырларны, иңкү-болыннарны дуамал ярып, сырт урыннарны җайлы гына урап, елга-ерынты, чишмә-чоңгыл суларын туплап, Зөя елгасына барып кушыла. Инешнең урта агымында, ярының ике ягына да җәелеп татар халкының көнбатыш диалектында сөйләшүче, ягъни мишәр дигән төркеме килеп төпләнгән – зур бер авыл барлыкка килгән, һәм аңа Кече Чынлы дигән исем биргәннәр.

Кече Чынлы инеше буена килеп иң әүвәл нигез коручылар, һичшиксез, инешнең төньяк ярыннан тибеп торган йомшак, тәмле, шифалы чишмә суыннан авыз иткәннәрдер. Әлеге чишмә хәзерге көндә Голдыр кизләве дип атала. Югары очта, инешнең һәр ике ягында яшәүчеләр дә кизләү суын чәйгә генә тоталар. Чишмәдән су җәен, көзен һәм кышын да туктамый агып ята, саекмый.

Шундый зур авыл булсын да, үзенең риваятьләре булмасын, имеш! Бар ул риваятьләр безнең авылда да, бар. Шуларның берсе мондыйрак аянычлы хәлне сөйли.

Моннан берәр йөз ел элек авылыбызда Алиулла атлы карт яшәгән. Әлеге чишмәне даими рәвештә әрчеп-чистартып торган, ә бер заман хәтта әле аңа бура да корыштырган – тәмам кое рәвешенә китергән. Тик менә бәла агач башыннан йөрми, кеше башыннан йөри шул: буранлы көннәрнең берсендә, аягы таеп, бурасы эченә үзе төшеп киткән икән... Алиулла бабай бераз гырылдабрак сөйләшә торган кеше булган. Шул фаҗигале хәлдән соң кешеләргә аның тавы-



шы ишетелгән сыман тоелган. Халык озак баш ватып азапланмаган – чишмәгә тоткан да Голдыр кизләве дип исем биргән...

Моннан ун-унбиш ел чамасы элек ул вакыттагы авыл советы рәисе (инде мәрхүм) Яхъя Вәлиев чишмәгә тәрбия күрсәтә: су чыганагына тимер-бетон кыршаулар салдыра, кое тирәли бетон җәйдерә, чыгырлы чылбыр куеп, кул көче ярдәмендә су алуны җайлаштыра, коеның өстен калай белән каплата, кое мәйданын тимер рәшәткә белән әйләндереп алдыра.

Кое суының тирәнлеге җиде метрга җитә, дип сөйлиләр. Ничәмә-ничә буын авылдашларыбызга үзенең шифалы суын эчергән Голдыр кизләве әле киләчәктә дә ул суын һичкемнән кызганмас, янә дә гасырлар буе кешеләргә хезмәт күрсәтер, дип ышанасы килә...

Әйе, безнең авыл халкы борынгыдан бирле чишмәгә, әлеге дә баягы Голдыр кизләвенә сыенып яшәгән, һәр нәселдән-төптән яшьләр башка чыгып, йортны мөмкин кадәр чишмәгә якынрак куярга тырышкан. Бу хәл һич тә мишәрләрнең уңган булган халык икәненә күләгә төшерми, шик-шөбһә тудырмый: авылыбызда коелар да бик күп, әмма бер генә коеның суы да Голдыр бабай кизләвенең суына тиңләшә алмаган, алмады һәм...

Җәмәгать, әгәр хәзер без, тиңләшә алмас та, дисәк, ялганчы булырбыз, чынбарлыктан ераклашырбыз.

Безнең авыл халкы элек-электән бичара-мескен булмаган, бүтәннәр алдында ким-хур булып яшәмәгән. Төбәктәге Сабан туйларында ким дигәндә ике елның берендә безнең авыл егетләре батыр кала килә. Күрше авылдагы базарда, нидер бүлешкәндә сүзгә килеп, йодрык уйната башласалар, ярты базар кызып-кызып сугышкан чакны берәүнең шунда:

– Чынлылар килә!.. – дип очыргаланып кычкырып җибәрүе бөтен дөмбәсләшүгә чик куя.

Чөнки авылыбыз егетләре тирә-юньдәгеләрдән буйга да калкурак, гәүдәгә дә тазарак, халык ягыннан да гайрәтлерәк-саллырак. Алар сиңа юкка-барга һич бәйләнмәсләр, тик инде җае чыкканда көч-гайрәтне сынаудан да баш тартмаслар. Көпә-көндез сугышып ятканны күрсәләр, ай-һай, моның сәбәбен сорап, әвәләшүнең нидән килеп чыгуын ачыклап торырлар микән?! Тиз арада әтәчләнгән егетләрне генә түгел, кул астына очраган берен, һәммәкиен уңлы-суллы җиргә сылап ташламыйча туктый белмиләр.

Тик менә таза-таза егетләрнең, гомумән, яшьләрнең авылда калырга теләмичә, берәм-берәм шәһәргә китеп барулары гына бер дә сөендерми күмәк хуҗалык рәисе Борис Гафуровны. Вакытында тугыз мәчете булган Кече Чынлы авылында ике катлы мәчет җиткезү эшеннән дә читтә калмый болай үзе, әмма яшьләрне аның белән генә тәртәгә кертеп булмаганын күреп тора Гафуров. Шуннан уйга кала рәисебез, ныклап уйлана. Яшь-җилкенчәкнең җаена да бара инде, югыйсә. Хезмәт алдынгыларына бүләген дә һич кызганмый, заманча булдырырга тырыша. Тагын ниләр генә эшлисе икән? Яшьләрне авылда ничек итеп саклап калдырасы икән?..

Әйе, гомере буе колхозда тырышып эшләгән, сугыш михнәтләренә дә бирешмәгән карт-коры белән генә әлләни майтара алмаячагын аңлый Борис Гафуров. Уйлый торгач, ниһаять, төпле бер карарга килә. Иң әүвәл югары урамда артезиан коесы казыта. Үз урамында түгел, бөтенләй әллә кайда, инешнең аргы ягында, халык мәнфәгатен кайгыртып, суга интекмәсеннәр әле, дип казыта. Нияте изге булгач, морадына ирешә рәисебез: артезиан суы җиде кат җир астыннан чыккач, әлбәттә инде, шул тирәдәге коелар суы ише генә булмыйча, Голдыр кизләвенең суына бирешкесез булып чыга. Өстәвенә, халык торбалардан килгән суга кинәнә.

Әмма рәиснең халык өчен тырышуы, крәстиән мәнфәгатен кайгыртуы моның белән генә чикләнми. Һәркайсыбыз йөри торган авыл урамы бар бит әле. Аны һич тә син читләтеп үтә алмыйсың. Кайчандыр авыл урамнарында чирәм үскән, хәзер исә техника ермачлап бетергән ул урамнар көзге яңгырлар вакытында лачма суга, сазга әйләнә. Сугыш елларында район түрәләренә тәлинкә тотудан узмаган, аларның әмерләрен үтәү йөзеннән, ата-бабаларның кабер ташларын кубарып алып, күпер төбенә түшәткән рәисләрнең вәхшилеген кабатламассың ич инде. Балчыктан-саздан чыгу юлы бер генә: фәкать асфальт түшәтеп кенә котылырга мөмкин бу бәладән. Иң әүвәл эшне чакрымнарга сузылган зур урамнарга асфальт җәйдерүдән башлый Гафуров. Аннары ярты гасыр буена рәтле күпер күрмәгән Чынлы халкына сугыш вакытында ташу бозлары җимергән, агызып алып киткән искиткеч матур агач күпер урынына шундый ук мәһабәт күперне тимердән салдырып куя. Тагын нинди хикмәтләр чыгарыр икән, дип кенә көткәндә...

Бер заман рәисебез ярыйсы ук җитди кыяфәт белән:

– Газ да керттерсәм авылга, яшьләрне үзебездә калдырам!.. – дип игълан итә.

Авылда иген игеп, малтуар асрап яшәү өчен сиңа бит әле нәрсә белән булса да аш-су әзерләргә, өеңне җылытырга кирәк. Бүгенге көндә салам ягып кына котыла алмыйсың. Шулай булгач, утыны кирәк, күмере кирәк...

Иһ-и-и! Безнең тирәдә бит аның берсе дә юк – ни урманы, ни күмере. Әллә кайлардан китергән күмер өчен синнән каерып малың алалар. Аның янына тагын өзелеп тә йолкынып утынын табыштырмыйча хәлең юк...

Халыкны шундый да зур мәшәкатьтән коткару дәрте рәисебезнең җан тынычлыгын ала, төн йокыларыннан мәхрүм итә. Әмма акыллы хуҗа кыенлыктан чыгу юлын шулай да таба. Район хакимиятеннән сукыр бер тиен алмаган хәлдә дә җиңеп чыга. Дөрес, һәр хуҗалыктан аз-маз акча җыялар җыюын, тик инде бүрәнәнең авыр башы Алып батырдай рәиснең үз җилкәсенә төшә. Безнең халыктагы "Ашаган белми – тураган белә" дигән мәкаль бик дөрес булып чыга. Ничәмә-ничә чакрымга җитәрлек торбаның калынын да, нәзеген дә нефть якларына барып табыштырасы, аны кайтартасы, атлаган саен хакын түлисе дә бар бит әле...

Барометр шикелле сизгер бит ул халык дигәнең. Олуг мәшәкатьне киң җилкәсенә алган Бориска ярдәм итәргә ашкынып торучылар санап бетергесез була. Арада техниканы, газ эшләрен үз йортын белгән шикелле белүче егетләр дә булып, гаять зур уңганлык вә тырышлык күрсәтәләр.

Җилкәсеннән тау төшкәч, рәисебез төрле җирдә яшәүче авылдашларга хәбәр бирә:

– Газ керттек авылга. Кайтыгыз тантанага! – дип кунакка чакыра.

Кайтмыйлармы соң салам ягып үскән, хәерчелектән җәяүләп качкан авылдашлар, кайтмый димени шундый тантанага!

Чынлап уйлап карасаң, исеңакылың китәрлек хәл бит, җәмәгать! Ничәмә-ничә йөз еллык тарихы булган Кече Чынлы авылына мондый да зур Яңа ел бүләген әлегә хәтле бер генә Кыш бабай да китермәгәндер. Менә ни сәбәпле авыл клубы шыгрым тулы: бу юлы яшь-җилкенчәк кенә түгел, бәлки, гомер буена колхоз кырында фидакяр көч түккән әбиләр-бабайлар да бәйрәмчә киенеп килгән иде. Һәркемнең йөзендә рәхмәт хисен белдергән балку-елмаю. Хәтта иң кырыс чырайлар да гадәттән тыш йомшарган, күзләрендә әйтеп бетергесез бәхет вә сәгадәт иде. Колхоз яралганнан бирле рәисләрнең төрлесен күрде бу халык: миһербансызын да, угрысын да, булдыксызын-җебегәнен дә, урак өстендә тун киеп кенә җылына алган хөрәсән ялкауларын да, атналар-айлар буе айный алмаганнарын да... Булды рәисләрнең төрлесе, мәгәр булмады Борис Гафуров чаклы халык мәнфәгатен кайгыртып йөрүче, янып-пешеп эшли ала торган уңганы.

Сабан туе батыры бер генә җиңүгә һич тә канәгать була алмый. Безнең рәистә нәкъ шулай. 1997 елны шундый зур тантана белән каршылаганнан соң бераз масаебрак-сабырланыбрак калса да, артык гаҗәпләнмәс идең. Ләкин ул яңа үрләрне яуларга ургылды – язгы чәчүгә әзерлек эшләрен кайгыртты, хезмәткә ярарлык көчләрне барладытуплады, механизаторларның хәләхвәлен белешә торды, гадәттә иплe генә сөйләшсә дә, кирәк чагында утлы табага да бастыра белде. Һәм нәтиҗәсе...

Нәтиҗәсе һәркемне сөендерерлек булды шул, җәмәгать. Кара туфраклы Кече Чынлы кырларында игеннәр төрле елны төрлечәрәк уңучан. Күмәк хуҗалык яшәгән дәвердә беренче мәртәбә мул уңыш 1937 елны булгандыр. Икенчесе 1941 елны, әмма анысын җыеп алырга, ил табынына куярга насыйп булмады... Сугыштан соң колхоз гектарыннан 6-7 центнер уңыш алу өчен көрәште. Бүген исә игеннәр, бигрәк тә сабан бодае шаулап үсте. Басуда хәзер син им-том өчен эзләсәң дә чүп-мазар таба алмассың. Шул чаклы тәрбия күргәч, әлбәттә, игеннәр дә крәстиәнне сөендерде: һәр гектардан 54,5 центнер уңыш алынды.

Чынлы чишмәләре дип башлаган сүзебездән читкәрәк киттек шикелле. Әйе, бар ул чишмәләр Кече Чынлы төбәгендә, бүген дә бар.

Авылның төньягында, сизелерсизелмәс кенә үрне менгәч, хәйран калырлык матур уйсулык бар. Иң гаҗәбе шунда ки, авылыбызның буеннан-буена сузылган әлеге үзәнлекнең өч исеме яшәп килә: көнбатыштагы, башланып киткән – әллә күпме чишмәдән су алып, үзенә юл ярган уйсу җиргә Диңгелде диләр; авылның уртасына таба ул уйсулык ярыйсы ук тирәнәеп китә, һәм бу өлешенә Тирән елга (Чатказ яки Чепкас авылына юл шуннан узганга Чатказ елгасы дигән исем дә йөри) дип әйтәләр – чишмәләрдән су җыела, ярлары торган саен текәрәк, биегрәк була бара (шуңа аның күпере дә түбәнгә, текә ярлар астына салынган); авылның кояш чыгышы ягындагы, ягъни Түбән оч турысындагы өлеше исә Тинчәле елгасы дип атала. Әмма ярлар акрынлап карсагая, басу белән авыл арасындагы уйсулыкка әйләнеп кала. Түбән очка җитәрәк, чишмәләрдән чыккан су исәбенә ишәеп, киң бер мәйданга җәелгән җирендә тимер-бетоннан буа корып җибәргәннән соң хәйран гына сусаклагыч барлыкка килгән, халык аңа "Океан" дип исем биргән. Океанда балык үрчетү хәбәрен әллә балыкчылардан ишеткәннәр инде – каяндыр акчарлаклар да килеп җиткән, чишмәләрдән җыелган Океан суын гүя алар да үз иткән...

Зөфәр АЛИМОВ,
Кыям МИҢЛЕБАЕВ.

"Федераль" үзәкнең демократия пәрдәсенә төренүенең сәяси уен гына булуы Русия-Чичән сугышы вакытында бөтен гарипләре белән ачылды. Бүгенге Русиянең урыс булмаган халыкларга һәм милләтләргә каршы эшләгән гамәлләре – асылда патша самодержавиесе сәясәтенең дәвамы ул. Үз ва- буенча һәр граждан үз милләтен һәм ана телен үзе билгели һәм ул телдә сөйләшү-аралашу хокукына ия. Бу конституцион нормалар гражданның төп документы – паспортны алганда кулланыла торган закон буларак гамәлдә. Русия Конституциясенең 70 нче маддәсе буенча дәүләт туграсы, аның состав өлешләре һәм рәсми куллану тәртибе башкарма органнарның, шул исәптән, Президентның ихтыяры буенча түгел, ә федераль конституцион Закон белән җайга салына. Бу очракта Русия парламентының авызына су капкандай утырып, бу мәсьәләдә күндәмлек күрсәтүе законга сыймый. Монда Русия Конституциясе таләпләрен санга сукмау ярылып ята. Хөкүмәт элитасы шулай ук дәүләтләр өчен үтәү мәҗбүри булган халыкара хокук нормаларын да санга сукмый. Ә ул нормалар буенча эшкә сәләтле (балигъ булган) һәр гражданга:

– үз-үзен идентификацияләү (раслау),

– дәүләт символларын билгеләгәндә турыдан-туры катнашу хокукы,

– гражданлыкны үзе сайлау яки теләсә нинди дәүләт гражданлыгыннан иректе рәвештә чыгу, баш тарту, кешенең бөтен башка милли хокукларын тормышка ашыру мөмкинлеге бирелергә тиеш.

кайберәүләр яшертен эш алып барып, халыклар белән песи тычкан белән уйнаган шикелле кыландылар. Халыкларга ташланган бер агулы сәяси "ризыгыгыз" төрле. Янәсе, паспортларда "милләт" графасы булмау – кешелеклелек, прогрессив күренеш. Бу халыкларны тигез хокуклы итә һәм "милли билге" буенча эзәрлекләүләрдән коткара. Янәсе, безнең бер-беребездән аермабыз юк, барыбыз да "русиялеләр". Ләкин әйтегез әле: сез "инородецлардан" шундый "россияннар" булырга ризалыкларын сорадыгызмы? Сезнең өчен барлык милли республикалар исеменнән җавап бер генә – теләмиләр һәм, билгеле булганча, моңа җитди сәбәпләре бар. Мисаллар эзләп укучыларны ялкытмыйк, шуны гына әйтик: Чичән иле белән Татарстан күптән инде барлык халыкара хокук кануннары буенча мөстәкыйль дәүләтләр булачак үзбилгеләнү хокукы алдылар, башка милли республикалар да мөстәкыйльлекләрен игълан иттеләр, аеруча милли мәсьәлә буенча. Сез һәрвакыт шундый сорау куясыз: "Нәрсә соң бу, нигә суверенитет яклылар берләшмиләр, цивилизацияле Аурупа берләшә бит?" Һәм сорау

Русия Конституциясе, суверен дәүләтләр бердәмлеген Федерация дип таныса да, үзенең беренче маддәсендә ук Русия Федерациясе белән Русиянең тигезлеген ныгытып куйды. Ә бит бу – элекке Русия империясен, аның сәяси акылын саклап калу дигән сүз. Һәм Контитуция кабул иткәндә Федерацияне тәшкил итүче, аның составына кергән суверен республикалар-дәүләтләр белән бу турыда киңәшеп торучы да булмады. Югыйсә, һәркемгә мәгълүм: Федерация һәм Русия икесе бер нәрсә түгел. Алар төрле дәүләтләр. "Русия Федерациясен" империя (союз) дип танымаган очракта, монда элементар мантыйк буенча да очы-очка ялганмый. Хокук күзлегеннән караганда да Русия – милли республикалар-дәүләтләрне исәпкә алмаган Русия ул. Ә Федерация – ул суверен дәүләтләрнең иректе кушылуы нигезендә генә федерация була ала. Мәсәлән, Русия һәм Татарстан, Русия-Башкортстан, Русия-Чуашстан, Русия-Якутия һ.б. кебек. Кабатлап әйтәм, бары тик тулы тигезлек нигезендә һәм бары тик үз теләкләре белән ку-

Гаял МОРТАЗИН,
юстиция советнигы

Өстебезгә ике башлы аждаһа килә

кытында милли территорияләрдә килеп чыккан суверенлыкка омтылуның табигый процессларын туктата алмаган Русия "федераль" үзәге йә ачыктан-ачык халыкның хыялларына киртә куя, йә аларның җимеш бирүгә сәләтле тамырларына яшертен генә балта чаба. Бүгенге чорда ул карусыз, "русияле", "урыс телле", ягъни милләте булмаган бер халык тудыру уе белән яна. Һәм, шул программасын тормышка ашыру йөзеннән, халыкларны юкка чыгаруга илтә торган гөбернәләштерүгә йөз тота. Үзәкнең йөз битлекле коммунистлары һәм демократлары милләтләргә үзбилгеләнү ирешкән һәм үзләре теләгәнчә тәрәккый итү хокукын игълан иткән халыкара хокук нормаларын күрмәмешкә салышалар. Гөбернәләштерү юлында Мәскәү суверен республикаларга колониаль патша империясе символларын көчләп тага. Ә бит йөз еллар дәвамында Русия империясе көчләп буйсындырылган халыкларга карата геноцид сәясәте алып барды, хисапсыз һәм чамасыз вандализм гамәлләрен кылды. Соңгы елларда Русия "федераль" үзәге "русиялеләргә" котырган канәчкечне хәтерләткән ике башлы каракош сурәте – империя символы төшерелгән яңа паспорт үрнәге "бүләк итте". Бу паспортта кешеләрнең милләтенә урын калдырылмаган. Бүгенге Русия цинизмына чикләр юк. Хәтта Русиянең үзендә дә мондый аждаһа сурәтенең тугра (герб) сыйфатында әлегә расланганы булмады. Әмма ул инде Русия халыклары өстендә, Президент Б.Ельциннан фатиха алып, кара канатларын җәя. Хөкүмәт башындагы элита Русияне Конституцион Федерация итеп күрсәтергә маташа. Ә бит аның төп законы – Конституциясе милли республикалар һәм территорияләр тарафыннан расланмады. Татарстан да шулар исәбенә керә. Ярый, бу сугышчан Конституцияне, шартлы рәвештә, гамәл дип уйладык, ди. Ә бит ике башлы каракош сурәтле туграны рәсмиләштерү һәм паспорттагы "милләт" графасын юкка чыгару Русиянең Төп Законын дорфа рәвештә бозу ич: Конституциянең 26 нчы маддәсе

Шул уңайдан Русиянең, элекке СССРның хокукларын гына түгел, халыкара йөкләмәләрне үтәүне мирас итеп алуын да әйтеп үтү кирәк. Соңгы вакытта Русия, аны демократизацияләү максатыннан, Аурупа Советына кабул ителде. Русиянең гражданлык мәсьәләләре һәм паспорт эшләре буенча хәзерге башбаштаклыгын киң масштаблы ассимиляцияләүне законлаштыру һәм империя тәртипләрен юридик яктан ныгыту омтылышы дип кенә бәяләп була. Бу – карусыз, җиңел идарә ителә, теләсә нинди авантюрага көчләп катнаштырыла торган бердәнбер милләтле – "русияле халык"ны ясалма рәвештә барлыкка китерүгә юнәлдерелгән һәм шовинистик сәясәтчеләр тарафыннан башкарыла торган яман эш. Империя беркайчан да цивилизацияле гамәлләр кылырга сәләтле булмады. Ә аның сәясәтчеләре һәр "россиян"ның үзенә кагылган мәсьәләләрне үзбашка чишәргә хокукы барын белә торып та, көтү көткән чабаннар шикелле, халыкларны тупыйкка өереп кертә тордылар. Якын тарихыбыз шаһит: мондый "көтүчеләр" бихисап русиялеләрне, әгәр әти-әниләре, туганнары көчләү сәясәтен үткәргәндә каршылык күрсәтә калса, ул кешене үз әти-әниләреннән, туганнарыннан баш тартырга да мәҗбүр иттеләр.

Бик күп сабыр иткәннән соң, империячел сәясәт тарафдарларына бер сорау бирәсе килә: сез кайчан үзегезнең мәкерле планнарыгыздан баш тартырсыз икән, әллә XXI гасырда да гайре табигый эшләрегезне дәвам итәрсезме? Ләкин, ничек кенә булмасын, көчләү яки мәкерле эшләр нигезендә сезгә кешелекнең табигатен җимерү, үзкыйммәтләрен гарипләндерү инде мөмкин булмаячак. Күпләргә мәгълүм: сез ялган һәм алдау юлы белән, моның өчен оятсыз сүз уйнатулардан да тайчанмыйча, һәрвакыт халыкны ялгыш юлга кертеп адаштырырга тырыштыгыз. Сезнең мәкер һәм хәйләләр астында һәрвакыт бер хыялый максат – урыс булмаган халыклардан урыска әйләндерелгән бер халык ясау, аларны бер утлы казанда кайнату максаты ята иде. Күпчелек галимнәрегез һәм сәясәтчеләрегез моны яшереп тә тормадылар, ясалма ассимиляцияләү турында бөтен дөнья каршында лаф ордылар. Ә

биргәндә шундый беркатлылык күрсәтәсез: гүя әле бернәрсә дә булмаган, берни дә аңламыйсыз, берни дә белмисез. Сезнең өчен билгеле һәм объектив хакыйкатьне тагын бер мәртәбә кабатлыйк. Цивилизацияле Аурупа, империячел дәгъваларыннан ваз кичеп, чынлап та берләшә, әмма – цивилизация нигезендә генә. Аурупа башка дәүләтләрнең һәм мөстәкыйль милләтләрнең мөстәкыйльлегенә зыян китермичә генә берләшә. Аурупа Союзы белән берләшкәнче, Германия үз дәүләтен берләштерүгә ирешмәдемени? Бүген Германия, Аурупага ярыйм, дип үз мөстәкыйльлегеннән баш тартмый, киресенчә, нимес милләтенең саклануы һәм алга таба тәрәккый итүе бәрабәренә, үз дәүләтен ныгыту буенча эшли. Германия үз милли теленнән ваз кичми, башка дәүләтләр белән берләшәм, дип аны кысмый, кимсеттерми. Мондый эшкә беркем дә бармый һәм бармас та. Англия белән Франция турында да шуны ук әйтергә була. Сез Русия обывательләрен Англия һәм Франция паспортларында "милләт" графасы юк, дип кызыктырган буласыз. Ләкин сез бик яхшы беләсез: Германия – немецләрнеке, Франция – французларныкы, аларның төп милләтләре күпчелекне тәшкил иткәнгә һәм һәр эштә мөстәкыйль булганга күрә, алар башка милләтләр басымын сизмиләр: яхшы үсеш алган үз дәүләт телләре, мәдәниятләре, гадәт-йолалары, үз мөстәкыйльлекләре һәм үзенчәлекләре үзләре белән кала. Бу Аурупа дәүләтләре, бер Союзга берләшеп, бары тик үзләренең иминлекләрен тәэмин итү турында уйладылар. Бәлки, алар Русиядәге хәлләрне күреп, коллектив иминлек турында кайгырткannardыр. Әйе, алар беркайчан да үз бәйсезлекләреннән баш тартмаячак. Ә Русия үзе бәйсезлек теләмимени? "Русия Федерациясе – Русия – урыслар өчен" – шовинистлар шулай лаф ора, күкрәк suga. Ә бит бер генә нимес тә беркайчан да Аурупа Союзы – Германия нимесләр өчен генә дип әйтәчәк түгел. Инглизләр дә Аурупа Союзы – Англия ул димәсләр. Әгәр кем дә булса "Аурупа Союзы – Франция ул" дисә, французлар аны авыру кешегә санарлар иде. Ә менә шовинистлар теле белән

шылганда гына. Референдумда халык ихтыяры белән үзен мөстәкыйль дәүләт дип игълан иткән Татарстанның бәйсез, суверен һәм һәрьяктан Русия белән бертигез дәүләт икәне инде бөтен дөньяга билгеле. Ә аның вәкаләтле органнары башка суверен дәүләтләр белән тигез хәлдә дәүләтара килешүләр төзергә хокуклы иде.Шуңа күрә, теләсә нинди хәлләрдә, тигезлеккә корылмаган дәүләтара килешүләр юридик яктан бер тиенгә тормыйлар һәм, шулай булгач, гамәлдә түгел дип исәпләнәләр.

Шовинист әфәнделәр! Сез инде, әлбәттә, моннан соң да Русия белән берләшергә теләмәү җәһәтеннән икейөзләнерсез. Милли дәүләтләрнең империя составына ничек килеп кабулары турында сез үзегез дә бик яхшы беләсез. Һәркемгә билгеле: ул дәүләтләр басып алынды һәм Русия составына көчләп кертелде. Табигать законнарына һәм тәңре ихтыярына каршы килеп, билгеле. Әгәр кайчандыр мондый гамәлләр кылуда Русия дәүләте кодрәт һәм кыюлык күрсәткән икән, ник соң әле аның бүгенге варислары, кыюлык, көч һәм юридик яктан зирәклек күрсәтеп, үткән тарихларын танып, тәүбә итеп, цивилизация нигезендә бу хәлләрне төзәтергә атлыгып тормыйлар? Сез, шовинистлар, гаделлек турында, үзегезгә кирәге чыкканда, бик еш сөйлисез. Гаделлек дигәндә, сез, "бердәнбер һәм бүленмәс империя" принцибыннан беркайчан да ерак китә алмассыз. Әйтелгәнгә өстәп, бердәнбер дөреслекне раслаучы мисал китерәм: Русия Иминлек Советы секретаре Иван Рыбкин болай дип белдерә: "Безнең борынгы бабаларыбыз империяне төзегәннәр, безнең, аларның варисларының, империя чикләрен кичерәйтергә хакыбыз юк". Сез яулап алучы патшаларыгызны юкка гына мактамыйсыз һәм буйсындырылган халыкларда гына түгел, бәлки барлык намуслы, гуманлы кешеләрдә нәфрәт уяткан канлы самодержавие тәртипләрен кабат кайтарасыз. Әлбәттә, бу очракта да "инородецлар" фи-

(Ахыры 8 нче биттә).



Әдхәт СИНУГЫЛ

Сагындыра сагынмаганнар да...

шигырь нечкәлек билгесе белән языла

Безнең исем

Безнең исем – чын кеше исеме,
Исем,алай, "Вели-мир"дан түгел.
Безнең исем гадидән дә гади:
Гайни, Ярми, Габделҗаббар, Әйди.

Без дөнья яуларга җыенмыйбыз,
"Влади-мир" түгел исемебез...
Исем безнең, үзебездәй, гади:
Кәли, Вәли, Шәйхелислам, Дәүли.

Залим исем – "Грозный" да түгел,
Моңа карап төшми бер дә күңел.
Исемебез галиләрдән гали:
Мәрди, Нәби, Габдрахман, Гали.

Исем алай, "Мудрый" булмаса да,
Бик ахмак та түгелбез, ләбаса!
Танырдайлар бар да безне таный:
Гази, Гани, Тимер, Тимергали.

"Слава" ук исемебез түгел...
Шулай да без затсыз халык түгел!
Исем инде үзебезгә ярый:
Хәйри, Һади, Колшәриф, Колгали...

Март, 1977.

Кышлар көтәдер

Ерактагы кояш җылырак күренә.
Татар халык мәкале.

Туган якта кышлар кунак итәдер,
Бураннары өйне күмеп китәдер.
Ерак калган балачакның кышында
Туган яклар карын күрим төшемдә.
Чаңгы шуам балачагым илендә,
Ятим еллар карын тоеп иңемдә.

Кышны ташлап киткән кучмә кошлар да,
Салам яккан мичләр яна эчләрдә.
Күз алдымда: күзачкысыз бураннар,
Адашудан туңып үлгән корбаннар...

Чана шуып, кар тауларын кочканнар,
Мамык карны сөзеп, коштай очканнар –
Истә бар да: эт сугарып йөрүләр,
Куян куып, этләр булып өрүләр.

Истә әл дә: ис китмичә буранга,
Ясап кую "карбабай"лар урамда.
Кышкы озын әкияти кичләр дә...
"Аулак өй"ләр, "урнаш аш"лар исләрдә.

Истә яши җуелмый Кыш илләре,
Сөйләп кенә бирергә юк телләре –
Кайнарлыгын карлы якның өйләрен,
Тәрәзләрдә бозлар үскән гөлләрен.

Каз-үрдәкләр суеп кышның сыена,
Туй итүен кышның кышлар буена,
Карурманнар пакьлеген кыш көннәре,
Сөйләп кенә бирәлми Кыш телләре!

..Кышлар һәр кыш, шулай, кышлап китәдер,
Мине кышлар юксындырып бетәдер.
Кышлар сезнең җаныгызга үтәдер,
Минем җаным кыш сагынып үтәдер!
Туган якта мине кышлар көтәдер...

Гыйнвар, 1995.

Анам теле

И туган тел, и матур тел...
Г.Тукай.

И бичара, Анам теле –
Ничек син түгел үле:
Гарәпләштең, фарсылаштың,
Һаман да да калдың тере!

И мокатдәс, Анам теле –
Нидә бу телнең сере?
Латинлаштың, кириллләштең,
Алай да калдың тере!

И хурланган, Анам теле –
Телсезнең бармы иле?..
Урыслаштың, кырыслаштың,
Шулай да калдың тере!

И каргалган, Анам теле –
Йөрәк парәмнең түре:
Үгиләштең, сырхауладың....
Барыбер калдың тере!

И кадерсез, Анам теле –
Юк синдәй телнең тиңе!
Бугазлаштың, нык тырмаштың,
Үлемнән калдың тере!

Октябрь, 1997.

Саттык

Кеше сатмас кеше тапмак асатмы,
Сине соң кайсы дус
дошманга сатмый?
Г.Тукай.

Исәрлеккә ис-акыл китәрлек:
Акыл затын "шыр исәр" дип таптык...
Иблисләрнең җырын җырлап кына,
Намусны да фатирга без саттык.

Уяулардан уяу булып һәрчак,
Күрсәтеп без гел "сәяси саклык",
Ана сөте белән сугарылган
Җандай газиз телгә кадәр саттык.

"Бәйнәлмиләл" көен көйләп кенә,
Чиләкнекен иләккә дә тактык...
"Дуслар чәчеп, дуслар җыеп", кайчак
"Карьера"га дусларны да саттык.

Чүлмәкчедән күрмәкче күреп,
Дегет итеп каралттык да аттык.
"Халык" белән "хаклык"ны аермый,
Жалу язып, әләкләп тә саттык...

"Стратег"лык кына күрсәтү аз,
Өстәвенә, булдык бик зур "тактик"!
Бүрәнәне бүре күреп, каһәр,
Үзебезне бүреләргә саттык.

Үзебезне белешмичә, беркөн
Гаҗәпсенеп, хәйран нык шаккаттык:
"Кайдан килә, анасын саткыры,
Кайдан килә бездәге бу сатлык?"

Кыңгыр эштә – кырык елдан соң да –
Санамый бит беркем үзен "сатлык"...
Ни өчен соң, "кгбшник"лардай,
Милләт кадәр милләтне без саттык?!

Октябрь, 1979.

Баен бай ул...

Баен бай ул Рәсәй... Урысы,
Ә урысы аның, әйт, баймы?
Чабатасын салганы кайчан,
Шуны искә алганың бармы?..

Баен бай ул Рәсәй анысы,
Тик "миллионер" кайсы урысы?
"Бердәм Русь" дип масаю белән,
Бердәмме соң анда барысы?!

Баен бай син, Рәсәй, ярыйсы...
Колонияләрең барында.
"Бүленмәс һәм бердәм Рәсәй"дә
Талкан кебек таркау бары да.

Баен бай ул. Урыс соң баймы,
Бу турыда уйланган бармы?
Әгәр төптән уйлап карасаң,
Күбенең бар чыкмаган җаны!

Баен бай ул... Урыс ник ярлы?
Сөреп чәчәр җирләре тармы?!
"Бөек Русь"ның "бөек"лек даны
Тик талауга корылган бары.

Баен бай ул Рәсәй, үзе тик
Кырыкмаса кырык ямаулы.
Бөтеймәс һич, котаймас Русь,
Коллык белән өзми араны.

Март, 1985.

Дуслыкка үгет

Әйдәгез, дус яшик:
Юк-барга телләшмик,
Телләрне озайтып,
Әрләшмик, тешләшмик.

Әйдәгез, дус яшик:
Һавалы сөйләшмик,
Күркәдәй кабарып,
Энәле сүз дәшмик.

Әйдәгез, дус яшик:
Тискәре эндәшмик,
Кул сузыйк дуслыкка,
Вакланмыйк, көнләшмик!

Әйдәгез, дус яшик:
Яхшылык өләшик,
Дуслык – тау күчерә,
Дус өчен көрәшик.

Әйдәгез дус яшик!

Апрель, 1986.

Без — бар!

Бөек Болгарның
1100 ел элек
Олуг иман китерү
шәрәфенә

Мең ел узгач, әйтте азан Болгар:
– Кыяметтән терек калган кем бар?
Утта янмас, суда батмас ирләр –
Колгалиләр аваз салды:
– Без бар!

Мең ел кичкәч, телгә килде Болгар:
– Мең үлемнән исән калган кем бар?
Кабер ташлар чиркәү асларыннан,
Нәгърә орып, кычкырдылар:
– Без бар!

Мең елдан соң аваз салды Болгар:
– Бармы минем дан тотар ир-уллар?
Кол булмыйча калган каһарманнар –
Колшәрифләр кычкырдылар:
– Без бар!
– Без бар!!
– Без бар!!!

Июнь, 1989.

* * *

Сагындыра яшьлек урманнарым,
Хыялымда янган учакларй,
Горбәтлектә яшәп картайсам да,
Туган якта калган яшь чаклар.

Сагындыра яшьлек болыннарым,
Сандугачлар һәм бүз тургайлар...
Сабан туйларында көч сынаткан,
Курай тарткан җәйләү-тугайлар.

Сагындыра яшьлек чишмәләрем,
Тәпи-тәпи каз көткән чаклар.
Яшьлегемә чабып кайтыр идем,
Исән булса мин менгән атлар.

Сагындыра яшьлек сукмакларым,
Сагындыра бик күп яшьтәшләр.
Сагындыра сагынмаганнар да,
Сау булыгыз, газиз якташлар!

Август, 1997.
Кырым.
Симферополь шәһәре.

(Ахыры. Башы 6 нчы биттә).

кере белән кызыксынырга оныттыгыз. Әйе, шулай булмаса, бүре, куып тоткан куянынан аны ашарга рөхсәт сораган кебек булыр иде. Бүре принципларын хөрмәт итеп, алар "инородецларга", хәтта империянең ике башлы каракош сурәте төшерелгән яңа паспорты нинди булырга тиешлеге турында хәбәр дә итеп тормадылар. Империянең ике башлы каракошы һәм Георгий – Победоностәкыйльлеккә омтылган төрле халык вәкилләрен сез, шовинистлар, юкка гына "россияннар" дип атыйсыз. Дөресен әйткәндә, Русиянең бөтен бәла-казалары әлеге дә баягы шул "инородецларны" ихтирам итмәгәннән килә. Бернинди империя дә тарих чытырманлыкларын исәнимин кичә алмаячак, чөнки анда буйсындырылган халыклар үзләре теләгән азатлыкка ирешә алмыйча яшиләр. Шартлы рәвештә әйтсәк, Русиянең гайре табигый ассимиляция үткән һәр гражданы нәсел-нәсәпсез "россиянга" әйләнә калса, мондый юл белән туган катнаш канлы буенча, резервтагы көч булачак, гомумкешелек материясен тулыландыра.

Шуңа күрә, милләтләрнең иминлеге һәм мөстәкыйль үсеше (үз холкы, психикасы, биологик билгеләре, мәдәнияте һ.б. белән) – Кешенең табигый балансын саклау дигән сүз. Бәлки, бу әле бөтен Галәм өчен бердәнбер шундый милләттер. Менә шуның өчен дә көч куллану, табигый балансны максатчан җимерү – табигать, кешелек дөньясы һәм Аллаһы тәгалә каршында кичерелмәс җинаять. Кешелекнең табигый балансын җимерү, асылда, масштабы ягыннан Җирдә аның Конститутциясенә төкереп карарга рөхсәт итсә; аның киләчәктә матур яшәү турындагы хыяллары бер тиенгә дә тормый. Әйтик, суверенитет игълан ителүгә 7 ел тулуга карамастан, ни өчен Татарстанда гражданлык турында Закон юк? Кая Татарстан гражданнарының үз паспортлары? Русиядә яшәгән татарлар, Татарстан паспортын алып, Русия гражданлыгына үз мөнәсәбәтләрен белдерә алалар бит. Русия территориясендә Татарстан паспортын күрсәтү бу кешенең Русия гражданымы, түгелме икәнен ачык аңлата. Республикабыз паспорты, Русиянеке белән бер дәрәҗәдә, Русиядә

Өстебезгә ике башлы аждаһа килә

сецка колларның милләте кирәк түгел.

Сез, шовинистлар, Русияне һәрвакыт Америка белән чагыштырырга яратасыз. Сезгә мәгълүм түгелмени соң – буйсындырылган дәүләтләр АКШ субъектлары түгел һәм андагы берләштерелгән милләтләр арасында чичән, татар, башкорт, чуаш һ.б. халыклар кебек, үз ватаннарында гомер итеп, милли изүдән азат булырга омтылган милләтләр юк. Индеецлар – Американың төп халкы, мәгълүм буганча, Америка континентына көчеп урнашкан кешеләр белән беркайчан да килешә алмады. Башка америкалылар, туган илләрен дөньяның төрле континентларында калдырып килеп, үз ихтыярлары белән берләштеләр һәм халыклары, психологияләре, үз-үзләрен тотышлары, уй-хыяллары белән башка бер халыкка да охшамаган америка халкын хасил иттеләр. Алар милли изелүдән котылу хыялы белән янмыйлар.. Кушма Штатларга охшарга тырышып, мөсявыз затлардан торган ил бөек тә, шовинистлар күрергә теләгән "бөек урыс халкы" да була алмаячак. Шулай булгач, шовинизм чиреннән тизрәк дәвалану лазем. Тагын да шуны аңлау мөһим: табигатьтән дә акыллырак булу мөмкин түгел – мең еллар дәвамында барлыкка килгән төрледән-төрле халыкларга үзләренә генә хас энергия белән, бергәләп кешелек дөньясын гармонияле рәвештә тәрәккый итү өчен шовинизмнан арынырга кирәк. Халыкларның табигать тарафыннан бирелгән үзенчәлекләре кешелекнең биологик энергиясен акыл белән алга карап туплау һәм бүлешү өчен мөмкинлек тудыра. Һәр тере зат – homo sapiens – кеше – табигатьнең акылга ия булган җимеше (бәлки, ул Галәмнең яшерен коды белән тудырылгандыр!), һәм бу специфик энергия кешелекне буыннан-буынга сәламәтләндерү, чистарту процесслары өчен кирәктер. Үзенчәлекле милли энергия, кирәк чакта, табигый акыл чакыруы килеп чыккан барлык һәлакәтләр белән чагыштырганда да бик күпкә зуррак. Шуңа күрә дә, милләтчеләр дип аталучылар (алар табигатьнең табигый сакланып калуы яклы), мәсьәләнең тирәнлеген тулысы белән аңлаган хәлдә, бөтен нормаль фикер йөртүче кешеләрне Югары Акыл чакыруына колак салырга һәм шовинистларны җимергеч эшчәнлекләреннән ваз кичәргә мәҗбүр итәргә өндиләр.

Монда әйтелгәннәргә нәтиҗә ясасак, милли мәсьәләләрдә империячел эшчәнлек алып баручыларга ярдәм итү барлык намуслы кешеләр тарафыннан тәнкыйтьләнергә тиеш. Шул уңайдан Татарстан гражданнары җирле хакимият органнарын алдан ук кисәтеп куярга тиешләр: алар, бернинди хәлләргә карамастан, халыкның мөстәкыйль тәрәккый итүгә булган ихтыяры һәм республиканың бәйсезлеге белән сату итәргә тиеш түгел. Ә инде халык үз ихтыярын сәясәтчеләренә аяк астына салырга, Татарстанның референдум аша ирешелгән бәйсезлегенә, дә, аннан читтә дә гамәлдә йөрер. Ә Русия татарларны һәм башка милләтләрне кимсетә торган ике башлы каракошны тугра сыйфатында сакласа, теләгән халыклар алсыннар, әмма Татарстан территориясеннән читтә... Башка милли республикалар һәм милли дәүләт төшкил итүче субъектлар, Русиянең "инородецларны" кимсетүенә бер караштa булырлар дип өметләнәбез. Бәлки, әле урыс өлкәләре дә безгә карата булган бу ихтирам итмәү, әдәпсезлекне безнең шикелле үк кабул итәрләр. Русия үз территориясендә Русия паспортларыннан баш тарткан суверен республикаларның паспортлары йөрүен тыя алмый, чөнки, шулай була калса, "Федерация" дип аталган дәүләтнең җимерелүе бар.

Татарстан гражданлыгы турындагы Законны кабул итү процессын беркем дә, бернәрсә дә туктата алмас. Татарстанлыларның үз паспортлары булыр. Чөнки халыкның мондый хокукка хакы бар һәм ул күптән аның тормышка ашырылуын көтә.

Җ атарны моң яшәтә

"Җидегән чишмә"
диеп кем җырлаган,
"Җидегән чишмә"
диеп кем язган?!

Мәңге сарыкмый торган чишмәләр бар. Аларның көмеш чыңы, татлы суы тереклекне-кешеләрне сугара, җанга-тәнгә шифа бирә.

Чишмәләр... Иҗат чишмәләре дә шулай түгелме?! Менә алар – "Җидегән чишмә"ләре белән дә тагын бер танылган кадерлеләребез – Сара апа Садыйкова, Гомәр ага Бәширов, Зөһрә ханым Сәхәбиева. Әле генә шуларның берсе – Гомәр ага 97 яшен тутырды. Сөбханалла! Бәхетле язмышлы җырлар буыннарны ялгый, килер елларга өмет уята...

Әйдәгез, Яңа елның җомга иртәсендә җидегән чишмәләрнең суы белән күңелләрне янә, бер сафландырыйк әле. Сара апаны да тагын бер искә алыйк. Бу яңа елда башкалабыз Казанда аның иҗатын, рухын-тормышын барлаган-туплаган музее булу бәхетенә ирешә алсак иде. "Җидегән чишмә"ләрне җырлап-тыңлап яшәгән, җидегән йолдызлар яктысында туганнарның һәм, гомумән, милләтебезнең изге теләге бу. Еллар – елга, буыннар – буынга, язмышлар язмышка шул рәвешле тоташа түгелме?!

Әзһәр ХӨСӘЕНОВ,
Сара Садыйкованың
иҗтимагый фонды рәисе.

Ө стәлдә ак кәгазь...

Фәүзия БӘЙРӘМОВА,
язучы, "Иттифак" фиркасе рәисе:

– Үткән елда китап киштәсендә кечкенә генә яңа китабым пәйда булды – "Кара урман" романы. Шушында нокта куярга да булыр иде, әмма өстәлемдәге тау-тау язылган кәгазь өеме, берничә китапның инде әзер корректуралары телгә килә, ел буена эшләнгән эшләр, язылган әсәрләр җанлана, күңелдә хәрәкәт итә башлый...

Язучының төп эше, әлбәттә, әдәби әсәрләр язу, ара-тирә ул, иҗтимагый тормышка катнашып, мәкаләләр дә язып ташларга мөмкин. Әмма сәясәтчеязучының төп эш урыны – язу өстәле генә түгел, төп жанры – әдәби әсәрләр генә түгел, төп вакыты иҗатка гына бирелми шул. "Шул" дип, кызганып әйтергә дә мәҗбүрмен, чөнки роман-повестьлар язарга тиешле алтын вакытымны бүлеп, үткән ел да сайлау алды программалары эшләнгән, дистәләгән сәяси белдерүләр, карарлар, резолюцияләр, милләт һәм дәүләт тормышына кагылышлы күп кенә мәкаләләр язылган, халыкара корылтайларда, конгрессларда чыгышлар ясалган һәм туктаусыз юлда, юлда булынган...

Үткән ел минем өчен тагы сайлаулар елы булды, Тукай районының 90га якын авылын үз аякларым белән йөреп чыктым, тагы бер тапкыр милләт фаҗигасен һәм үз фаҗигамне күрдем, кичердем. Болары – "Тиран" романына материал, болары инде өлешчә кәгазьгә күчә дә бара... Моннан тыш, ике тапкыр Төркиядә зур халыкара корылтайларда катнашып, чыгышлар ясалган, Милли Мәҗлес һәм "Иттифак" партиясенең корылтайларын үткәрү минем өстә һәм җаваплылыкта булган, II Бөтендөнья татарларының конгрессында катнашып, чыгыш ясалган, Мәскәүдә һәм Казанда имам Шамилнең 200 еллык юбилее уңаеннан конференцияләрдә катнашып, махсус докладлар укылган, Ислам җыеннарында дистәләгән чыгышлар ясалган, шул максаттан Казан, Түбән Кама, Әлмәт, Алабуга, Минзәлә, Чаллы шәһәрләрендә берничә тапкыр халык белән зур очрашулар үткәрелгән... Болары – инде җыелып беткән, өстәлемдә әзер корректура булып яткан "Дәверләр кучешендә" китабыма материал булып кергән, иншаллаһ, ул якын арада укучы кулына килеп тә керер.

Өстәлемдәге өченче китапның корректурасы – "Коръән сүрәләре..." Аңа да минем күз нурларым сеңгән, күңел җылым кергән, күп вакытым һәм гакылым сарыф ителгән.

Кулымда инде әзер кечкенә генә китапчык – ул "Иттифак" партиясе кичә, бүген, иртәгә" дип атала. Шул партиянең җитәкчесе буларак, милләт һәм дәүләт өчен барган көрәшне документларда чагылдырган китап итеп чыгаруны без кирәк дип таптык. Бирегә дә мин үз кулларым белән язган күп кенә сәяси документлар тупланган.

Әйткәнемчә, үткән ел үз хисабыма "Кара урман" романын китап итеп бастырып чыгара алдым. Хәзер инде аның дәвамын сорыйлар. Аллаһы Тәгалә гомер һәм сәламәтлек бирсә, анысы да булыр, иншаллаһ! Бу хакта материалым күп, әйтер сүзем бар.

Кызганычка, "Безне онытмагыз" дип аталган пьесалар җыентыгым Татарстан китап нәшриятында басылып чыгарга тиеш булса да, нигәдер дөнья күрмәде.

Шулай итеп, ел үтеп тә киткән... Күңелдә һаман кара урманнар шаулый, татар милләтчесе һаман ирек даулый, гавам дәверләр капкасы каршында басып тора...

Бер олау печән һәм скрипка

Башкалабызның Ирек мәйданында урнашкан Зур концерт залында узган ел ахырында Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Казан дәүләт консерваториясе профессоры, танылган скрипкачы Марат ӘХМӘТОВның 60 яшьлегенә багышланган иҗат кичәсе булып узды. Шул уңайдан без филология фәннәре докторы Илбарис НАДИРОВның маэстро белән әңгәмәсен тәкъдим итәбез.

– Татарстан җирендә генә түгел, читтәге байтак шәһәрләрдә һәм кайбер ерак илләрдә дә Сезне татар халкының күренекле скрипкачысы буларак беләләр, хөрмәт итәләр. Искә төшерегез әле, Сез беренче кат скрипка дигән назлы, нечкә һәм бик сирәкләргә генә буйсына торган бу уен коралын кайчан кулга алдыгыз?

– Бу хәл минем бала чагымда булды. Өебездәге шкаф башында бер скрипка ята иде. Бервакыт мин аны алдым да, әтием янына килеп кызыксына башладым. Әтием шунда ул скрипка тарихын сөйләде. Скрипка бабамнан калган икән. Ул аны әтиемә дип Мәләкәс базарыннан алган булган. Аны алыр өчен бер олау печән сатып акча юнәткән. Үсмер вакытында әтием үзлегеннән скрипкада уйнарга өйрәнгән һәм үзенең туган авылы – биш мәчетле Татар Урайкинында бердәнбер скрипкачы булып саналган. Әмма соңыннан Казанга күчеп килгәч, скрипкада уйнарга форсат калмаган. Шулай итеп, ул скрипка безнең гаиләнең бер ядкаре булып ята биргән. Скрипкага күзем генә түгел, күңелем дә төшкәнен сизеп алгач, әтием дә, әнием дә мине Казанның 1 нче музыка мәктәбендә укытырга карар кылалар. Бу – Бөек Ватан сугышының ахыргы елы иде. Хәтеремдә шул ерак елның бер хатирәсе саклана. Мәктәпнең 1 нче сыйныфында укыганда мине башка балалар белән бергә үзәк трампарк каршындагы хәрби госпитальгә концерт куярга алып бардылар. Шунда мин беренче кат скрипкада чыгыш ясадым. Аягы яралы бер өлкән солдатның мине янына чакыруы, башымнан сыйпавы, күз яшьләрен сөртә-сөртә тумбочкасыннан шикәр кисәге чыгарып миңа бирүе бүгенгедәй хәтеремдә. Ул чакта миңа җиде яшь иде.

– Зур концерт залында узган истәлекле иҗат кичәгездә Сез газиз әниегез Сабира апа рухына багышлап гаҗәеп самими һәм җылы сүзләр әйткән идегез. Сезнең ул сүзләрегезне залдагы халык алкышлап хуплады. Тагын шунысы да истә калды: ул сүзләр саф татар телендә яңгырады. Туган телебезгә шундый ихлас мәхәббәт каян килә?

– Минем күңелемдә туган телгә мәхәббәт хисе әнием сурәте белән тыгыз үрелгән. Чөнки әнием дә, әтием дә татар җанлы кешеләр иде. Урыннары оҗмахта булсын. Безнең өйдә татар телендә сөйләшү, татар музыкасы тыңлау гадәти бер хәл иде. Әтиемнең дуслары арасында Фәтхи Бурнаш, Заһид Хәбибуллин, Мансур Мозаффаров кебек язучылар, композиторлар бар иде. Мин аларның безнең өйгә килеп дустанә сөйләшеп утырганнарын яхшы хәтерлим. Сез искә алган иҗат кичәмдә иң әүвәл композитор Альберт Леманның скрипка һәм оркестр өчен язылган Беренче татар концерты яңгырады. Аның музыкасына нәфис булып милли моңнар тукылган. Бу концертның башкарылу тарихы минем иҗат биографиям һәм әнием сурәте белән тыгыз бәйләнгән. Музыка училищесын тәмамлагач, мин Казан консерваториясендә укый башладым. Тегендә дә, монда да скрипка буенча укытучым Натан Брауде иде. Консерваториянең 1 курсында чакта (1956) ул миңа А.Леманның әле яңа гына язылган концерты турында сөйләп, шуны өйрәнергә кушкан иде. Тик ул вакытта бу концерт әле ноталарда басылмаган иде. Автор кулъязмасыннан миңа аны әнием күчереп алды. Бу катлаулы, нечкә эшне башкарып чыгу әниемә җиңел булмагандыр. Белеме буенча ул бит инженер иде. Мин концертны әнием кулы белән язылган шул күчермә буенча өйрәндем һәм 1957 елның җәендә Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы көннәрендә Бөтенсоюз радиосының зур симфоник оркестры белән скрипкада башкаручы солист булдым. Ул көннәрдә матбугат битләрендә минем уенымны яшь музыкантның көтелмәгән уңышы һәм казанышы дип мактап яздылар. Хәтерлим, декада вакытында мине, танышыр өчен дип, Мәскәү консерваториясенә чакырдылар. Очрашуда танылган профессорлар Давид Ойстрах, Леонид Коганнар да бар иде. Аларга кайбер әсәрләрне уйнап күрсәттем. Мактадылар, хупладылар. Казанда укуларым тәмамлану белән Мәскәү консерваториясенең аспирантурасына юлым ачык булуын да әйттеләр. 1961-1964 елларда мин, чыннан да, ул аспирантураны уңышлы тәмамлап чыктым. Җитәкчем Русиянең танылган музыканты профессор Дмитрий Цыганов иде.

Шулай итеп әнием кулы белән күчереп язылган А.Леман концерты минем язмышымда зур урын тота. Иҗат кичәмдә уенымны алкышлар белән каршы алгач, сөекле әниемнең якты истәлегенә багышлап татар телендә рәхмәт хисләремне әйтми түзә алмадым.

– Мәскәүдә аспирантура тәмамлап кайткач, Сез утыз елдан артык инде Казан консерваториясендә укытучысы булып эшлисез. Шул еллар дәвамында шактый шәкертләр тәрбияләгән һәм профессор дәрәҗәсенә ирешкән тәҗрибәле, мактаулы педагог саналасыз. Гомер юлыгызга билгеле бер йомгак ясаган бу көннәрдә яраткан эшегез, укучыларыгыз турында тәфсиллерәк сөйләсәгез иде.

– Скрипка буенча миндә укып чыккан студентлар йөзләгән. Аларның берәүләре музыкантлар булып оркестрларда, театрларда, икенчеләре укытучылар булып мәктәпләрдә эшлиләр. Араларында Русия өлкәләрендә, Урта Азия якларында, Мәскәү, Санкт-Петербург шәһәрләрендә генә түгел, Германия, Америка, Израиль, хәтта Бразилия кебек ерак илләрдә гомер итүче музыкантлар да бар.

Дөрестән дә, минем бөтен гомер юлым Казан консерваториясе белән бәйләнгән. 4 нче курста чакта мин үзем белән бергә укучы Лариса исемле кызга өйләндем. Ул да хәзер консерваториядә эшли, татар музыкасы буенча диссертация яклады, татар мәктәпләре өчен музыка дәреслекләре язды. Шунысын да әйтим, Лариса минем гомер юлымда ышанычлы юлдаш, гаилә учагын җылы итеп тотучы таянычым булды. Хәзерге вакытта татар этнографиясе буенча белгеч булып эшләүче улыбыз Рөстәм, онысыбыз Тимур шуңа ачык дәлил дип уйлыйм.

Сүземне яңадан консерваториягә күчерим. Баштарак мин анда дәресләремне гел урыс телендә алып бара идем. Соңгы елларда исә татар студентларына дәресләрне татарча бирәм. Бу хәлгә алар баштарак сәерсенеп карасалар да, соңыннан күнектеләр. Татар теленә мәхәббәт белән караганымны белгән урыс студентлары да минем белән кайвакыт матур итеп татарча исәнләшәләр.

– Белүемчә, Сез Казанда соңгы вакытта ачылган татар музыка мәктәбендә дә дәресләр алып барасыз?

– Әйе, ул мәктәп 1993 елда ачылган иде. Анда барлык дәресләр дә туган телебездә алып барыла. Күптән түгел мин анда 4 нче сыйныфта укучым Алия Габидуллинаның соло концертын уздырдым. Ул анда кырым татар композиторы Назыйм Амедовның балалар өчен язылган сюитасын башкарды. Концерт күркәм булды, соңыннан аның турында газитләрдә яздылар, телевидениедән тапшыру эшләделәр. Бу музыка мәктәбе үрнәгендә татарча белем бирүче яңа мәктәпләр дә булыр әле дип өметләнәсе килә.

– Марат әфәнде, Сез скрипканың сихри серләрен, тылсым көчен һәм нәзберек табигатен тоя торган музыкант, алай гына түгел, Сез – виртуоз. Шуңадыр, Сезне Татарстаннан тыш та әйбәт беләләр. Ничәмә еллар дәвамында йөзләгән гастрольләрдә булдыгыз. Шулар турында да бераз сөйләгез әле?

– Консерваториядәге төп эшемнән бушаган араларда миңа Татарстан филармониясе артистлары белән төрле концертларда катнашырга туры килә. Мин Ташкент, Алматы, Новосибирски, Әстерхан һ.б. шәһәрләрдә гастрольләрдә булып, тамашачыларга Көнбатыш һәм татар музыкасының классик әсәрләрен уйнадым.

Гастрольләрнең аеруча истәлеклесе, әлбәттә, Финляндия белән бәйле. Миңа анда ике мәртәбә – 1968 һәм 1977 елларда бару насыйп булды. Безне – бертөркем сәнгать осталарын Финляндиягә Габдулла Тукай исемендәге җәмгыять президенты профессор Гомәр Таһир чакырган иде. Баручылар арасында Рөстәм Яхин, Илһам Шакиров кебек бөекләребез дә бар иде. Үз вакытында Сез, Илбарис ага, безнең ул гастрольләр, гомумән, Финляндия татарлары турында мәкаләләр дә яздыгыз. Дөрестән дә, ярты гасырдан артык гомер дәвамында бер генә чит илгә дә аяк басмаган татар артистларының Финляндия җиренә барып концертлар бирүе бик тә күркәм бер вакыйга булды. Чит илдә яшәсәләр дә, үзләренең туган телләрен, гореф-гадәтләрен онытмыйча бердәм булып гомер итүче тырыш милләттәшләребезне күреп сокланган идек. Безнең милли концертларны анда таң калып, яратып карадылар. Финляндиягә икенче мәртәбә барганда, төп концерттан тыш, без пианист Марат Сираҗетдинов белән Сибелиус исемендәге музыка академиясендә профессорлар һәм студентлар өчен аерым бер концерт оештырдык. Анда без татар композиторларының киң билгеле инструменталь әсәрләрен башкардык. Академиянең безнең концертыбызга югары бәя биргән рәхмәт хатын мин бүген дә кадерләп саклыйм.

Чит илләр белән бәйләнешләр җәһәтеннән караганда, узган 1997 ел бигрәк тә истәлекле булды. Без Татарстанның атказанган артисты, танылган пианист һәм дирижер Тәлгат Әхмәтов белән (ул минем бертуган энем) өч мәртәбә Германиядә булдык. Төньяк Германиянең алты шәһәрендә концертлар бирдек. Соңгы баруыбыз декабрьнең икенче яртысына туры килде. Андагы концертларны оештыру эшен Марта ханым Фрицберг башкарды. Ул үзенең дусты белән Казанга – минем иҗат кичәмә дә килгән иде. Германия шәһәрләрендә без Бах, Шуберт, Венявский, Рахманинов һәм Фәрит Яруллин, Рөстәм Яхин, Заһид Хәбибуллин әсәрләрен уйнадык. Немесләр татар музыкасын бик яраталар. Безнең өчен алар белән аралашу ул кадәр кыен булмады, чөнки мин нимес телендә иркен генә сөйләшәм. Бер нәрсә истә калды: беренче баруыбызда безне Русия музыкантлары дип каршы алганнар иде. Без үзебезнең мөстәкыйльлек юлыннан баручы Татарстаннан килүебезне аңлаткач, икенче-өченче концертларыбыз афишаларында "Татарстан музыкантлары" дип яздылар.

– Минем Сезне берничә мәртәбә онысыгыз Тимур белән күргәнем бар. Катнаш никахтан туган малай булса да, ул рәхәтләнеп татарча сөйләшә. Үзебезнең телдә сөйләшергә аны Сез өйрәттегезме?

– Әйе. Тимурга хәзер 16 яшь. Ул кечкенәдән үк татар музыкасы тыңлап, татар әкиятләре укып үсте. Мин аның туган халкыбызга хезмәт итәрдәй татар егете булып үсүен бик теләр идем.

● Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, профессор Марат Әхмәтов.



Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗев – гаять дәрәҗәдә талантлы язучы. Көнe төне эшләде, эшли, күп санлы повестьлар һәм романнар, 30дан артык пьеса авторы. Үз каләмдәшләре хакында тирән эчтәлекле мәкаләләр язды. Мөхәммәт Мәһдиевнең иҗатын аннан да зуррак итеп ачып биргән әдип юк.

Менә бу көннәрдә ул, минем каләмдәшем, гомер юлының тагын бер баскычыннан атлап менә. Татар әдәбиятында Әмирхан Еникиләр, Гомәр Бәшировлар, Ибраһим Газилар, Мирсәй Әмирләр, Габдрахман Әпсәләмовлар кебек өлкән осталар буыны бар иде. Безнең буын, сугыштан соң мәйданга килгән буын – шул өлкәннәрнең традицияләрен дәвам иттерә. Аяз – шуларның беренчесе...

Гариф АХУНОВ.

буенча тулып ята, шулай да малайларның күзе амбар тирәсендә... Айбагырның үзе түгел, шуны чәлдерергә маташу дәмәк!.. Амбар артыннан шыпан-шыпан чыгып кесәләргә айбагыр тутыра башлаган гына идек, тап-таза Югары оч егете Мәндәй Ибаны якадан эләктермәсенме?! Яра инде дип торганда, Ибан минем кем малае булуымны белгәч йомшады, кесәмә айбагырны шыплап үзе тутырды...

Озын кышларны кая да чыгып йөрмибез, Багражда үткәрәбез, язгы-җәйге бәйрәмнәргә – җыенга, Сабан туена без Сарман, Әхмәт якларына кайта торган идек. Хуш исле йомшак печән түшәлгән тарантаска гаилә белән төялеп, мәктәп атын җай белән генә атлатып егерме чакрымны – Сарман-Баграж арасын үтүләр татлы төш булып истә калды... Завод үрен менгәч юл урман кырыннан үтә, ә анда җир җиләге кып-кызыл келәм булып, кызыктырып, җанландырып безне күтәп ала торган иде. Табигатьне олылау, аны изге санап баш ору безнең заман кешеләрендә үтә көчле

Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ, Татарстанның халык язучысы

Балачак

1.

Әле бүген дә, алтмыш яшьне үтеп, ашыга-ашыга җитмешкә тәгәрәгәндә дә, мин җәяүле сукмакларга тыныч кына карый алмыйм. Олы юлларны аркылы-торкылы кисеп үткән гап-гади сукмаклар миндә татлы хисләр, җылы тойгылар уяталар. Кая гына барсам да – поездддамы, автобустамы – мин ихтыярсыз тәрәзәгә ябырылам, уңга, сулга, урман ешлыкларына, әрәмәләрнең сихри кочагына кереп киткән сукмакларга карап хыял дөньясына чумам. Шушы, меңнәрчә адымнар белән такырланган, инеш-күл буйларын чәлмәп ураган, кыр-урманнарның серле дөньясы аша үткәрүче, зарыктыручы, кавыштыручы уравыч тар юллардан дөньяның иң бәхетле адәмнәре йөридер дип фараз кылам. Әнә алар, кабаланмыйча, бер-берсен очлы терсәкләре белән борчымыйча, дөньяның кабатланмас гүзәллеген туя карап, зәп-зәңгәр күк, ямь-яшел җир белән аңлаша-аңлаша, болын, урман чәчәкләренең куе исенә кинәнеп бәхет диңгезендә йөзәләрдер төсле.

Бәләкәй чакта сукмаклар синеке! Ялан тәпи тып-тып басып дөнья белән танышу әнә шул җәяүле сукмаклардан башлана. Кая карасаң да сине ят, яңа урыннар көтә, уңда-сулда ят ярлар, моңарчы син күрмәгән, күрә дә алмаган сер дөньясы.

Балачак хатирәләре – әкрен аккан, өзек-өзек ак болыт кебек, истәлекләр бер-беренә ялганмыйлар, әллә кайда, шул серле сукмакларда уралып, еракта, томанлы офыклар артында тынып калган вакыйгалар һичкайчан да бер-беренә чылбырдай тоташа алмыйлар. Алсу шәүлә дә кебек алар, таңда яңгыраган сак җыр да сымак, кайчан булып үткәннәрен өзеп әйтеп тә булмый. Балачак хәсрәтне белми, ә вакыт белән янәшә яшәү хәсрәт килгән көннән генә башлана...

Тәңремә рәхмәтлемен: ул мине туганда ук шигъри күңелле иткән. Шулай уйлыйм. Хәтергә нык сеңеп калган вакыйгалар шуны сөйли.

Җәйләрнең берсендә әнием ындыр түрендәге кыяр түтәлләре арасына барып кергән. Мин, терсәкләремә таянып, артымны туңкайтып, борын очым белән җир сөреп, чәнти бармак кадәрле үскән кыяр малаен кимереп ятам икән... Әни соң дәрәҗәдә гаҗәпләнеп: "Улым, нигә кыярны ятып ашыйсың?" дип сораган. Мин, аллы-күкле янып: "Үзең өзмәскә куштың ич!" дип җавап биргәнмен, имеш. Җавабымны үзем хәтерләмим, әни сөйләвеннән исемдә калды, ул ышанып сөйләгәч, шул вакыйга балачагымның иң кадерле хатирәсе булып күңелемдә саклана.

Минем әтием тумышы белән Сарман кешесе, үз-үземне белә башлаганда без Югары Баграж дигән гүзәл керәшен авылында, нәкъ чиркәү каршысындагы пужумда, Әндрияң дәдәйләр өендә яши идек. Таза ихата, йорт-җир байларча биек итеп салынган, җәен салкынча, кышын зәмһәрир суыкларда да җылы була торган калын стеналы таш амбарны мин аерата ярата идем. Әндриян дәдәй балта остасы, аны Федоттагы ятим балалар йортына эшкә чакырып алганнар да, ул гаиләсе белән шунда яшәп ятканда, без алар өендә тордык. Минем татлы, кадерле балачак истәлекләрем Җир шарының шушы нәни ноктасы белән бәйләнгән. Каршыда, бакча эчендә чиркәү, уңда мәктәп бинаoлары, мәктәп каршысындагы киң генә мәйдан миңа – шактый елгыр малайга – яшәү серләрен ачып биргән кадерле урыннар иде.

Әндриян дәдәйләр бакчасы кояшка таба авыш, ул сөзәкләнеп ындыр артыннан үткән Метри елгасына төшә. Язын әз-мәз сулы, ташу кузгалганда ике-өч көн дулап агып, җәйге чиләдә кибеп корый торган Метри ярында әти яшелчә бакчасы ясады. Яфракларыннан татлы ис таратып утыручы юаш карлыган куаклары да шунда тезелде. Кыяр, кишер, чөгендер, помидорлар янәшәсендә Югары авыл өчен ятрак булган кавын-карбызлар тәгәрәп үсте. Кунак-мазар килгәндә әти аларны чәй эчкәнче үк бакчасына алып төшә иде. Әти урта мәктәптә химия, биология укыта – иртә-кич бакчада казынырга нык ярата иде.

Соңгы сигез гасыр эчендә дөньяда табигатьнең иң мәрхәмәтле еллары утызынчы белән кырыгынчы еллар арасына туры килгән. Җир сирәк тетрәгән, зилзиләләр сирәгәйгән, янар таулар яман утларын сак түкергәннәр, җәйләр җылы, мәрхәмәтле, шәфкатьле булган. Утызынчы-кырыгынчы – минем бәхетле балачагымның еллары! Мин хәзерге әле коры, әле яңгырга тоташ манчылган җәйләрне ул бәрәкәтле еллар белән чагыштырып карыйм һәм хәзерге заман балаларын уйлап күңелем сызлый... Җир мәрхәмәтле, сөйкемле еллары белән дә безне иркәләгән икән!

Агач чиркәү! Аның безнең тәрәзәләргә караган диварына, өскә үк, "1840" саны сугылган сары калай кадакланган. Без бәләкәй чакта Баграж чиркәве үзенең йөз еллыгын үткәргән икән. Мин чиркәүнең биек-биек, янындагы озын чыршылардан да биегрәк күтәрелгән хачларын, эчендәге алтынкөмешле бизәкләрен, диварларына эленгән тәреләрне, чигүле тәре алъяпкычларын яхшы хәтерлим. Утызынчы елларда авыл коммунистлары – Озын Микайла, тагын кемнәрдер, чиркәү хачларын кисеп, түбә калайларын изә-изә дөбердәтеп җиргә төшерделәр.

Чиркәүгә һәм Әндриян дәдәйләр өенә чапырышта, сул ягыбызда мәшһүр каравыл өе. Шунда ук янгын сарае, ат абзарлары, тутыккан кул насослары, коргаксыган мичкәләре, лапас өрлекләрен терәгән шома сөян баганаларга ыргак, багур, корымлы пумалалар асылган, дәү-дәү имән чөйләргә бөятләре ашалган камытлар, буяулары купкан дугалар, сүсәргән аркалык-түшлекләр, тәҗе баулары эленгән. Без – Урта һәм Аскы урам малайлары – бәхетле! Әниләрнең "замат арасында кайтасы бул, ыштубыты, ишетсен колагың!" диюләренә карамастан, әбәдтән соң гел шунда уралабыз. Мич арасыннан, аулактан урын алып калырга кирәк. Менә каравыл өенә карт-коры җыела башлый, кич-кырын, иплән кенә ирләр дә шунда тартыла. Алар вәкарь белән ашыкмыйча күрешәләр, озын итәкле чикмәннәрен, иске пинҗәкләрен чишеп җибәрәләр, чөлемнәрен кагып тәмәке тутыралар. Һәм, китә сүз! Ишек шар ачык булса да өй эче тиздән төтен белән тула, ләкин без кымшанмыйбыз, киресенчә, мич арасыннан башта елтыр танаулар күренә башлый, аннары баш күренә, муеннар сузыла. Ашау, өй, әнинең кисәтүләре истән чыга, кумасыннар гына!.. Кызык сүзләр, мәзәкләр, дәмәкләр шунда сөйләнә... Инде Багражның аталы сунарчылары Аксак Ибан белән Сәвәләй Питере дә килеп керсә... Бетте! Без төнгәчә аларның маҗараларын тыңларга әзер. Түтәл тәмәкесеннән төрелгән "кәҗә сыйраклары" чытыр-чытыр яна, йөз ел юылмаган тәрәзәләргә эңгер иңә, идән өстенә яңа керүчеләрнең алаптай чабаталарыннан туфрак коелып яңа катламнар ясала, ә безгә рәхәт. Керәшеннәр үтә сабыр, бер-берсенә итагатьле халык, ничә еллар яшәп багражлыларның үзара сугышканын, талашканын күргәнем, ишеткәнем булмады. Багражда олылар – олы, кечеләр – кече...

Кем, ничек кушкандыр, бер заман каравыл өе адәмнәре янына мин үз бакчабыздан бер кесә кыяр тутырып килдем. Бусын үзем дә ап-ачык хәтерлим!.. Дәү-дәү, көрәк сакаллы керәшен дәдәйләр мине кызык өчен генә кыяр урларга җибәргәннәрдер дип уйлыйм, борчак кузагы дәүмәлеге кыярларны күреп: "Ник мондый вакларын өздең?" дип сораганга, "олыракларын күтәреп булмый шул аның!" дип җавап бирдем. Үзем оялып, пешеп-янып идәнгә текәлдем һәм нәп-нәни кыярларны идән ярыгыннан берәм-берәм базга шудыра башладым.

Оялуымны, чәнти-чәнти кыярларымны, ирләрнең көлеп җибәрүләрен бүгенгедәй хәтерлим.

Авыл малаеның балачак хатирәләре кыяр-шалканнан башлана икән, моңа һич гаҗәпләнергә кирәкми. Авыл баласы үзенең эшчәнлеген, хезмәтен әнә шул бакча түтәлләреннән башлаган.

Әтиемнең Сарман тумасы икәнен әйткән идем инде, әнием Мөгаттәрә дә шул төбәк кызы, Сарманга терәлеп үк торган Югары Әхмәт авылында туып үскән. Әти Минзәләдә педучилищеда укый башлаган, әнием шунда ук кызлар мәктәбендә белем алган. Минзәләдә танышканнар алар, шунда кавышканнар. Әтине эшкә Чукмарлы авылына җибәрәләр, әни бер-бер артлы өч малай табып өйдә утыра. Әтине, яшь мөгаллим дип, район читендәге Югары Баграж авылына укытырга җибәрәләр, авыл Зәй районы карамагына күчкәч тә безнең гаилә Багражда калган. Минем балачагым, яшьлегем әнә шул авылда, юмарт күңелле, кунакчыл, гади, үтә кешелекле, риясызхәйләсез керәшеннәр арасында үтте. Олысы-кечесе безне хөрмәт итә иде. Көрәк сакаллы, абруйлы авыл агалары әниемне яратып, гади укытучы хатынын зурлап "апа" дип эндәшәләр, әллә каян, ерактан, бөгелә-сыгыла сәламләп китәләр иде. Әнием оста җөйче иде, Баграж сылуларына чуклы-чачаклы түшле, бәбәйтәкле күлмәкләр тегеп кигертә башлагач аның абруе тагын да үсте. Ата-ананың абруе авыл арасында малайларны да үсендереп җибәрә. Хәтеремдә, авыл уртасындагы мөгәҗи амбарына айбагыр кайтарып тутырдылар. Кояшлы көннәрнең берсендә айбагырны амбар алдындагы чыбылдыкларга чыгарып тараттылар. Керәшен авылында айбагыр йорт иде! Без, малайлар да, җиләкне алан читеннән, таптамыйча, берәмтекләп җыя идек. Башта "кызыл сандык"ка – авызга шудырасың, аннан берәр савытка, күчтәнәчкә җыя башлыйсың. Җир-су чиста, болытлардан көмештәй яңгыр ява, җир хәзинәсе җиләк-җимешләр әле саулык кына китерә!

Гаҗәп, бәләкәй чакта мин Сарман урамнарына калай җәелгән, ә Нөркәй дигән авыл кешеләре очлы түбәле брезент юрталарда яшиләр дип белә идем. Малай кеше аякка киеп торамыни? Күп кешеле Сарман урамнары нык тапталып, җәйге чилләләрдә көйдерерлек кызгандыр шул! Мин шулай дип хәзер генә, шушы хатирәләрне язган чакта юрадым. Ә нөркәйләрне ник брезент юрталарга күчергәнмендер, аңламыйм, бәлки этиләр белән Нөркәй авылын узып та киткәнмендер?

Исемдә, тәбәнәк кенә, йомры гына ике малай, әтинең бертуган абзыйсы Мәхүбрахман абыйның улы, яшьтәшем Максут белән алар капкасыннан ишегалдына кереп киләбез. Куллар артта, йөзләр җитди, авызлар йомык. Әниләр безгә карыйлар да башта... кычкырып көләләр! Ә аннан соң... куллары кычытканга үреләә. Тикшереп карасак, икебезнең дә түшләр сап-сары икән... Ни хикмәттер, дүрт яшьләрдә чакта икебез дә чи кукай эчәргә ярата торган идек. Гел-гел оясына менәргә әниләр рөхсәт итмәгәндер шул, ара-тирә күршеләрнең тавык ояларына да походка чыкканбыздыр... Шуны уйладым да мәшһүр шагыйребез Һади Такташның "Мокамай йомырка урлаган" дигән тәүге шигыренең юллары искә төшә. Һәр Мокамайның Әйшә тәтәе була: бәләкәй чакта татыган "кычыткан себерке"ләр ул чакта урлашмаска өйрәткән эче сабак була торган иде.

2.

Дүрт яшемдә идемме, әллә якты кояш астында бишенче җәемне үткәрә идемме, безнең авылда балалар бакчасы ачтылар. Аны "Площадка" дип атадылар. Урак өсте иде шикелле. Минем әни белән Югары очның Феона апа Васюкованы тәрбияче иттеләр. Үзләре ашчы, үзләре караучы, җыештыручы, кер юучы да иделәр. Шуның өстенә әни малай-кызларга пар җәйге киемнәр дә текте. Ул чаклар тагы рәхәтлекләр! Су коенырга йөрибез, авылга авып торган тау тезмәләре битләреннән җиләк җыябыз, олы малайларның ат коендырганын бергәләп карыйбыз. Мин атларга якын ук килергә куркам, читтән генә, сагаеп, яр буе таллары арасыннан карап торам. Ник дигәндә, бер заман әти белән мәктәпнең Аманат исемле атына утырып кайттык та, әти Аманатны тугарып җибәрде, мин

сукмаклары

сарай ишеген ачарга йөгердем. Анымоны искәрмичә барам, башын чайкый-чайкый артымнан фырлап килгән Аманат, кинәт җилкәмнән умырып алды да, мине алагаемга чайкап җибәрде. Акырып еларга тотындым, аркам канады, Аманат тешләренең эзе шактый вакыткача җөйләнеп торды. "Аткамы, бүтән хайваннаргамы, телең белән эндәшмичә бер чакта да алдына төшмә!" дип өйрәтте эти. Мин гомерем буе аның киңәшен тоттым, тик, ни хәл итәсең, йорт тирәсендәге мал-туарлар, кош-корт әтинең киңәшен белмәгәндер шул: үз гомеремдә мине өч тапкыр каз талады, дүрт-биш мәртәбә кәҗә тәкәсе сөзде, колхозның иң дәү ата дуңгызы төртеп екты, бер тапкыр Имәнле урамында ана күркә кычкыртып талады.

"Площадка"ның кайда, кем өендә урнашуы ныклап исемдә калмаган, мәгәр без Метри елгасы тирәсенә Каравыл почмагыннан Макар дәдәйләр, Ипис түтиләр ызанынннан төшеп йөри идек. Елга аръягында искиткеч матур, аллы-гөлле чәчәкләр каплаган бәләкәй генә болын бар иде. Иртә яздан кара көзгәчә чәчәкләр бер-бер артлы ачылалар да җәйнең һәр күләмендә болынның үзенә хас чәчкә исе була торган иде. Беркем кисәтмәсә дә болынга аяк баскан кеше кинәт үзгәрә, чәчәкләрне өзмәскә, үләннәрне таптамаска тырыша. Кай яктан җилләр иссә дә алар тыгыз һавалы бу үзәнгә төшеп җитә алмыйлар, көн туса без шул оҗмахта күбәләк куабыз, гөрләкачышлы уйныйбыз, әз-мәз таптап китсәк тә, без болыннан чыгуга үләннәр рәхәтләнеп турая торганнар иде. Еш кына болынга эштән бушаганда эти дә төшә, безне түгәрәкләп тирә-ягына утырта, ганҗәүләннәрнең исемен атап, берәмберәм күрсәтә башлый. "Безнең якларда ашарга яраган йөзләп үлән бар" дия иде.Ниләр генә җыеп ашамый идек без Баграж болын-урманнарыннан! Җиләк-җимешне, гөмбәләрне әйтеп тә тормыйм, язга чыгып кар китүгә кояшка караган ермак ярларына сап-сары булып бакыр тәнкәләр сибелә. Кимәшә башын бүксәң кап булганчы аша, зыяны юк. Кимәшә башына ялганып урманда, көзгедән калган коры яфракларны аралап күке башы калкына. Аланнарда кузгалак үсә, кыр какысы, урман какысы котырып уңа... Төрле якларга әнис, җир бәрәңгесе, карабаш, балтырган җыярга йөрибез. Олы су башында сарана!.. Кәҗә башы урамыннан ындыр артларына төшсәң ни генә юк анда: песи борчагы, карга борыны, шепкән... Тыкрыкларда кычыткан кыяры үсә. Карга борынының тамарга торган җиләген ашыйбыз, шепкән уабыз. Шома көпшә, сасы көпшә, чуар көпшә. Җаның ни тели!

Эссе җәй! Яндыра! Быел җәй коры, ләкин без яраткан болынның дымы бетми, без икешәрләп тотаклашып Метри елгасына таба төшеп барабыз. Алдан юл күрсәтеп әни бара, ыбыр-чыбыр бәрәңге арасында адашып калмасын дип арттан үткер күзле Феона апа атлый. Нәкъ каршыбызда, елга үзәненең аръягында, уңдарак, унбиш-егерме йортлы Имәнле урамы. Урам очында Чулак Кунуннар йорты. Үкличә киртәсе алар ихатасына тоташкан. Үзем күрдем, әнигә ияреп көтү каршыларга барганым бар. Кунуннарның Ладимыр исемле куштүбәле базык уллары да площадкага йөри, без хәзер шуның белән җитәкләштек. Булса да булыр икән шук бала! Ладимыр берәүгә дә тынгы бирми, кызларның толымыннан тарта, толымыюкларның бармагын тешли, малайларны чалып ега, су коенганда кызларның күлмәгенә таш бәйләп буага ыргыта. Үзе көчле, үзе алагаем хәйләкәр. Бу терекөмеш мәктәпкә кергәч тә укытучыларның җанын чыгарды. Дәрестә утыра алмый иде, мәктәп базына кереп чума, теленә нинди җыр килсә, шуны акырып ята... Имәнле урамы хәзер юк, бетте, таралды, Ладимыр яшьтәшем дә күптән инде гүр иясе булды. Үскәч акыллы, үтә сабыр, ипле кеше иде, шофер булып эшләде, көтү көтте... Сирәк кенә, сагынышып очраша торган идек, урының җәннәттә булсын, яшьтәш!

Төшеп барабыз, әни, күз алдында булсынга, аны алгы парга куйган, шунда да ул мине чалып егарга маташа. Тезләре кутырлап беткән, иягендә җөй, иреннәре мыймылдый; колагы селкенә. Һич тик бара алмый! Күзем Имәнле урамы өстенә эленгән, печән кибәне дәүмәлеге болытка төште. Болытны чамалап әни дә туктап калды. Зәп-зәңгәр иде бит күк, каян ялалды әле бу аклы-каралы иләмсез болыт? Капылт кына әлләни булды, зәңгәрсу-кызыл сызык болыттан аерылды да түбәнгә, җиргә, Имәнле урамы өстенә атылды. Күк яман чатлап урталай ярылды, гайрәтле күк күкрәвеннән без җиргә егылдык. Әни борылып: "Балалар!" дип кенә әйтә алды. Аяк өстендә бер Ладимыр басып калган икән, Имәнле өйләре өстеннән ургылып чыккан төтенне әүвәл ул абайлады, яшелле-мөшелле тавыш белән: "Пужар! Пужар!" дип акырырга тотынды. Озак та үтмәде тирә-якны искәртеп чиркәү чаңын кага башладылар. Әни белән Феона апа, тилгәннән качып кайсы кая таралган чебиләрне җыйган төсле, безне көч-хәл белән җыйдылар. Бер кыз куркуыннан Метри елгасының төбенә үк тәгәрәп төшкән икән. Утыра шунда посып, үги ана яфраклары арасында! Без бәрәңге сабакларын таптый-таптый каравыл өенә менеп җиткәндә анда мәхшәр башланган иде инде. Тик ятып үшәнләнгән каравыл атлары чаң тавышыннан куркып тәртә арасына керми интектерәләр, пужарниклар да каушаган, алар ат сыртына каеш камчы белән тамызалар. Атлар аның саен киреләнә, йөгәннәрен тартып хырылдыйлар. Күпердән әйләнергә ераксынган Урта урам адәмнәре чиләк, көрәк, багурлар тотып, без менгән сукмактан гына Метри елгасын кичеп, янгын ягына элдерәләр. Башта аклы-каралы куе төтен бөркелгән иде, соңра ялкын телләре сузылды, бераздан Имәнле урамы тоташ учакка әйләнде. Әллә-лә! Яна Имәнле урамы, дөрли, ә яман гадәтле алама болыт "Сау булыгыз!" дигән төсле, авыл күген бер әйләнде дә үтеп китте. Ут янына чабарга шүрләгән карткоры Каравыл өе янына җыйналды. Телләрдә бер сүз: "Вәт ходаның хикмәте, ишеп яуса соң! Нигә утын гына ташлап калдырды бу болыт, шонык!"

Унбер йорт нигезенә кадәр утырып янды. Кага-кага чиркәү чаңын урталай ярганнар...

"Эзидән дә килделәр, тирә-яктагы унбиш авылдан атлар килде", дип сөйләде, соңгарган кичке чәй янында әни. Ул төнгә әни площадкага ашыкты, ул төнне Имәнле урамы балаларын шунда кундырдылар. Әни шуларны карап, ашатып, площадка саклап чыкты.

Мин бик озак йокыга китә алмадым, иләмсез болыттан аерылган дәһшәтле ут күз алдымнан китмәде. Йоклагандай булам да куркып, кычкырып уянам. Ичмасам, янымда әни дә юк!

Шул көннән мин болыттан, яшен утыннан, күк күкрәвеннән курка башладым. Офык читендә каралҗым болыт куера башладымы, өйнең берәр почмагына кереп качам. Тик яшен камчысының агы шулкадәр көчле, кермәгән тишеге, үтә алмаган почмагы юк. Чоланда дәү агач сандыгыбыз бар – артына кереп посам, яшен чартлый-чартлый мине эзләп таба. Толыпка уралып мич арасына кереп утырам – колагымны ярырдай яңгырап күк күкри. Ахырда әмәлен уйлап таптым. Олылар йоклый торган караваt башына әни мендәр-ястыкларны көндезгә кабартып өеп куя иде. Чак кына болыт кабарды исә шул мамык тавын ишеп төшерәм дә ястык-мендәр астына кереп йомылам. Яңгыр килгәндә ишек-тәрәзә тыгызлап ябыла, мич төннекләре томалана, өебез бәләкәй, бөркү, эссе. Ястык арасында мунча ләүкәсеннән мең яман, тын җитми, шабыр тиргә батам, манма су булам, ләкин курку барысын да җиңә.

"Курку иң явыз көчләрнең берсе", дип аңлата эти, мине батыраерга чакыра. Бу курку хисеннән мин озак арындым, хәзер яшенне бар дип тә белмим, хәтәр давыллы сәгатьләрдә, каралҗым караңгы күк явызланып ут чыбыркысын болгаганда Идел уртасында балык тотып утырганым бар. Әллә нинди яшен сәнәкләре күз алдымда болытлардан аерылып биектә яман сызылып барды – каушамадым. Курку – хатирә булып кына калганда әлләни зыянлы түгел икән үзе!

3.

"Улыбыз үсә!" диләр, эти белән әни куаналар. Күрше-күлән, килгән-киткән кунаклар да мине алларына бастырып мактыйлар: "Үскән, егет бу[лган] ич улыгыз!" дип, әниләрнең сөенечен арттыралар. Бала-чаганы мактаган саен сыйның мулрак, тәмлерәк эләккәнен хәзер генә аңлыйм – үзем дә өч бала атасы...

Үсү шулдыр инде, хәзер үзем генә көтү каршыларга барам, үткен күзле, корыч томшыклы тилгәннәрдән бәбкәләрне дә энем Алмаз белән бергә саклыйбыз. Сыер абзарын тазартырга, ишегалдын себерергә, малларга печән салырга эти белән чыгабыз. Эш арасында эти янында уралу иң рәхәт чаклар булган...

Үсте дисәләр дә бәләкәй шул әле мин! Үземнән ике яшькә генә олы Азат еш кына мине тәпәләп ала. Менә ул үскән ичмасам! Шкафның иң өске киштәсенә үрелә дә прәннекне чәлдерә, мин сорасам муен тамырыма кундыра. Азат үскән ичмасам, ул мәктәпкә йөри, ул – укучы, аның белән чамалап сөйләшергә кирәк. Олы малай буларак, ул эти белән утын кисәргә чыга, пычкының бер башын ул тарта. Мин эти ярган утынны ышыкка, лапас астына ташыйм, ә энекәшем Алмаз җиз таска түбәләмә итеп йомычка җыя. Баграж авылын өч яктан урманнар ураган булса да безнең эти әрәм-шәрәм иткәнне өнәми.

Үскәнмендер дә шул: хәзер мин бик күпне беләм. Безнең бабай Сарманның иң ярлы "Ак ыштаннар мәхәлләсенең" имамы булган. Әтинең Нурлыһода, Маһиәнвәр, Әсма атлы апалары бар, Сарманда элегрәк телгә алган Мәхүбрахман абый яшәп ята. Элеккеге Мөхәммәдия шәкерте, зур укымышлы зыялы кеше, скрипкачы. Һәр яктан талант иясе. Бакчачы, җиләк-җимеш үстерү остасы. Агач утырту, күпер-юлларны төзәтү, табигатьнең кадерен белү безнең нәселдәге һәр кешегә хас. Нурлыһода түтинең ире Ризван мулланы күргәнем юк ахрысы, ә аларның бердәнбер уллары Хәмзә исемле искиткеч чибәр, бөдрә чәчле, көр тавышлы егет безгә еш-еш кунакка килеп йөри. Без дә аларга баргалыйбыз. Әсма апаның Лена, Илтөзәр, Рәҗия исемле балалары да безгә килеп чыга, безнең яшьлек чорында туганнар еш аралаша иде, бер-береңә хөрмәт, хәл-әхвәл белешү көндәлек гадәткә кергән, канга сеңгән иде. Безнең йортка иң еш килеп йөргән кеше әтинең тол апасы Маһиәнвәр булгандыр. Без аны кыска гына "Әнвәр түти" дип атап йөрттек. Әнвәр түти еш килү өстенә бездә бик озак – икешәр, өчәр ай торып китә иде. Көзгә кереп бакча эшләре тәмамлангач, сугымнар суелгач, каз өмәләре үткәч килеп төшә дә язга кадәр кунак була. Үз гаиләсе булыр-булмас, кияүгә чыгып тиз үк аерылып кайткан бу апабыз әз генә йокычан, әз генә юбалгы, мунчага барса дүрт-биш сәгатьсез чыкмый торган, тәмле тамак карчык иде. Кара тут йөзен, шактый куләмле борынын гына калдырып, яулык белән урап куя торган бу апа гомере буе кара-көрән, озын итәкле күлмәк яратты, яулыкның да агын бәйләми иде шикелле. Бу ятимә карчык олылардан аерым хөрмәт күрмәсә дә безгә килергә ярата иде. Дөрес, аның өс-башын карыйлар, тамагы сыйлы, урыны түрдә, мәгәр олы кунак-мазар килгәндә аны табынга алмыйлар, бәлки ул үзе шулай теләгәндер, әмма кеше барында, кече якка чыгып Әнвәр түти ашап утырганда мин аны үтә нык кызгана идем. Шунысы да бар, күпме яшәсә дә ул мәңгелек кунак, өй эшләренә катышмый, сирәк-мирәк идән себергәли иде, мендәр-юрганнарны кагарга көнгә алып чыга. Яше олы булса да намаз укымый, мин аның дога укып, амин тотканын да хәтерләмим. Ул шушы дөньяда тарсынып, нәрсәдәндер кыенсынып яшәгәндер, ахрысы. Хак, зарланганын ишеткәнем дә булмады, җылаганын күрмәдем, йомылып, үз уйларына батып яшәүче бу сәер апага мин аерата нык тартыла идем.

Үзара дус идек без.

Менә олылар кайсы кая тарала, киндер букчасын асып Азат мәктәпкә китә, Алмаз уенда, без түти белән өйдә икәү калабыз. Кайчагында гына Алмаз да өйдә була. Урамга чыгар идең, карлы яңгыр коя, тәрәзәләр парланып томаланган, җил янбакчадагы шомырт агачларының соңгы яфракларын талап улый. Шундый аулак чакларда Әнвәр түти капылт үзгәрә, аның хәсрәтле җыерчыклар белән каймаланган кап-кара күз тирәләре җанлана, нурлана, ул яулыгын маңгаеннан күтәребрәк куя, кара тут маңгаена чал сибелгән кара чәчләре сибелеп чыга. Аның җанлануын, күңелле үзгәрүен күреп мин куанам, түтине ныграк сөендерәсем килә, өстәлне, урындыкларны күчереп өйне киңәйтәм, идәннән сәкегә, сәкедән идәнгә сикереп мәзәк ясарга тотынам. Авыз-борынымны мыймылдатам, телемне чыгарам, күзгене үчеклим, ишек катында мыштым гына утырган дәү галушларны киеп лыпыр-лыпыр биегәндәй итәм. Берзаман галушлар очып ике якка барып төшәләр... Әнвәр түти тагын да җанланып минем маймыллануымны күзәтеп тора, ачуланмый, сүкми, көлә, тәне җиңеләеп китә. Аның да иңбашлары бер күтәрелә, бер төшә, йөзенә кызыллык чыга: ул учын-учка бәреп такмак әйтергә тотына. Аның такмагы кыска, ике-өч сүздән генә тора, алай да минем йон оек кигән аякларым үзеннән-үзе сикергәли башлый, мин идән уртасына чыгып тыпыр-тыпыр биеп китәм. Түти җай гына, бер көйгә генә: "Сездә кем бар киндер суга, сездә кем бар киндер суга!" дип бертуктаусыз кабатлый. Аның сүзгә зарыккан иреннәреннән тавыш һаман көчлерәк чыга, ни озак такмакласа да мин армыйм, аның шушы гади такмагы мине котырта, дәртләндерә, шашындыра. Мин тәмам онытылганмын, түтинең колагы тышта икән, менә ул тынып кала, яулыгын төшереп бәйли, маңгаен яшерә һәм тынын тигезләргә мич арасына кереп китә. Андагы үзгәрешне күреп мин телсез калам. Түтинең: "Кайттылар!" дип пышылдавы гына мине игә китерә.

(Дәвамы бар).

Кави ЛАТЫЙП

УЙЛАНДЫРАСЫҢ...

Аяз Гыйләҗевкә

Уяндырасың,
уйландырасың.
Син беләсең милләт кыйбласын.
Ай калкасын,
Кояш чыгасын –
бәхет сәгате илдә сугасын.

Сокландырасың,
таң калдырасың.
Күз алдында
язгы гөлдәй,
аяз көндәй елмаеп торасың.

Тылсымлы каләм синең кулда.
Синең уйлар
чишмә буенда,
яшел болында.

Синең хакка дога укып,
каршылыйм туган көнеңне.
Синең күңел, синең күгең
Киек каз юлы түгелме?!

Уйландырасың,
уяндырасың,
сокландырасың.
Өч аршин җирне генә түгел,
бар Җир шарын
татар кыйбласына борасың!..

"Бодай чәчсәң җиргә, һич вакытта Тигәнәкләр үсмәс..."

Фәтхи Бурнашның иҗат гомере озын түгел: ике дистә елдан аз гына артык. Ләкин иҗаты бик бай, гаять эчтәлекле. Мирас хәзинәсендә 300гә якын шигырь һәм поэмалар, 22 пьеса, опера өчен 5 либретто, 15ләп хикәя һәм фельетоннар, А.Пушкинның "Евгений Онегин" шигъри романының соклангыч тәрҗемәсе, Л.Толстойның "Хаҗи Морат", И.Тургеневның "Аталар һәм балалар" кебек зур күләмле әсәрләреннән уннарча тәрҗемә китаплар, М.Җәлил кебек замандашларына хатлар, бәяләмәләр һ.б. бар. Дистәләгән псевдонимнар кулланып ул ярты меңнән артык мәкаләләр һәм рецензияләр язган.

Аның әдәби иҗат юлы ике тармакта башлана. "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенең 15 яшьлек шәкерте "Сәйяр" труппасы өчен урыс язучысы С.Найденовның "Ванюшин балалары" исемле драмасын татарчалаштыра. Көнчыгыш әдәбиятлары рухында тәрбияләнгән шәкерт ул тарафны да онытмый: шәрекъ мотивларын иҗади файдаланып, "Гарәп кызы Ләйлә" пьесасын яза. Беренче пьеса Г.Кариев тарафыннан сәхнәләштерелсә, икенчесе язучының шәхси архивында ятып кала. Моннан соң "Язмыш", "Сукбай", "Саташкан кыз" дип аталган оригиналь әсәрләре языла, беренче икесе сәхнә күрә.

Шул ук вакытта шагыйрьлек юлы да башлана: 1914-16 елларда гына да Ф.Бурнашның дистәләрчә шигырь-поэмалары ("Авылда", "Дулкыннар арасында", "Коркыт", "Казакъ кызы", "Вакытсыз үлгән апама", "Зур хата" кебек шигырьләре журналларда дөнья күрә.

Ф.Бурнашның беренче чорда язган әсәрләре сәнгатьчә эшләнеше ягыннан инде шактый җитлеккән булуын, шигъри табышларга байлыгын, пьесаларында характерларның ачыклыгын күрергә мөмкин. Моңарчы без, совет заманында кабул ителгәнчә, аның беренче әсәрләрен "өйрәнчек" дип кенә бәяләп уза идек, чөнки аның таланты чын мәгънәсендә совет чорында гына чәчәк атты дип расларга кирәк иде. Инде аның тәүге шигырь-поэмалары татарның романтизм шигъриятендәге иң югары нокталарында торганлыгын тану вакыты җитте.

Драматургиядә исә аның беренче зур уңышлары, авторының исемен киң укучыларга таныткан әсәрләре – "Таһир-Зөһрә" трагедиясе һәм "Яшь йөрәкләр" комедиясе була. Әйтергә мөмкин ки, гәрчә каләме чарлана, тәҗрибәсе арта барса да, болар кебек озын гомерле пьесаларны ул инде совет чорында тудыра алмый. Моның сәбәпләре һич тә Ф.Бурнашның үзендә генә түгел.

Ни өчен татарлар Октябрь инкыйлабында актив катнашты да, гражданнар сугышы елларында хәтта Урта Азия далаларына кадәр барып чыгып, анда совет хакимиятен урнаштырып йөрде? Бу яктан башка төрки халыклар һәм Идел-Урал өлкәләрендәге милләтләр арасында иң активы булды? Моның күзгә ташланып торган ике сәбәбе бар. Беренчесе, татар җәмгыяте милли азатлык фикере белән иң нык сугарылганнардан иде. Көчле оешкан һәм заманы өчен алдынгы дәүләте булган, аны XVI гасырда җуйган һәм колониаль хәлдә яшәп килгән халык инкыйлабларда иң әүвәл милли азатлык өметен аклау юлын күрде. Икенчедән, мәгърифәт ягыннан башкалар белән чагыштырганда шактый ук алга киткән татар халкы социализм идеяләрен, андагы алдынгы фикерләрне тизрәк үзләштерде.

Революцион көрәшне мактауда, яулап алынган хөрлекне зурлауда, Татарстан һәм татар халкының киләчәген матур итеп күрүдә Ф.Бурнаш та каләмдәшләре арасында үткен фикергә һәм хыялга байлыгы белән аерылып тора. Гаять нәтиҗәле эшләве, йөгерек каләме белән. Мәсәлән, оештыру-җитәкчелек һәм редакторлык-журналистик хезмәтләреннән тыш, ул 1919 елда гына да 9 поэма язарга, шигырьләр һәм хикәяләр, "Җирсезләр" драмасының бер өлешен иҗат итәргә, күпсанлы мәкаләләр язып бастырырга вакыт таба. Ә бит алар арасында татар поэзиясенең алтын фондында урын алган "Ак каен", "Әҗәл" поэмалары да бар. Кыскасы, бу – Ф.Бурнашның әдәби иҗатында иң уңдырышлы, табышларга бай чор.

Билгеле инде, мондый әсәрләрнең уңышы, беренче чиратта, аларның сәнгатьчә эшләнеше югары булудан килә. Икенчедән, аларда милли әдәбиятта традицияләре көчле булган мотивларның алга үстерелүе дә мөһим роль уйный. Мисалга 20 нче еллар театрында тирән эз калдырган "Хөсәен мирза", "Камали карт" пьесаларын алырга була. Мәсәлән, икенчесенең уңышын әсәрдәге вакыйгалар үзәгендә торган Камалины фаш итү билгели. Иске тормышның терәге булган тип. Иске тормышның кимчелекләрен фаш итү татар әдәбиятының игътибарын күптәннән җәлеп итә. Аерым алганда, күп хатынлылыкны хупламау хас. Г.Исхакыйның "Өч хатын белән тормыш" драмасын искә төшерик. "Камали карт"та ике хатынга баш булырга омтылган кешенең деспотлыкка корылган гаиләсенә тигез мәхәббәткә, үзара хөрмәткә, тугрылыкка нигезләнгән яңа гаилә каршы куелган. Шулар тамашачыга якын да инде. Ә инде комсомоллык, кызыллык, пионерлык, байлыкка төкереп карау, дин әһеленнән көлү, бай мещанканың яңалыкка реакциясе һ.б. – болары совет идеологиясеннән килә. Һәм менә шулары комедияне, тарихи кыйммәтен җуймаган хәлдә, үз чоры белән бергә калдыра, бүгенге укучы һәм тамашачы өчен артык кызыклы булмавын китереп чыгара.

Бер яктан, дөреслеккә омтылганы, икенче яктан, иҗатында, бигрәк тә шигъриятендә романтизмга тугрылыгы өчен ("Мазлума", 1924; "Мөкәррәмә", 1926; "Бохара" поэмалары) Ф.Бурнаш 20 нче елларның урталарынан башлап каты сүгелүләргә һәм кыерсытылуларга очрый. Иң әүвәл, шулары өчен аны "карт язучылар" рәтенә кертәләр, "әдәби суд"лар оештыралар (1924). Әйе, 26 яшьлек Ф.Бурнаш – карт язучы, яшьләргә юл бирмәүчеләрнең башында торучы дип игълан ителә. Асылда "Сулф" тарафдарлары оештырган бу "суд" Ф.Бурнаш иҗатын тулаем кире кага, күпчелек әсәрләрен "эшче-крәстиән әдәбиятын агулаучы нәрсәләр" дип бәяли. Ә инде "Матур әдәбиятта буржуаз милләтчелеге" (1930) исемле китапта партиячел тәнкыйть тагын да "алгарак" китә, аңа "сарайлар, ханнар, кенәзләр, мәчетләр шагыйре" дигән ярлык тага. Алда аталган һәм башка, шулай ук "Шаян кыллар" (1926), "Борынгы җырлар" (1927) исемле җыентыкларында тупланып басылган, нахак гаепләүләргә сылтау булган шигырь-поэмалары Ф.Бурнаш поэзиясенең көчен һәм төп юнәлешен билгеләүче, татардагы романтик шигъриятнең үзенчәлекләрен ачык чагылдыручы әсәрләр буларак яңача укылырга һәм бәяләнергә хаклы.

Сәнгатьчәлекнең бер терәге булган дөреслек белән советчыл сәясәт арасында еш кына туры килмәү, хәтта каршылык туу Ф.Бурнашның пьесаларында да, аларның сәхнә тарихы, тәнкыйть бәясендә дә күренә. Авторның баштагы нияте белән рәсми идеологик ноктадан торып "төзәтүләр" арасындагы аерымлыкларда да чагыла ул. Мисалга драматургның 30 нчы еллар башында язылган драмаларын алырга була.

Дөреслек һәм рәсми идеологиянең тартышы нинди әдәби-иҗади нәтиҗәләргә китерүен Ф.Бурнашның тагын да кайбер әсәрләре, мәсәлән, "Ялгыз Нурулла" пьесасы мисалында да күрергә мөмкин. Рәсми идеология белән артык сугарылганлык аркасында Ф.Бурнашның әдәбиятыбызга алып килгән яңа-лыклары тиешенчә яңгырый алмый.

Мәсәлән, ул татар поэзиясендә беренче булып оратория ("Ватан", 1935), марш ("Колхозчылар маршы", 1933) иҗат итә. Җырбию ансамбле өчен "Колхоз туе" исемле сценарий-либретто яза. Соңыннан, Ф.Бурнаш "халык дошманы" дип игълан ителгәч, Н.Исәнбәт аны нигезгә алып, Татарстан филармониясе өчен сценарий эшләде, һәм ул озак еллар репертуарда сакланды. Гомумән, бу иҗатның кайбер шул рәвешле яшәвендә,– үзе әдәбияттан сызып ташланган булса да,– дәвам итте. Бурнашның балалар өчен язылган "Бүре" поэмасы нигезендә К.Нәҗми әсәр иҗат итте. Аның шигырьләренә чыгарылган көйләргә Ә.Ерикәй һ.б. шагыйрьләр, яңа сүзләр язды, алар яңгырауларын дәвам иттеләр "(Бибисара", "Комсомолка Нәфисә" һ.б.). "Таһир-Зөһрә" өчен, андагы "Гөл патшалыгы" күренешенә махсус язылган "Шәрекъ биюе" исемле балет музыкасы (С.Сәйдәшев) трагедиянең исеме әйтелми генә яшәде...

Без, еш кына, большевиклар хакимияте чорында гомерләре лагерь-төрмәләрдә өзелгән язучылар турында сүз барганда "күпме тормышка ашмаган хыяллары, язылмаган әсәрләре үзләре белән китте", дип офтанабыз. Шуның белән бергә шул шартларда азмы-күпме яза алган, ихластанмы-юкмы совет идеяләрен алга сөргән һәм матур гына әсәрләр иҗат иткән талантларның тиешенчә тормышка ашмаган яки ярым-йорты гына үтәлгән планнары да бар бит әле. Ягъни таланты чын мәгънәсендә чәчәк ата алмаган, совет режимы моңа иркенлек бирмәгән иҗатчылар. Ф.Бурнаш – шундыйларның берсе. "Сарайлар, мәчетләр былбылы" дип аталган язучының күпме әсәрләре язылмый калгандыр да, күпмесе тиешенчә эшләнеп бетә алмыйча, ялгыш принциплар тәэсирендә сәнгатьчелек җәһәтеннән дә, дөреслек ноктасыннан да зәгыйфь булып тугандыр... Дөресен әйткәндә, совет елларында гомере буе кагылган-сугылган башка андый язучыны атап әйтүе кыен. Романтик әсәрләре өчен дә сүгәләр аны, Татарстанда милли сәясәтне бозуга каршы язылган "39 кеше белдерүе" (1924) дип аталган рәсми хатка кул куйганы өчен дә, "солтангалиевчелекне ахыргача яклаган" өчен дә кыйныйлар, Г.Тукай һәм Ф.Әмирханнар иҗатларын яклаганы һәм пропагандалаганы өчен дә кыерсыталар... Нәтиҗәдә – күпме иҗат ялкынын, талант көчен аның тантанасы өчен сарыф иткән язучы тоталитар режим тарафыннан җисмәни юк ителә: Ф.Бурнаш 1942 елның 1 августында лагерьда атып үтерелә.

Без, бүгенге укучылар да, әдәбиятчылар да, Фәтхи Бурнашның 100 еллыгын совет җәмгыятендәге мәгънәсезлекләрне һәм кешелексезлекне гаепләү һәм каһәрләү белән, офтану һәм кызгану белән билгеләп үтәбез. Шул ук вакытта, ул язган әсәрләрнең милли әдәбиятыбыз тарихындагы урынын дөрес билгеләргә омтылып, алардагы сәнгатьчә табышларга сокланып, бүгенге укучы күңеленә дә юл табардай әсәрләрен барлап-билгеләргә тырышабыз. Шул максат белән, бүгенге көндә Татарстан Фәннәр академиясендә язучының күпчелек әсәрләрен эченә алган 5 томлык җыентыгын төзү эше алып барыла.

Рәсми идеологияне яклап язган күпчелек әсәрләрендә дә Ф.Бурнаш олы художник булып кала. Халыкчан, сәнгатьле тел, сурәтләү чараларына байлык, фикер ачыклыгы аның шигъриятенә дә, драматургиясенә дә хас. Пьесаларының яртысы сәхнәдә уйналган. Алар буенча куелган спектакльләрдә уйнап, Г.Кариев, Б.Тарханов, Ф.Ильская, Х.Сәлимҗанов кебек дистәләгән артистлар талантларын үстергән, димәк, бу яктан да алар театр сәнгате тарихында сизелерлек эз калдырган.

Кыскасы, пролетариат идеологиясе орлыклары өчен генә дип эшкәртелгән совет туфрагында Ф.Бурнаш мул уңыш үстергән.

Бодай чәчсәң җиргә,
һич вакытта
Тигәнәкләр үсмәс... –

дип яза ул үзенең бер шигырендә. Ул чәчкән бодай бөртекләреннән зәгыйфьләре, хәтта кысырлары да шытып чыкты. Шулай да, тулаем алганда, Ф.Бурнаш әсәрләре әдәбиятыбыз басуында үзләренә генә хас төсләр белән балкый. Үзләренә бүгенге укучының да игътибарын тартып, аларда бу талантлы әдипкә карата соклану һәм рәхмәт хисләре уята.

Азат ӘХМӘДУЛЛИН,
Казан дәүләт университеты профессоры.

Батулла баганасы

Милләт аермаучы

Уфага баргач, Бакый Урманчены, аның хатыны Флора ханымны һәм Әмирхан Еникины партия өлкә комитеты секретаре Таһир Ахунҗанов үзенә кунакка чакыра. Сөйләшеп утырганда, Ахунҗанов "Башкорт драматургиясе" исемле өч томлык китапны ачып күрсәтә. Бик һәйбәтләп чыгарылган бу антология Мирхәйдәр Фәйзинең "Галиябану" пьесасы белән ачылып китә икән.

– Бәй! – дип гаҗәпләнә Әмирхан Еники. – Мирхәйдәр Фәйзи башкорт түгел бит ул, татар кешесе. Аның туганнары композитор Җәүдәт Фәйзи дә, журналист Сәгыйть Фәйзи дә татар кешеләре.

– Без башкорт белән татарны аермыйбыз! – ди Ахунҗанов вәкарь белән генә.

Көчекләр

1986 ел.

Язучыларның олы бәйрәмнәрен уздыру-уздырмау мәсьәләләре турында партиянең ачык җыелышы бара.

Әмирхан Еники: Фатих Әмирхан – бөек язучы. Әле аның бөеклеге тулысы белән ачылып бетмәгән. Хәзер аның олы язучы, акыл иясе икәнлеге турында җыелышлар үткәрәбез. Шөкер. Ләкин минем күз алдымда аны буржуаз язучы, зарарлы шәхес, дип сүктеләр. Матбугатта барысы да бар. Аны изгән, аны үтергән кешеләр үзләрен марксист дип саныйлар. Аларның инкяре матбугатта калган. Хәзер әнә шул карашны сүтәргә кирәк бит. Хатаны төзәтергә кирәктер бит, иптәшләр. Тарихи гаделлек йөзеннән кирәк бу нәрсә...

Нәби Дәүли: Нигә кирәк ул? Нигә яңадан буза куптарырга! Мәгълүм бер мәсәлдә көчек филгә өрә. Фил аңа игътибар итми. Фатих Әмирхан ул көчекләрдән өстен.

Әхмәт Исхак (Батулла колагына сак кына пышылдый): Бүгенге көчекләр филләргә өрмәсен өчен кирәктер аларны фаш итү, сабак алсыннар өчен!

Югалту

Сибгат Хәким Хәсән Туфанның зинданда күргәннәрен аерым бер дәфтәргә язып бара. Дәфтәр тышына "Туфан" дип язып куя.

Бервакыт Сибгат Хәкимнең дачасын караклар баса. Әллә ни дә алалмыйлар. Иң кыйбаты – "Туфан" дәфтәре юкка чыга.

– Каракларга нигә ул дәфтәр, Сибгат ага? – ди Батулла.

– Черек күл буендагы караклар алгандыр аны! – дип җаваплый шагыйрь.

Көлсәң – көл, көлмәсәң – ела!

Заманалар авыр, дөнья кырыс. Кайвакыт утырып елыйсы килә. Кем ничектер, ә мин шундый чакта йолдызнамә укырга керешәм. Менә бүген дә, хезмәт хакы алмаганга биш ай тулган көнне, көҗәмөгезләргә (ә мин шул йолдызнамә астында туган) ишелеп акча керәсе икән.

Эчкә шундук җылы керде, йөрәктә өмет чаткысы кабынды. Ул җылылыкны тоеп, кичке алтыга хәтле эштә дулкынланып утырдым. Әмма акча ишелеп түгел, тишелеп тә кермәде. Бәлкем, өйдә берәр сюрприз көтәдер, мәйтәм.

Кайттым. Кичке өстәл артында бер чынаяк чәй эчәргә өлгермәдем, хатын:

– Фатир өчен түләргә квитанса китерделәр, кызның аягына кияргә сапогие юк, – дип мине йолдызнамәләр җемелдәгән хыялый галактикадан кырыс җиргә иңдерде. Хәләлем тагын шул яши белгән баҗайны искә төшереп кухняда савыт-саба шалтыратты.

Ә мин, хыял атына атланып, тагын йолдызнамәләргә очтым. Юкка уйлап чыгармаганнардыр бит инде аларны?! Күпме гыйльми китаплар язылган: гәзитләр һәр көнне бастырып торалар. Бер килмәсә, икенче килергә тиештер бит...

Дамир ГЫЙСМЕТДИН

Юраулары рас килде...

Иртән, гадәттәгечә, үзем яраткан "Капитализм таңнары" гәзитәсен сатып алдым да, эшкә килдем. Бу юлы йолдызнамә "көҗәмөгезләр кирәкле малларын сатып алачаклар", дип вәгъдә иткән иде. Рас килмәсә дә, мантыйк бар үзендә. Кичә ишелеп акча килә, бүген китә...

Ул көнне эштә, биш ай хезмәт хакы алмаганга күрә, безнең контора ачлык игълан итте. Ял көннәрендәге хәлләрне сөйләп тормыйм, дүшәмбедә йолдызнамә буенча эшләр шәп, һава матур торачак, көҗәмөгезләр табигать белән хозурланачак иде.

Чынбарлыкта исә эштә ачлык дәвам итте, ә урманда иртәннән кичкә хәтле карлы яңгыр иште.

Сишәмбедә һәм чәршәмбедә көҗәмөгезләр романтик мәхәббәткә дучар булып, ләззәтләнергә тиешләр иде.

Бергә эшләүче Гөлнур, ачлыктан эчкә баткан күзләрен миңа төбәп: "Ханнан абый, сез нишләптер бер дә ябыкмыйсыз, әллә инде бездән качып ашыйсыз?" – дигәч, мин ачудан контористагы бердәнбер калькуляторны сейфка бәреп ваттым.

Өйдәге ләззәтләрдән иң истә калганы хатынның: "Ханнан, кеше ирләре акча эшли, синнән ни он суы, ни тоз суы!" – дигән сүзләре булды. Кухняда шалтыраган савыт-саба да "баҗаң, баҗаң", "үрнәк-үрнәк" дигән авазлар чыгара сыман тоелды миңа.

Гыйләҗи баҗайның шушы болганчык заманда белемсез-нисез баеп китүенә гаҗәпләнсәм дә, ул аферистка мәңге кул сузып бармам, Аллаһы боерса. Кара әле син аны: ике класс белеме белән элек склад мөдире булып эшләде, ә хәзер психотерапевт. Йөзләгән кешенең башын әйләндереп, акчалы сеанслар уздырып йөри...

Пәнҗешәмбе көнне директор миңа хөкүмәт милкенә зарар китергәнем өчен шелтә бирде һәм штраф салды. Ә йолдызнамә буенча мин эштә зур уңышларга ирешергә, шефтан мактау грамотасы һәм премия алырга тиеш идем.

Кыскасы, атналык, еллык йолдызнамәләр көҗәмөгезләргә әллә нинди уңышлар, көтелмәгән акчалар, сәламәтлек, гаилә бәхетләре, чит ил сәяхәтләре вәгъдә итсәләр дә, аларны күрергә насыйп булмады. Киресенчә, тормыш җилкәгә икенчерәк, һич тә дәртләндерми торган нужаларны, михнәтләрне аудара торды.

Ә бит мин, Үгез елында туган көҗәмөгез, быел аеруча шатлыклар, көтелмәгән бәхетләр татырга тиеш идем, югыйсә.

Нишләп соң әле бу йолдызнамәләр, юраулар бер дә юш килми? Нәрсә соң бу? Белә торып алдаумы, шарлатанлыкмы, әллә махсус эшләнә торган бер кыңгыр эшме? Бәлкем, мондый матур киләчәк хакындагы әкиятләрне вәгъдә бирүчән депутатлар, йә "тормыш яхшыра" дип тәкрарларга маһир хөкүмәт вәкилләре язып утырадыр? Әллә, мәйтәм, яхшыга барган тормыштан канәгать булмаган халыкка шулай итеп өмет, түземлек иңдерәләр микән?

Шушы башваткыч сорауларга җавап эзләп, мин "Капитализм таңнары" гәзите редакциясенә юл тоттым. Тормышымның аксап-туксап баруына ул да гаепле сыман тоелды миңа. Мәсәлән, бүген җомга һәм йолдызнамә буенча мине көтелмәгән очрашу, кичен гаиләмне көтелмәгән бүләкләр көтә. Нинди очрашу ди, нинди бүләкләр! Кем соң әле ул гәзиттә акны кара дип утыручы күрәзәче?!

– Ул бик гади, ләкин талантлы кеше, – диде миңа елмаеп, гәзитнең баш мөхәррире. – Әйтик, мистни талант. Теләсәгез, очраштыра алам. Ул әле генә безгә киләсе атнага йолдызнамәләр фаразлавын алып килде...

Бер-ике минуттан баш мөхәррир бүлмәсенә мин инде кайчаннан бирле битенә төкерергә ниятләп йөргән йолдызнамә авторын алып керде. Аны күрүгә, "лып" итеп урындыкка утырдым. Ул – хатынның идеалы, Кашпировскийның варисы, аферист Гыйләҗи баҗай булып чыкты.

Мин, хәтта төкерергә онытып, мөхәррир бүлмәсеннән ашыгып чыгып киттем. Гарьләнәсүгенә эшкә кайттым. Ә анда барысы да ашап утыра. Безгә, ниһаять, хезмәт хакы биргәннәр. Юк инде, нинди акча белән булсын. Памперс һәм прокладка белән. Шулай итеп, беренче тапкыр йолдызнамә рас килде бит, әй!.. Өйгә бүләк белән кайтам...

Күршеләрнең эте бар

Соңгы вакытта "һәвәскәр" шагыйрьләрнең зәвыксыз шигырьләренә һәвәскәр композиторлар көй язган җырлар күбәеп китте, дип яздыгыз. Мин дә сезгә шундый бер җырны аңлатып бирмәкче булам.

Кунак кызы

Кунак кызы, кунак кызы,
Кемгә тиярсең икән?
Озата барсам әгәр дә,
"Сөям сине, сөям сине,
Сөям", диярсең микән? -

дип җырлый Айдар Галимов. Беләсезме, кем ул авылга килгән кунак кызы? Ул үзен королева, принцесса, сандугач, Алланың кашка тәкәсе, ягъни көҗәсе, дип саный. Аны килде-китте егетләр озатмый да әле. Әзмәвердәй, гайрәтле, кызларның күз явын алырдай егетләргә генә тәти аны озату. Шулай булуга да карамастан, ни өчен кунак кызы беренче озатуда ук үзе "сөям" дияргә, озата барган һәр кешенең кочагына ташланырга тиеш әле? Сез аны "путана" белән бутамагыз.

Әгәр инде озата барган кешенең Айдар икәнен белсә – другой вопрос. "Сөям", дию генә түгел, "үбешүләр обязательная", дип, бәлки, муенына да асылыныр иде. Монысы инде аның эше.

Ренат ГАЛӘВИН.

Пар(О)дия

Ринат МӘННАН

Каты кул

Каты куллы була күрмә,
Йомшаклыкта синең көчең,
Олы җанлы, мәрхәмәтле -
Дөньяда иң яхшы кешем!

Фирдәвес ӘҺЛИЯ.

Каты куллы булма, яме?
Беләм, бар синең көчең.
Ләкин аңла мине дә син -
Кадерле һәрбер төшем.
Әнә, күршедәге хатын -
Ишетелә бит барысы! -

Бер ел юк торуларына -
Сынык ун кабыргасы.
Икенче катта торучы -
Яратса да ул ирен -
Алдырган (җәрәхәтләнгән
Кыйнаудан соң) бөерен.
Дүртенче катта бер хатын -
Чибәр генә ул үзе -
Ире каты куллы булгач,
Күрми күптән бер күзе.
Менә сиңа ничә мисал
Китердем, яхшы кешем.
Катгый итеп әйтеп куям:
Тик йомшаклыкта көчең!..

Сала саен мең дә бер мәзәк

Телеңне дә тыя бел!..

Көз. Өзлексез яңгырлар явып, җәй челләсендә дә машина үтмәслек юллар җәяү дә йөрмәслек хәлгә килгән.

Урман кисүдән кайтып килүче биш-алты ир-ат яңгырдан ышыкланып, салам эскерте төбендә ял итәргә тукталганнар. Араларында җор, усал телле Сафиулла абзый ерактан бата-чума, пычрак ерып килүче бер хатын-кызны шәйләп:

– Карагыз әле, карагыз, егетләр! Бәкәштән "пешкәкләп" җибәргәннәр моны, аягын да көч-хәл белән сөйрәп килә. Бу фәлән-кем түгелме соң? – ди.

Барысы да көлешәләр, үзләреннән дә "төмле-төмле" сүзләр өстиләр һәм күзәтеп-көтеп торалар: "Чыннан да, кем соң бу?", янәсе.

Йөз-килбәтен аерырлык ара калгач таныйлар, аллап-артлап ике биштәр аскан бу хатын-кыз Сафиулла абзыйның берничә көн элек шәл сатарга киткән үз хәләл җефете булып чыга.

Сафиулла абзый, бер сүз дә дәшмичә, мыек астыннан мыгырданып,балтасын да алырга онытып, берүзе авылга кайтып китә.

Илһам ФӘЙЗРАХМАНОВ.
Балык Бистәсе районы.

Галим мөнбәре

Дөньяда безне әле аз беләләр. Белгән очракта да, килеп чыгышыбызны, кешелек тарихындагы ролебезне, тоткан урыныбызны монгол империясе тарихы яктылыгында гына бәяләү гадәти хәлгә әйләнгән. Аерым тарихчыларның безне күп "милләтле" төрки халыкларның берсе итеп тануларына карамастан, әле күпләр өчен без һаман да "татар-монгол" булып кала бирәбез, шулай тасвирланабыз. Безнең шундый "данлы", "шанлы" халык булып тарихка керүебезнең сәбәпләре күп. Әмма биредә сүз бу хакта түгел.

Царизм шартларында татар халкының хакыйкый тарихын чагылдырган хезмәтләргә патша цензурасы юл бирмәсә, совет, "коммуно-фашистик" режим чорында үзләре татар хисапланган кайбер тарихчылар да халкыбыз тарихын бозуда шовинистлар белән кулга-кул тотынып эшләде. Хәтта алардан уздырып та җибәрде.

Гасырларга сузылган патша-совет империясе җимерелде. Аны алыштырган урыс империясе агониядә, упкын алдында, явызлык империясенең сәяси кулы кыскара төште. Хәзер безгә татар халкының газаплы үткәне, килеп чыгышы, милли азатлык өчен гасырларга сузылган көрәше, мәдәниятебез, кешелек тарихына керткән зур өлешебез, авыр көрәшләрдә чиксез күп югалту-

Кояш чыгышына тәрәзә

ларыбызны тасвирлаган хезмәтләр язу, чын тарихыбызны торгызу мөмкинлекләре ачылды. Тарихыбызны уйдырмалардан арындыру белән берррәттән, хак тарихыбызны туган җиребездә генә түгел, дөньяга таныту турында да уйлау кирәк.

Узган ел азагында минем исемгә бер хат килеп төште. Хатта татар галимнәрен түбәндәге яңалык белән таныштыруымны сораганнар.

1997 елның 9 октябрендә язылган бу хатта Япониядә "Ислам дөньясын өйрәнү" дигән фәнни-тикшеренү җәмгыяте оештырылуын хәбәр итәләр һәм безнең галимнәребезне аның эшчәнлегендә катнашырга чакыралар. Икенче төрле әйткәндә, татар халкының тарихын, мәдәниятен, сәнгатен, әдәбиятын чагылдырган хезмәтләр белән кызыксыналар. Хат белән бергә җибәрелгән китапта бу җәмгыятьнең структурасы, максаты, бурычлары, эш программасы, планнары җентекләп аңлатылган.

"Ислам дөньясын өйрәнү" җәмгыяте Токио университеты каршында оештырылган. Әлеге җәмгыятьнең исә "Ислам дөньясында фәлсәфи вә сәяси хәрәкәт", "Ислам дөньясында географик-информацион система", "Ислам тарихы һәм мәдәнияте", "Ислам цивилизациясе" дигән бүлекләре бар. Һәр бүлекнең җитәкчесе, бүлектә эшләүче галимнәрнең исемнәре, адресы, телефоннары, электрон почта, факс номерлары күрсәтелгән. Соңгы бүлектә Ислам дөньясы халыкларына бәйле китап-журналларны туплау, кульязмалар җыю буенча махсус фәнни китапханә дә оештырылган.

Фәнни оешманың максаты мөселман илләре тарихын өйрәнү белән генә чикләнми. Хәзерге заманда АКШ, Кытай, Япония, Франция, Англия кебек илләрдә миллионлаган мөселман яши. Аларның тормышын, яшәешен, ул илләрдәге ролен тикшерү, өйрәнү дә планга кертелә. Фәнни оешма, әлбәттә, XXI гасырда мөселман халыкларының кешелек тарихында зур роль уйнаячагын искә алып эш итә.

Җәмгыять Ислам дөньясының сәясәтен, фәнен, экономикасын, динен, әдәбиятын, телен, халыкара бәйләнешләрен, тарихын өйрәнүне беренче планга куя.

1998 елдан башлап, һәр кеше, һәр галим үзенең хезмәтләрен шушы җәмгыять исеменә җибәрә ала. Кече күләмле хезмәтләр журнал битләрендә басылачак, ә зур күләмлеләре аерым китап буларак нәшер ителәчәк. Хезмәтләр ике телдә – япон һәм инглиз телләрендә дөнья күрәчәк. Димәк, хезмәт шушы ике телнең берсендә язып җибәрелергә тиеш.

Дөньяның төрле почмакларында яшәүче исламчы галимнәрнең эшчәнлеген координацияләү өчен җәмгыять 1999 елның 8-10 октябрендә Япониянең Киото шәһәрендә "Беренче халыкара симпозиум" оештыруны планлаштырган, аның икенче симпозиумы 2001 елның башында Токиода үткәреләчәк.

1998 елдан башлап, исламчы галимнәрне Япониягә фәнни семинарларга, лекцияләр укырга чакыра башлаячаклар. Болар өстенә, бу җәмгыять каршында чит илләрдән килгән галимнәргә фән докторы исеме бирү, докторантурада уку өчен дә шартлар тудыру планга кертелгән.

"Ислам дөньясын өйрәнү" җәмгыяте үз профиленә якын булган барлык фәнни оешмалар белән элемтәдә торып, алар белән Халыкара конгресслар оештыруны да күздә тота. Алар белән беренче уртак фәнни конгресс 2000 елда Норвегиядә, Осло шәһәрендә 6-13 августларда үткәреләчәк.

Күреп үткәнебезчә, бу җәмгыять белән элемтәгә кереп, аңа халкыбызның тарихына, әдәбиятына, сәнгатенә һәм башка темаларга кагылышлы хезмәтләрне җибәрү өчен шундый зур мөмкинлекләр каралган.

Бу фәнни җәмгыятьнең адресы түбәндәгечә:

Islamik Area Studies Proiect Manaqement Office

The Unjversjty of Tokyj, Bundakubu Annexe 7-3-1 Hongo, Bunkyo-ku, Tokyo 113, Japan

Электрон почта адресы:

e-mail: i: office a l u-tokio aa ip (IAS)

Телефоны: 81-3-5684-3285

Факс: 81-3-5684-3279.

Җәмгыятьнең директоры профессор Тсугитака Сато.

Бу фәнни җәмгыятьнең бүлек мөдирләре арасында татар халкы тарихын белүче, татар телен әтрафлы үзләштергән, гарәп, латин, кириллицаны яхшы укучы япон галимнәре дә бар. Аларның берсе Масаюки Ямаучи, "Солтангалиевнең хәяте: Ислам галиме вә Русия инкыйлабы" дигән, Япониядә 1988 елда япон телендә чыккан китапның авторы, минем "Татарлар: исемебез һәм жисемебез" дигән китабымны (1992) һәм Рәшит Ибраһимовның "Сәяхәтнамәсе"н япон теленә тәрҗемә иткән (1995) Хисао Комацулар бар. Әйтергә кирәк, Япониядә төрки-татар тарихы белән кызыксыну шактый сизелә. Безгә билгеле булганча, XX йөзнең 30 нчы елларыннан башлап Япониядә төрки-татарлар тарихына караган дистәләгән китаплар, шул исәптән Ибн Фадланның "Рисалә"се дә япон телендә басылып чыга. Кыскасы,япон тюркологлары төрки-татарлар хакында шактый хәбәзарлар, безнең тарихыбыз, мәдәниятебез белән кызыксыналар, аларның миңа җибәргән хаты һәм башка материаллары да шул турыда сөйли.

Җәмгыятьнең эшчәнлегендә катнашырга теләүче кешеләр, аның эш планнары белән тирәнрәк танышырга уйласалар, бу оешманың статусы, программасы белән алар җибәргән китап аша таныша алалар. Ул басма Татарстан Милли китапханәсенең кульязмалар бүлегендә саклана. Төрки-татар тарихы белән кызыксынучы икенче бер фәнни оешманы да искә алып үтәргә кирәк дип саныйм.Ул Лондонда эшләп килүче "Үзәк Азияне өйрәнү җәмгыяте". Ул инде ун елдан артык "Үзәк Азияне күзәтү" исемле журнал да чыгарып килә. Аның битләрендә безнең бүгенгебез турында Аурупа тюркологларының дистәләрчә мәкаләләре дөнья күрде.

Бу фәнни җәмгыятьнең җитәкчесе Мэри Броуксоп 1992 елда Казанда булды, татар галимнәре, әдипләре, журналистлары, милли хәрәкәт җитәкчеләре белән очрашты. Аның үзе һәм җәмгыяте турында Тәлгат Бариевның күләмле мәкаләсе дә басылып чыкты. Бу очрашулар вакытында М.Броуксоп үзе оештырган җәмгыятьнең максаты, башкара торган эшләре белән таныштырды һәм зыялыларыбызны журнал эшендә катнашырга чакырды.Бу җәмгыять, журнал чыгару белән беррәттән, Азия халыклары тормышына багышланган китаплар да бастыра. Биредә урыс телендә безнең тарихыбызга караган дистәгә якын китаплар басылды: "А.Исхаки. Идель-Урал" (1988), "М.С.Султан-Галеев. Статьи" (1984), "Дж.Валидов. Очерк истории образованности и литературы татар" (1986), "Мусульманская печать в России" (1987) һ.б. М.Броуксоп безнең зыялыларыбызга урыс телендә язган монографияләрен аерым китап итеп басарга әзер булуын да белдерде.

Моннан ярты ел элек җибәргән бер хатында ул татар галимнәреннән монографик хезмәтләр түгел, хәтта мәкаләләр дә килмәвен борчылып язды. Ярый, татар тарихчылары инглиз телен белмиләр, ди, шуңа күрә Лондонда чыга торган бу журналга мәкаләләр яза алмыйлар, ди. Ләкин бит аны инглиз теленә тәрҗемә иттереп тә җибәреп була! Безнең татар тарихчылары нигездә урыс телендә язалар. Ә бит М.Броуксоп китапларны урыс телендә бастырып чыгара. Күп кенә галимнәр язган хезмәтләрен аерым китап итеп бастырып чыгару авыр, диләр, зарланалар. Аларны, күрәсез, Англиядә чыгарырга әзерләр. Эш нәрсәдә соң, мөхтәрәм галимнәребез?

Халкыбыз тарихына, иҗтимагый фикеренә, мәдәниятенә караган хезмәтләрегез булса, аларны түбәндәге адрес белән җибәрә аласыз:

The Society for Central Asian Studies
Unit 8, 92 Lots Road
Chelsa, London SW10 4BQ England.

"Үзәк Азияне өйрәнү җәмгыяте" Мэри Броуксопның әтисе, атаклы шәрекъ белгече, тюрколог Александр Беннигсен инициативасы белән оештырыла. Александр Беннигсен – Аурупада, Америкада төрле университетларда эшләгән, дистәдән артык монография, йөзләгән башка фәнни хезмәтләр авторы. Аның хезмәтләренең күпчелеге төрки халыклар тарихына, Русия мөселманнары язмышына, СССРда милли мәсьәләләрне өйрәнүгә багышланган. Иҗатыннан күренгәнчә, байтак хезмәтләрендә ул татар халкының язмышын, татар зыялылары иҗатын өйрәнүгә зур урын бирә. Беннигсенның әтисе чыгышы белән Балтыйк буе немесләреннән, үз вакытында ул Русиянең II Дәүләт Думасында депутат итеп тә сайланган була. Ул анда Садри Максудиның төрки халыкларның хокукын яклап ясаган чыгышларын, Босфор мәсьәләсе буенча чыгышларын тыңлагандыр. Адам Беннигсен, Александрның әтисе, урыс-япон сугышында катнашкан, хәрби дәрәҗәсе буенча – капитан. Русиядә большевиклар режимы урнашкач, ул гаиләсе белән ак армия составында – Кырымга, аннан Төркиягә барып чыга. Александр Төркиядә белем алырга керешә, төрек тарихы белән кызыксынуы аны төрки халыклар дөньясына алып керә. Франциягә күчеп килгән Беннигсеннарның улы Александр соңыннан берничә тапкыр Төркиягә килә, биредә архивларда, китапханәләрдә эшли. Истанбул университетында саклнучы китапханә – Н.Катанов китапханәсе аркылы ул татар тарихы, мәдәнияте, әдәбияты белән таныша, күрәсең, шушындагы бай материаллар аңарда беренче чиратта татар халкына мәхәббәт тудыргандыр. Александр үзенең балаларында да төрки халыкларга карата мәхәббәт тәрбияләгән. Мэри Броуксоп, әтиебез безгә, урыс телен өйрәнеп сез төрки дөнья турында күп әдәбият белән таныша алырсыз, дип сөйли торган иде, ди. Аның икенче кызы Фенни Браун да тарихчы-тюрколог.

Фенни Браун хәзер Америкада яши, ике тапкыр Казанга килеп китте, архивлардан Татарстан АССРның төзелүе турында материаллар эзли, шул темага докторлык диссертациясе әзерли. Алар икесе дә, әтиебез безгә татар телен өйрәтү турында уйламаган, шуңа үпкәләп тә куябыз, диләр. Хәзер алар төрки телләрдә дә укый, тәрҗемә итә алу дәрәҗәсенә ирешкәннәр. Әтиебез гаиләбездә сөйләшкән вакытта һәрдаим "Алла белер", "Алла боерса", дип әйтергә ярата иде, диләр.

Шушы хәлләрне белгәннән соң, Мэри Броуксоп һәм аның "Үзәк Азияне өйрәнү җәмгыяте"нең безгә, төркиләргә, беренче чиратта татарларга карата киң, жылы күңелле булуын аңлавы авыр түгел.

Шәрекъ тарихы, әдәбияты, сәнгате, теле, мәдәнияте буенча Франция, Англия, Польша, Венгрия, АКШ, Австрия, Дания, Норвегия һәм башка илләрдә дә журналлар басылып килә.

Күреп үткәнебезчә, алар безгә үзләре үк хезмәтләребезне басарга тәкъдим итеп торалар.

Халкыбызның дөрес тарихын торгызу, аны дөньякүләм таныту иң мөкатдәс бурычыбыз бит. Әйдәгез, без дә аларга үз язмаларыбыз белән ярдәм итик.

Әбрар КӘРИМУЛЛИН,
академик.

Фәнзаман БАТТАЛ

БЕРЕНЧЕ ТАТАРНЫҢ



(Алдагы гасыр хикәясе)

(Ахыры. Башы 1-2 нче саннарда).

Шул ягы үзәккә үтә бу галәмдә – төн кычыта, дистә еллар буе җыелып яткан бетләр, кандалалар сөягеңә төшеп кимерәләр. Мунча кирәк аңа хәзер, мунча!.. Хәер, кан эчүче бу паразитлар хәлсезләнә башладылар соңгы вакытта. Саттарның канын эчкәнгәдер, стенада алпан-тилпән йөриләр. Алар бит, кан эчәбез, дип алданалар, чынлыкта спирт эчәләр. Саттар кайтып киткәч, макмырдан кырылып бетүләре дә бик мөмкин. Шундый нәрсә ул Минзәлә аракысы: эчкәндә каннарың да яңарып киткәндәй була,. әмма, эчеңә керми торса, җан тәслим кылгандай интегәсең...

... Эреп кенә китәм дигәндә, тәрәзә шакыдылар – иллюминатор пыяласын! Куркудан коты ботына төшкән Саттар күзләрен чытырдатып йомды. Катырак, шомлырак итеп тагын берничә мәртәбә шаңлаттылар иллюминаторны. Әллә шайтаннар да менеп җитә микән бу космос дигәннәренә?! Галлюцинация башлануы түгелдер бит, Ходаем!..

Йомылган күзләрен куллары белән дә каплаган иде Саттар, әмма станция эчендәге көчле яктылыкны барыбер шәйләде. Алай-болай ут чыкмагандыр бит?!

Күзен ачуы булды, тыштан шаку аралаш тавыш яңгырады:

– Саттар! Саттар!! Саттар, дим!!! Уян тизрәк, бетәсең! Сиңе харап итмәкчеләр!

Саф татарча эндәшәләр бит әле, җитмәсә! Тиз генә торып караса, ни күрсен, иллюминаторның теге ягында... түбәтәйле бер егет карап тора! Шундый көләч, шундый матур, мыегы медучилище директорыныкына охшаган. Ә үзе, аякларын салындырып, бик тә дәү тәлинкә читенә утырган.

Ләкин көләчлеге шундук югалды егетнең – Саттарны күреп алуга ук, җитдиләнеп китте.

– Айны, кардәш, тиз бул, монда чык! Җирдәге башлыкларың кислородны ябачаклар. Сине үтермәкчеләр!..

Чүт кенә скафандрсыз чыгып йөгермәде космонавт. Ләкин, акылына килеп, кия башлады. Шулвакыт станция эчендә нәрсәләрдер чыжларга, сызгырырга тотынды: әйтерсең лә, ниндидер машина камерасын кабарттылар-кабарттылар да, тиз генә ниппель, колпачок дигән нәмәстәләрен тыгып куйдылар.

Ләкин Саттар бер мизгелгә генә булса да алданрак өлгерде скафандрын кияргә. Ә скафандр эчендәге баллонда ярты сәгатьлек чамасы кислород бар иде әле.

Станциядән башын тыгуга ук аны кемнәрдер күтәреп алдылар. Ике-өч мәртәбә дә сулыш алырга өлгермәгәндер, үзен шундыен да пөхтә бүлмәдә күрде. Һавасы, гүя, Ык буе күләнеке. Эссе көндә тал күләгәсендә утырган сыман...

Ә каршысында, ошбу егеттән кала, тагын өч татар утыра. Барысы да сизелер-сизелмәс елмаялар, сизелеп тора, карашлары белән Саттарны барлыйлар. Чал төшкән түгәрәк сакаллысы, алдындагы чынаяктан сөтле чәй кебегрәк нәрсә йотып куйды да, ак сөлгене иреннәренә тигереп алгач, рәхимле генә көлеп куйды:

– Аллага шөкер, милләттәшебез исән калды. Шуның хакына, Аллаһы тәгаләнең кодрәтле вә рәхим-шәфкатьле булуы хакына дога кылыр вакыт та җиткәндер, балалар.

Алар дога кылганда Саттар да куш учы белән битен каплап утырган булды. Бу очракта да тамагыңны киереп, катлы-катлы сүгенеп кенә җибәрәсе булса, ул боларның барысыннан да уздырыр иде. Әмма нурлы, тыныч карашларыннан ук аңлашыла – болар, мөгаен, Русиядә әйтелә торган күп сүзләрне белмиләрдер. Кулланмыйлардыр...

Дога кылынып беткәч, битләр сыпырылгач, чал сакал иясе әкрен генә сүз башлады:

– Синең хакта сорашып тормыйбыз, кардәш. Без, Җирдәге һәр татарның тормышын, язмышын белгән кебек, синекен дә беләбез. Синең галәмгә очачагың турында Җирдән хәбәрләр яңгырый башлауга ук, һәр хәрәкәтеңне, һәр гамәлеңне күзәтеп тордык. Сездәге космик үзәкнең яшерен тыннары да безгә килеп тора, дип әйтүнең кирәге дә юктыр.

Чөнки без андагы һәр кешенең тавышын гына түгел, уе белән ниятен дә тыңлый алабыз. Менә бүген шул космик үзәк дигән мәкерле йортта синең хакта кыска гына сөйләшеп алдылар. "Әгәр бу татар шушы зур эшләреннән соң Җиргә төшсә, аңа кадәр очкан урысларның эше бер тиенлек тә булып күренмәячәк, диештеләр. Ә инде син җыйган чүп-чарны кайсыдыр ки кяфердән төшертмәкчеләр... Шуннан соң без тиз генә юлга чыгарга булдык...

Тын гына утырган Саттар Чал Сакалның сүзен бүлдерми кала алмады:

– Сез үзегез кайсы районнан буласыз соң... абзый кеше, дисәм, аерма зур түгелдер...

(Бүлмәдәгеләр, Чал Сакал сизмәгәе, дигәндәй, сәер генә елмаешып куйдылар.)

– Аерма зур, бик тә зур, улым. Йөз мәртәбәдән артык. Минем улларым туганда да сезнең бик ерак бабаларыгыз әле монда – Натсратат планетасында яшәп ятанлар иде. Төшереп өлгермәгән идек әле аларны. Әйе... "район" дигәнеңә дә җавап булды бугай – без моннан, сезнең сәгать белән исәпләгәндә, ярты сәгатьлек юл үтә торган планетадан. Син монда менгән ара безнекеннән миллиард мәртәбә кыскарак... Хәер, аз гына сабыр...

Ул ниндидер төймәгә басты. Шундук: "Мәскәү сөйли. Соңгы хәбәрләр тапшырабыз", – дигән аваз килде дә, музыка шыңгырдый башлады. Гаҗәпләнүе хәттин ашкан Саттар шул арада сорау бирми түзмәде:

– Кайчаннан бирле татарча сөйли башлаган бу Мәскәү?!

Чал Сакал да хәбәрләр башланганчы җавап биреп өлгерде:

– Без барлык телләрне дә тәрҗемә рәвешендә кабул итәбез.

Мәскәүнең беренче хәбәре үк, Минзәлә кешеләренчә әйтсәк, аяктан еккыч иде:

"Бүген галәмнән күңелсез хәбәр алынды – галәмсәфәр Саттар Гаттаров фаҗигале төстә үлде. Ләкин бу көтелмәгән үк хәл түгел иде. Инде дөньяның хәлхәбәр чараларыннан мәгълүм булганча, ул корабка бик күп аракы тутырткан иде. Шунлыктан, бер файдалы эш тә кыра алмыйча, елга якын эчеп ятты. Табибларның әйтүенә караганда, йөрәге тотып, баш миенә кан савып үлгән. Бу җәһәттән, Илбашының катгый белдерүе дә мәгълүм булды. Ул: "Татарлар эчкече, ялкау һәм табигый яктан зәгыйфь булганлыктан, киләчәктә мондый хатаны кабатламаячакбыз", – дигән. Гаттар Саттаров ел буе эшли алмаган эшне урыс галәмсәфәре Иван Вольфович Шнайдер бер атнада башкарып чыгарга ниятли. Ул галәмдәге барлык чүп-чарны җыеп, Минзәлә читенә алып төшәргә вәгъдә бирә. Аларның ягулык калдыкларында радиация нормадан миллион ярымга артыграк булганлыктан, Минзәлә халкын Соловкига күчерү каралган. Иван Вольфович китәчәк корабка бер атнадан старт бирeләчәк!."

Инде айнып беткән Саттарның каны кабарганын, бу хәбәрне ярсулы нәфрәт белән тыңлаганын әйтеп торуның кирәге бар микән? Ул: "Оятсызлар! Мин үлмәдем, мин монда!" – дип сикереп тормакчы иде дә, Чал Сакалның салмак, тынычландыргыч соравын ишетте:

– "Радиация" дигәнен генә аңламадым. Анысы нәрсә икән тагын?..

– Агу ул! – диде Саттар һәм сүгенеп куймакчы иде, кайда, кемнәрдә булуын абайлап, телен тешләде.

Шулчак Чал Сакал егетләрнең берсенә боерык биреп өлгерде:

– Габделәхәт углым, Мәскәүдәге гөнаһсыз бәндәләргә агудан саклану әфсенен җиткер. Ә син...

– Ул икенче ягында утыручы иргә борылды. – Ә син, Габделхәмит кияү, Саттар тутырган җәтмәне Мәскәүдәге Кремль ишек алдына төшереп әй. Үз нәҗесләрен үзләре иснәсеннәр! Акылга утыра башлаулары хәерле булыр. Күп түздек – җитте! Ә без ошбу кораб белән Саттар оланны Минзәләсенә илтеп куярбыз.

Ике ир-егетнең коридор сыманрак уемтыкка кереп югалуы булды, Чал Сакал каршында утырган улына әйтеп куйды:

– Киттек, Габделбәр углым. Абыең белән җизнәңә хәбәр җиткер. Утыз сулыштан соң монда булсыннар. Сиңа да сүзем бар Саттар олан: агулы илдә яшәп, агу эчеп йөрмә. Татар халкының тәгаме түгел ул. Бүтән милләт өлешенә кермә – үзләре ризыклансын ул эчемлек белән.

Чал Сакал авыр сулап алды да, өстәп куйды:

– Без сезнең авыр тормышыгызны аңлыйбыз. Кирәк тапсак, бер сулышта дөньягызны ямьли алабыз. Ләкин үзегезнең акыл туплавыгызны телибез. Бабаларыгыздан башлап бердәм булмавыгыз харап итә сезне. Шуңа күрә без, сезне чыныктыру, гыйбрәт алдыру, сынау өчен, урыс дигән кавемне дә уйлап таптык. Чөнки без теге заманда үз планетабызда гөнаһ кылган татарларны төшергән идек Җиргә... Ярый, сау бул. Без сине онытып бетермәбездер...

"Әле юл озын, бик күп сүз сөйләшеп кайтырбыз", дип өметләнгән иде Саттар. Баксаң, ул авызын ачып өлгергәнче дәү тәлинкәнең ишеге ачылып китте.

– Синең туган илең шушы. Аны бәхетле итәргә тырыш!

Саттарның баш өстендә генә җил сызгырып алгандай булды һәм ул кычкырып җибәрә язды: як-ягында яшел алан, ә алдында бинихая зур ят шәһәр иде.

Әйе, ул:

– Абзыкаем, ялгыш чит шәһәргә төшергәнсез бит! Кайтырга бер тиен акчам да юк минем! – дип кычкырмакчы иде. Әмма ике-өч чакрымда гына Дамбы күперен күргәч, шым булды. Балачактан ук күзгә, күңелгә газиз булып сеңгән күпер иде бу!

... Шулай итеп, кадерле укучым, сезгә дә, миңа да беренче татар космонавты Саттар Гаттаров белән аерылышыр вакыт җитте. Ләкин, күңеләмә бик авыр булса да, тагын бер-ике сүзне әйтеп бетерү мәслихәттер...

– Үлгән кешегә без нинди акча бирик! – дип, Саттарга вәгъдә ителгән минималь хезмәт хакын бирмәделәр. Ул үзе:

– Менә бит мин! Исән бит! Таныйсыз бит! – дип тәкрарлап караса да, бер тиен дә бирмичә кире бордылар. Артыннан:

– Әйе, таныйбыз, исән икәнеңне дә күрәбез. Ләкин сине Мәскәү тиклем Мәскәү үлдегә санаган икән, без аның сүзеннән уза алмыйбыз, – дип калдылар.

Аны бөтен шәһәрдә бер кеше генә санга сукты, хәлен аңлады. Ул – йортлар идарәсе башлыгы Исмай Галләметдинов иде. Саттарны күпме генә иске эшенә алырга тырышса да, файда чыкмады. Шәһәр башындагы түрәләр, кырт кисеп, Исмайның тетмәсен теттеләр:

– Башың бармы синең?! Шушындый гүзәл шәһәрне себерергә шундый шыксыз бәндәне урамда йөртикме?! Хәерче бит ул, бердәнбер хәерче! Аңлыйсыңмы шуны! Безнең күркәм шәһәребезнең юлларын бары тик сылу кызлар чистартып торачак!

... Бер эш тә тапмагач, Саттар атна буе урман-кырларда, болыннарда каңгырап, елап йөрде-йөрде дә, шәһәргә кайтып, үзенә салынган һәйкәл төбенә хәер сорашырга утырды...

Иҗтиһат

Вагыйдуллин мәктәбе

Илдус ВАГЫЙДУЛЛИН – 35-40 яшьләр тирәсендәге якты йөзле, терекөмеш кебек хәрәкәтчән мөлаем бер кеше. Арча Үзе Балтач районының Куныр авылында туып үскән. Казан педучилищесын кызыл дипломга тәмамлагач, Казан университетының тарих факультетына укырга керә. Хезмәт кенәгәсендәге беренче язма да шул елларда теркәлә: каравылчы һәм мич ягучы. Авылда эшкә өйрәнеп үскән егет студент елларында акчага аптырамый, аена 130ар сум акча ала, әле әти-әнисенә, туганнарына да ярдәм итә. Аның каравы, 70 сум хезмәт хакына эшли башлагач, "бай" вакытларын сагына.

Илдус алты балалы ишле гаиләдә үсә. Әтисе Вагыйдулла абзый – сугыш ветераны. Әниләре Нәгимәбану апа колхозда эшли, балаларын тәрбияли. Гаиләдә һәркемнең вазифасы билгеле. Малайлар идән юалар, кер уалар, печән чабалар, сыер савалар. Атна-ун көн эчендә гаиләләре белән бишәр-алтышар гектар борчак чабалар. Һәм хезмәт, нужа, ишле гаилә, соңыннан комсомол мәктәбе үткәннән соң Илдус Вагыйдуллиннан коеп куйган мәктәп директоры килеп чыга. Аның тәвәккәллек, куйган максатына ирешү өчен тау-ташлар актарырга әзер торуы балачактан ук тәрбияләнгән сыйфатлар.

● *Мәктәпнең Тукай бүләге иясе, Чаллы пединституты галиме Хәниф Хәкимов.*

● *Тукай бүләге ияләре Мәүлиевләр гаиләсе; Миләүшә Нәҗметдинова (аста).*

"Сигез ел җүнләп йокы күргән юк"

Кызыл диплом иясе, Ленин стипендиаты, иң актив студент, университетны тәмамлагач ук яраткан эшенә керешә алмый. Башта комсомолда, аннары төрле җитәкче урыннарда эшли. Ул арада 10-15 ел үтеп тә китә. 1989 елда Илдус Вагыйдуллинны альтернатив нигездә Чаллыдагы 29 нчы мәктәп директоры итеп сайлыйлар. Яшь директорны җәлләүчеләр дә табыла: "Озак эшли алмас. Ашыйлар инде моның башын", – диләр, чөнки коллектив ул чагында әллә ничә төркемгә бүленгән була. "Нинди генә эшкә тотынмасын, ахырына җиткерә. Төймә төяргә алынса – аны да булдырыр иде. Туры сүзле. Таләпчән. Вакыты белән кырыс та була. Эшләгән кешенең эшен күрә, бәяли белә. Берәр бала коридорда, класста сызган-бозган икән, гаепләне тапмыйча калмый, үзеннән төзәттерә, "болай эшләргә ярамый", "мәктәп – синең туган йортың" төшенчәсен канына сеңдерә".

Бүген коллегалары Илдус Вагыйдуллинга шундый характеристика бирәләр. Әйе, берничә ел эчендә мәктәп тә, коллектив та танымаслык булып үзгәргән. Биш ел элек мәктәп "Татар педагогик мәктәп-лицее" статусын ала. Биредә хәзер меңнән артык укучыга йөздән артык мөгаллим белем бирә.

Мәктәп килеп керүгә үк сине үзенә җәлеп итә. Һәркайда милли рух. Коридорларда үзеңне музейдагы кебек хис итәсең. Бер залга шәмаилләр куелган. Татар театрлары тарихы залында барлык милли театрлар турында тулы мәгълүмат алырга була. Танылган актерлар портретлары эленгән. Картиналар галереясе ачылу да кызыклы: мәктәпне тәмамлаган һәр класс берәр картина бүләк итеп калдыра икән. Хезмәт залы, Дан залы. Аларның һәрберсе югары зәвык белән эшләнгән, төрлесе төрле яктан татар халкының рухын ачып бирә. Шунысы мөһим: аларны бизәүдә директор үзе дә укучылар, укытучылар, ата-аналар белән бергә катнашкан.

Дан залын гына алыйк. Биредә Бөек Ватан сугышында катнашучыларның исемнәре, фотостендлар гына тезелмәгән, татар халкының гасырлар буена сузылган азатлык өчен көрәше сурәтләнгән. Бәйсезлек өчен көрәшкән каһарман бабаларыбызның исемнәре, Советлар Союзы Каһарманнары арасында да татар фамилияләре генә язылган.

Залларның берсендә 1959 елда БМО кабул иткән "Бала хокуклары декларациясе", Милли Мәҗлес концепциясе буенча эшләнгән "Татарның әхлак кодексы" һәм "Гаилә кодексы" да бар. Илдус әфәнде һәрдаим эзләнә, көндәлек матбугатны күзәтеп бара, укытучы, мәктәп, бала файдасына эшләрдәй бер генә мөмкинлекне дә күз уңыннан ычкындырмый.

"Боларның барысына ничек өлгерәсез дә, каян акча табасыз? – дигәч, "Сигез ел җүнләп йокы күргән юк инде", – диде ул. Һәм шул сүзләрдән барысы да аңлашылды: сиңа берәү дә башкалардан артык акча бирми, барысына да үзеңә чабарга кирәк.

Тарих – укучыларның иң яраткан фәне. Һәр чыгарылыштан ел саен 6-7 укучы Чаллы, Казан, Алабуга вузларының тарих, фәлсәфә, юридик факультетларына укырга керә икән, бу – укытучы хезмәтенә иң зур бәя. Илдус Вагыйдуллин җитәкчелегендә менә өченче ел инде республика күләмендә тарихи темаларга фәнни-гамәли конференцияләр уздырыла. "Каһарманлык гасырларны кичәр, яңа буыннарны уятыр", "Древние тюрки в истории татар и русских. Факты, вымыслы, исследования" һ.б. темаларга уздырылган конференцияләргә төрле төбәкләрдән укытучылар килә. Мәктәп-лицей Чаллы регионында алдынгы тәҗрибә үзәге.

"Этнопсихология + этнофәлсәфә = этнопедагогика"

Менә берничә ел инде мәктәп-лицей үстерелешле укыту проблемалары белән шөгыльләнә. Бу алдынгы ысул авторы – Уфа галиме Рәхимов. Биредә ел әйләнәсе шәһәр, республика күләмендә семинарлар үткәрелә, ачык дәресләр бирелә. Баланың иҗади халәтен, белемгә омтылышын, теге яки бу теманы үзләштергәндә ахыргы нәтиҗәне күрү укытучыга бик мөһим. Ул баланың теманы ни дәрәҗәдә үзләштерүен белеп шунда ук ярдәм итә ала. Меңнән артык укучының яртысы "4"ле, "5"ле билгеләренә генә укый, мәктәпне тәмамлаучыларның 60-70 проценты махсус һәм югары уку йортларына керә. Узган ел бу сан 88 процентка җиткән. Наилә Сәлахова, Дамира Йосыпова, Рәиф Мостафин, Гөлкәй Вәлиуллина, Мөслимә Нуриева, Резедә Смакова, Гөлия Хуҗина, Хөмзә Йосыпов, Лениза Дәүләтьярова һ.б. үз фәннәренә мөкиббән киткән һәм укучыларын да гашыйк иткән олы шәхесләр. "Милли мәгариф системасын үзебезнең тарихка, гасырлар буе формалашкан психология һәм фәлсәфәгә нигезләп корырга тиешбез", – ди Илдус әфәнде. Һәм аның сүзе эшләреннән аерылмый. Укучылар уйларга, югары фикер йөртергә өйрәнәләр.

Мәктәп татар халкының интеллектуаль потенциалын формалаштыру, милли мәгариф системасын үстерү һәм камилләштерү, югары уку йортларына кадрлар әзерләүне үзмаксат итеп куйган. Сүз дә юк, 8, 9, 10 нчы сыйныфларга үз мөхәлләләреннән (комплекс) генә түгел, бөтен шәһәрдән килгән укучыларның барысы да укытучы булмас, әмма милли рухта тәрбияләнеп татар җанлы ватандашлар булып үсәрләр.

Илдус әфәнде, "яхшы кеше", "начар кеше" модельләрен төзү буенча эшлим, диде. Мин уйга калдым. Кеше ак яисә кара, бик яхшы яисә бик начар гына була алмый бит, ул аклы-каралы, яхшылы-начарлы була. Әмма чиста көгазьдәй бала күңеле абстракт фикерли алмый. Яхшыны начардан аера башлагач, ул үзе үк күңелендә шундый модель төзи башлый. Әгәр укытучы, ата-ана аның фикерләрен дөрес юнәлешкә җибәрсә, акыллы киңәшләрен бирсә, үсмер бала яхшы кешенең дә, начар кешенең дә прогрессив үсеш юлын күзаллый һәм теге яки бу начар гадәтнең киләчәктә кая алып барасын анализлый ала. Бу җәһәттән мәктәп коллективы күптән нәтиҗәле эшли икән инде. Күз тимәсен, биредә җинаятьчелек юк. "Татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары" дигән махсус курс эшли, ә аның гамәли ягы төрле кичәләр, милли бәйрәмнәр уздыру белән тәгәлләнә. Өлкәннәр көне, "Әтиләр һәм уллар", "Пар канатлар" кичәләре, төрле йолаларны театральләштереп күрсәтү әйбәт традиция булып кереп бара. Һәр елны уразада әби-бабайларны җыеп авыз ачтыралар. "Мирас вә заман" концепциясе буенча, әйтик, "Коръән һәм Библиядә әхлак тәрбиясе" һ.б. темаларга фәнни-гамәли конференцияләр уздырыла. Мәктәп-лицейда 49 класс-комплект бар. Педагогларның интеллектуаль көче, иҗади эш-сәләте гаять югары. 103 укытучының икесе – тарихчы Илдус Вагыйдуллин һәм физик Рафаэль Шакиров – әйдәп баручылар. 16сы – методистлар, 36 кеше өлкән укытучы исемен йөртә.

Сабак түе

Юк, хата китмәгән, дөрес укыдыгыз. Менә биш ел инде укулар тәмамлангач бу бәйрәмдә коллектив эшчәнлегенә бәя бирелә. Гадәттә, язгы матур көнне табигать кочагында уздырыла торган бу чын хезмәт бәйрәменә, мәктәп белән гаилә бәйрәменә әверелә.

Саный китсәң, мондый бәйгеләр тагын да бар. Коллектив өч ел рәттән Бөтенрусия күләмендә "Ел мәктәбе", "Иң лаеклы мөгаллим", "Ел укытучысы", ә Илдус Вагыйдуллин "Ел директоры" дигән югары дәрәҗәле дипломнарга лаек булды. Соңгысында мондый дипломны укытучылардан Галия Хуҗина алды.

Татарстан Мәгариф министрлыгы Каюм Насыйри бүләгенә булдырган иде, быел мәктәп-лицей бу бүләккә дә ия булды.

Коллективның үз бүләге дә бар. Узган ел мәктәп тарихында Тукай бүләге ияләре барлыкка килде. Иң яхшы һәм актив, иҗат, фән белән шөгыльләнүче укучы, иң яхшы укытучы, балаларын милли традицияләр нигезендә тәрбияләүче үрнәк гаиләләргә бирелә мондый бүләк. Оешкан, бердәм коллективның максатчан тырышуы бушка китми, мәктәп-лицей яңадан-яңа үрләр яулый.

Рәсимә СИБГАТУЛЛИНА.

● *Мәктәп-лицейда авыз ачтыру. (Сулдан өченче Илдус Вагыйдуллин).*

Хуҗи МӘХМҮТОВ,
филология фәннәре докторы

Гыйбарәләр тарихына сәяхәт

Гали кылычы (пәкесе)

Мөхәммәд пәйгамбәрнең иң якын сәхабәләреннән берсе, 656-661 елларда идарә иткән дүртенче хәлифә Гали бине Әбу Талиб исеме белән бәйле әйтелмә. Гаять куәтле, батыр булганы өчен ул "Аллаһы арысланы" дигән кушамат йөрткән. Мөхәммәд җитәкчелегендәге барлык сугышларда диярлек катнашкан, Бәдер янындагы тарихи бәрелештә ул 16 тапкыр яраланган.

Бәдер сугышында мөселманнар кулына бик күп ганимәт (трофей) эләгә. Шулар арасында атаклы зөлфәкар ("арка умырткасын кисүче" мәгънәсендә) кылыч та була. Пәйгамбәребез аны үзенә ала. Мөхәммәд вафат булганнан соң бу кылыч мирас буенча Галигә күчә.

Легендаларда һәм риваятьләрдә, борынгы әдәби әсәрләрдә Гали кылычы гаять зур тылсым көченә ия итеп тасвирлана, үзе кирәк кадәр сузыла яки кыскара ала, искиткеч үткен була. Ул хәтта меңләгән дошман башын кискәч тә үтмәсләнүне белми.

Татар халкы арасында киң популярлык казанган "Кисекбаш" дастанында (Ш.Мәрҗани аны болгар чоры ядкяре дип саный) Галинең искиткеч зур каһарманлыгы сурәтләнә. Ул, тирән кое төбенә төшеп, Ислам диненең явыз дошманы, мөселманнарга күп җәбер-золымнар күрсәтеп яткан, үзе биек манара, бармаклары кеше гәүдәсе хәтле булган коточкыч дию пәриен үзенең зөлфәкары белән чабып үтерә, шуның өстенә аның 300ләп диюдән торган гаскәрен дә тураклап ташлый:

"Минди ташның үстүнә ол дәм вәли,
Чалды андин зулфикарны башына,
Кечти-китди ирде аның җанына,
Чүнки өлтүрди пәри девне Гали,
Тәңре арсланыдыр ул шаһ вәли.
...Галинең үстүнә девләр түштиләр...
Гали девләр башыны кесәр ирди,
Девләрнең йүзинә ол басар ирди,
Үч йүз девни өлтүрди
ол күн Гали".

XVI йөз татар шагыйре Мөхәммәдъяр да үзенең "Нуры Содур" поэмасында Гали кылычын "зарбындин булур өҗдәһа мур" (аның белән чабудан аҗдаһа һәлак булыр) дип сыйфатлап үтә.

Бүгенге әдәби телебезгә килсәк, "Гали кылычы (пәкесе)" тәгъбиренең күбрәк күчерелмә мәгънәдә, сурәт-тасвир чарасы буларак кулланып йөрүен күрәбез. Андый мәгънәләр берничә:

1. Ялтыр-йолтыр килеп, уйнаклап торган әйберләрнең, күренешләрнең чагыштырмасын тудыра:

"Урман артында нәҗәгай уйный
Гали хәзрәтнең кылычы кебек".
(Г.Афзал. Сайланма әсәрләр. – Казан. 1991. 101 б.).

2. Хезмәт (яки сугыш) коралының гаять үткен икәнлеген аңлата.

"Чабучылар ял иткән чакларда аларның чалгыларын таптап бирә иде... Ул (Мөстәкыйм карт) таптап биргән чалгылар Гали пәкесе булалар иде" (М.Әмир. Сайланма әсәрләр. 3 т., – Казан, 1967, 201 б.).

3. Н.Исәнбәт үзенең "Татар теленең фразеологик сүзлеге"ндә (1 т., Казан, 1989, 219 б.) күрсәтеп үткәнчә, кайбер очракта бу әйтем киресенчә, ироник мәгънәдә, үтмәс коралга карата әйтелә. Ул, Г.Әпсәләмовтан алып, мондый мисал да китерә:

"Гали кылычы икән бу пычак. Моның белән утын түгел, бәрәңге дә кисеп булмый".

4. Ниһаять, шулай ук Н.Исәнбәт күрсәткәнчә, тәгъбир бик үткен кешегә карата мисалдан да әйтелә: "... Гали пәкесе инде. Кая барса да эшен булдырып кайта торган үткен кеше".

Куян шулпасының шулпасы

Хуҗа Насретдин турындагы мәзәкләр җирлегендә туган гыйбарә. Башта шуларның икесе белән танышып китик:

"Хуҗаның әбисе белән бабасы моңа кунакка килгәннәр. Хуҗа аларны куян ите белән сыйлаган. Тансык аш әби белән бабайга бик ошаган. Өйләренә кайткач: "Бик сыйладылар", – дип, мактап сөйләгәннәр.

"Кияү юмарт кеше икән" дип, әбинең энесе дә хатыны белән кунакка килгән. Хуҗа аларны куян шулпасы белән сыйлаган. Шулпа да кунакларга ошаган. Артык сый булмаса да, кайткач: "Бик сыйладылар", – дип, болар да кеше арасында мактанганнар.

Моны ишетеп, Хуҗаның әбисенең энесенең хатынының сеңлесе дә ире белән парлап кунакка килгән. Хуҗа болар алдына табак белән су утырткан. Кунаклар аптырап:

– Бу ни була инде, кияү? – дип сораганнар.

Хуҗа:

– Бу – куян шулпасының шулпасы була. Әби белән бабай итен, әбинең энесе хатыны белән шулпасын эчтеләр, сезгә шулпасының шулпасы гына калды инде. Хәзинәдә бары, гаеп итештән булмасын, – дигән".

"Бер кеше Хуҗа Насретдинга бүләк итеп бер куян китергән. Хуҗа моңа бик шатланган һәм ул кешене үзендә кундырып, куян ите белән сыйлап җибәргән.

Берәр көннән соң бер кеше килеп хуҗада кунак булырга теләгән. Хуҗа аңардан: "Син кем буласың соң әле?" – дип сорагач, бу кеше: "Мин сиңа куян китергән кешенең күршесе", – дип җавап кайтарган. Хуҗа аны да өендә кундырып, калган куян шулпасы белән сыйлаган.

Биш-алты көннән соң тагын өч-дүрт кеше Хуҗага килеп кергәннәр. Хуҗаның: "Сез кемнәр буласыз?" – диюенә каршы алар: "Без сиңа куян китергән дустыгызның күршесенең күршеләре булабыз", – дигәннәр. Хуҗа аларны: "Бик яхшы, хуш килдегез!" – дип, түр башына утырткан һәм алларына бер табак су чыгарып куйган да:

– Рәхим итегез, җитешегез, кунаклар! – дип кыстый башлаган.

Кунаклар аптырашып:

– Бу нәрсә? Бу нәрсә? – диешә башлагач, Хуҗа аларга:

– Бу минем дустым китергән куянның шулпасының шулпасы! – дип җавап кайтарган".

"Куян шулпасының шулпасы" әйтелмәсенең ике төрле мәгънәсе күзәтелә:

1. Ул туганлык-кардәшлекнең, дуслык-танышлыкның бик ерак, әллә ничә кеше аркылы гына икәнлеген белдерә:

(Сафия Закирга): "Мәскәү кешесенең танышы булгач – (кияүгә) чыкмыйча соң! Куян шулпасының шулпасы диләрме әле. Нәкъ шуның төсле булды бу" (Ш.Камал. Әсәрләр. Өченче басма. 2 т., – Казан, 1952, 120 б.).

2. Теге яисә бу әйбернең, күренешнең, төшенчәнең эчтәлеге белән үзенең исеменә туры килмәвен, сыйфаты буенча түбәнгәрәк төшкән, начар якка үзгәргән булуын күрсәтә:

"Бу искәртүләрдән шул ачык аңлашыла: чыганаклар үзләре дә, (аларның)... кульязма-тәрҗемәләре дә сакланмаган икән. Укучыга Хуҗа Насретдин мәзәкләрендәгечә "куян шулпасының шулпасы" гына тәкъдим ителә". (Нил Юзиев. "Роман ачышмы, әллә..." – "Ватаным Татарстан", 1993, 7 май).

"– Ләкин шуны алдан белеп таныш, Сәлимов, бик интеллигентный кеше безнең Сәрвәребез. Революцияне ак перчатка киеп кенә ясамакчы.

– Революцияне безгә чаклы ясап өлгергәннәр инде, безгә куян шулпасының шулпасы гына калган..." (Фатих Хөсни. "Утызынчы ел". – Казан. 1980, 52 б.).

Нервыда уйнау

Төп чыгышы белән латин теленә караса да, бу фразеологик әйтелмә хәзер татар телендә дә актив кулланыла. Мәгънәсе "кемнең дә булса ачуын китереп, озак вакыт ошамаган нәрсә эшләү, сөйләнү, кәефенә тию" дигәнгә туры килә.

"Ул карт төрегә инде хәзер ике дөнья бер, ачудан барыр да... Кулга төшерә алмадым бит шул хатны. Мене хәзер шуңа аркаланып минем нервымда уйный инде ул.

Сәүбанның күңелендәге укыган кебек, бер читтән усал гына аңа караштырып утырды Галләм хаҗи" (Фатих Хөсни. "Утызынчы ел" – Казан, 1980, 175 б.).

Эчтәлеге белән өнә шундый шактый күңелсез вөзгыятьне гәүдәләндерүенә карамастан, "нервыда уйнау" гыйбарәсенең чын мәгънәсендә музыкаль тарихы бар.

Билгеле булганча, кешеләр әле бик борынгы заманнарда ук кыллы музыка кораллары ясарга өйрәнәләр. Латинча "кыл" сүзе "нервус" дип йөртелгән. "Нервыда уйнау" исә кыллы музыка коралында уйнау дигәнне аңлаткан.

Соңга табарак табиблар кеше организмында да "кыллар" булуын ачканнар һәм аларны да "нервлар" дип атаганнар. Телдә электән үк килә торган "нервыда уйнау" дигән сүзләр тора-бара һәм инде күчерелмә мәгънәдә – кеше нервыларына карата да кулланыла башлаган һәм образлы әйтелмә булып әверелгән.

Ни башына ни кунган

Бу гыйбарә сөйләгәндә кирәкле сүзне таба алмыйча, һич урынсызга "ни", "нитү" кебек сүзләрне күп куллана торган кешегә карата көлеп яки шелтәләп әйтелә. Халык иҗатында шушы вөзгыятьне тасвирлый торган төрле мәзәкләр дә бар.

"Бер "ни" белән сөйләүче аучы булган, ди. Бу аучы бер көнне ишек алдына чыкса, ни күзе белән күрсен – моның сарай башына кыр үрдәге килеп кунган! Аучы бу хәлгә бик каушап кала. Өйгә кереп мылтыгын алып чыгар иде – үрдәк очып китәр дип курка. Шуңа бу хатынына кычкыра башлый:

– Әй, карчык! Ни башына ни кунган! Тиз генә нине алып бир әле, нине нитеп нитием әле!

Билгеле инде, хатын иренең нәрсә сораганын аңлап, аңа мылтыкны чыгарып биргәнче, үрдәк очып та китә. Шуннан соң аучы, бик кәефе кырылып, хатынына әйткән:

– Их, карчык!.. Син нине ниткәнче ни башыннан ни нитте дә китте шул, – дигән".

Н.Исәнбәтнең "Татар халык мәкальләре" томында әлеге гыйбарә Мокыт сүзләре дип китерелә: "Ни башына ни кунган иде, ниткән идем – нитте дә китте, ни китерегез әле нитәргә!" – Янәсе, ул: "Киртә башына күркә кунган иде, куган идем – казыкка кадалды, пычак чыгарыгыз әле бугазларга", – дип әйтергә теләгән икән.

Матбугаттан мисалга Марсель Галинең "Үз теле бар" дигән шаян парчасын китерергә мөмкин ("Шәһри Казан", 1991, 18 апрель):

"Казан урамында композитор Зиннур Гыйбадуллин белән җырчы Рафаэль Сәхабиев очрашалар.

З.Г. Ниме... Ни бит син, чукынчык! Бик нитеп тордылар әле сине радиода. Мин дә ниттем. Минем теге нине нитәрсең инде. Нитмә, яме! Нитеп бетергәч, миңа нитәрсең дә... нитеп нитәрбез... Нигә тизрәк нитәргә иде бит!

Р.С. Ярар, ниткәчтеннән нитәрмен...

Тәрҗемә түбәндәгечә:

З.Г. Хәлләр әйбәтме?.. Шәп җырчы бит син, чукынчык! Бик мактап тордылар әле сине радиода. Мин дә макташтым. Минем теге җырны өйрәнерсең. Сузма, яме! Өйрәнеп бетергәч, миңа шалтыратырсың да... очрашып алырбыз. Радиога тизрәк яздырырга иде бит!

Р.С. Ярар, өйрәнгәч тә, хәбәр итәрмен..."

РЕДАКЦИЯДӘН.

АКШның Төньяк Каролина штатындагы Халыкара биография институты күптән түгел берничә татар галименә, шул җөмләдән Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты баш гыйльми хезмәткәре Хуҗи МӘХМҮТОВка "Ел кешесе – 1997" дигән мактаулы исем бирде.

Гәзитебезнең актив авторы Хуҗиәхмәт аганы тормышындагы бу истәлекле вакыйга белән ихлас күңелдән котлыйбыз һәм аңа яңа иҗади уңышлар телибез.

Әлеге дә баягы

Эш хакы түләмәсәләр, нишләргә?

Һәр кеше хезмәте өчен эш хакы алырга тиеш.

Гражданнарның бу хокукы ничек тормышка ашырыла соң? Башта шул хакта берничә сүз.

– Эш хакы һәр ярты ай саен түләнергә тиеш. Ешрак түләү – мөмкин, сирәгрәк – юк.

– Ялга киткәндә тиешле акча китәргә бер көн кала түләнә.

– Эш башыннан түләнә торган хезмәттә администрация, граждан эшкә алынып 5 көн узганчы, исәп-хисап кенәгәсен аның кулына бирергә тиеш. Исәп-хисап кенәгәсе (расчетная книжка) яки исәп-хисап язылган кәгазь (расчетный счет), кешенең башка вазифаларыннан тыш, эш хакының күләмен раслый торган документ та. (РФнең хезмәт турындагы законнар кодексы, 96 нчы маддә).

Эш хакы тоткарланса нишләргә?

Бу очракта башта хезмәт буенча бәхәс комиссиясенә мөрәҗәгать итеп, сезнең белән исәп-хисапны өзүне – тиешле акчагызны кичекмәстән түләүне таләп итегез. Комиссия 10 көн эчендә, тикшереп, җавап бирергә тиеш. Администрациягә комиссиянең карарына ризалык бирү-бирмәү буенча җавап тоту өчен 10 көн вакыт бирелә. Шуннан соң 3 көн эчендә комиссия карары җиренә җиткерелергә тиеш. (209 нчы маддә).

Әгәр бу вакытта сезгә тиешле акчагызны түләмәсәләр яки предприятиедә хезмәт буенча низагларны тикшерү комиссиясе төзелмәгән булса, судка мөрәҗәгать итәргә туры килә. Шунысын да истә тотыгыз: эшче һәм хезмәткәрләр эштәге мөнәсәбәтләр буенча таләпләре белән судка мөрәҗәгать итсәләр, дәүләт пошлинасы түләмиләр (РСФСРның гражданнар эшләре буенча процессуаль кодексы. 212 нче маддә).

Шуны белү дә файдалы: сезгә хезмәт хакын түләмәгән вакыт эчендә гаиләгездә финанс кыенлыклары килеп чыкса, мәсәлән, гаиләгездән берәү авырып китсә, дару алырга акчагыз булмаса, сезнең мораль яктан зыян күргәнегез өчен матди чыгымнарны каплауларын таләп итәргә тулы хакыгыз бар. (Гадәттә, моның өчен 5-10 миллион сум күрсәтергә ярый).

Судка ничек гариза язарга?

Мораль яктан килгән зыянны каплату таләп ителгәндә, дәүләт пошлинасын түләргә кирәк булачак. Әмма, мораль зыян өчен нинди сумма күрсәтсәгез дә, дәүләт пошлинасы айлык эш хакының 10 проценты күләмендә генә түләнә. (Бу очракта 8349 мең сум).

Дәгъва гаризасы 3 данәдә языла. Шул гаризалар белән судьяга барырга һәм гаризаларның 2 данәсен һәм башка кирәкле документларны аңа тапшырырга кирәк. Сезнең кулга дәгъва гаризагызның кабул ителүе турында билгеләмә бирелергә тиеш.

РСФСР гражданлык процессуаль кодексына туры китереп (89 нчы маддә), судья сезнең эшне карауны 7 көннән дә соңга калмыйча төгәлләргә һәм, дәгъвачы белән җавапка тартылучы бер шәһәрдә, районда яшәсәләр, 10 көн эчендә карар чыгарырга тиеш.

Суд карары (җавапка тартылучы тарафыннан суд карарына риза булмыйча югары органга шикаять бирелмәсә), хөкем чыгарылганнан соң 10 көннән дә соңга калмыйча үз көченә керә.

Аннан соң судның рәсми башкару кәгазе нигезендә гражданның хезмәт хакы суд башкаручысы аркылы предприятиенең исәп-хисап счетыннан алына һәм, паспорт күрсәткәннән соң, документка кул куйдырылып, кулына бирелә.

("КП").

"Бүре кебек көчле бул, барс кебек җитез бул"

Күптән түгел Германиядә оригиналь фильмнар фестивале булды. Анда барлык кыйтгалардан килгән яшь авторларның йөздән артык фильмы күрсәтелде. Фестиваль якташларыбыз – Казан журналистлары Нәфисә һәм Руслан Умаровларның "Чеченцев древняя земля" дигән фильмы белән ачылды һәм тамашачыларның да, жюри әгъзаларының да мәхәббәтен казанды, югары бәягә лаек булды. Һәм әлеге нәфис-публицистик-документаль фильм авторлары киләсе елда Һолландиядә узачак, тагын да дәрәҗәлерәк форумга чакыру алдылар. Ул форумда милли проблемалар беренче планга куелачак.

Фильм ике яшь тележурналистның (үзләре үк оператор, режиссер һәм продюсер да) 1992 елдан алып бүгенгәчә Ичкериядә булган фаҗигаләр хроникасын төшергәндә туган уйланулар, үзләре, гаиләләре кичергән михнәтләр нәтиҗәсе дияргә мөмкин.

Чичәннәрнең борынгы исеме – нохчи. Һәм фильм нохчиларның борынгы риваятенә нигезләнеп эшләнгән. Борын-борын заманда Тәңре халыкларга җир бүлгәндә нохчилар аның хөрмәтенә бәйрәм итеп соңга калалар. Җирләр инде бүленеп беткән була, һәм Тәңре аларга үзе яшәгән Кавказ тауларын бүләк итә. Шуннан бирле бу горур халык тауларда яши һәм начар ният белән килгән теләсә нинди баскыннарны үз иленнән куып чыгара.

Фильм, риваять белән тыгыз үрелеп, тамашачыны бүгенге көн проблемаларына алып керә. Русиядә хәзер иң кискен проблема – милли мәсьәлә, чөнки милләтләрне үстерү сәясәте юк, киресенчә, юкка чыгару сәясәте бик астыртын рәвештә, төрле юллар белән дәвам итә.

– Моны бик күп мисаллар белән раслап булыр иде, – ди Руслан Умаров. – Мин бары чичән фаҗигасен генә әйтәм.

Риваятьләр нохчиларның оча торган халык икәнлегенә дә ишарә ясый. Мәхмүт Эсәмбаев шулар токымыннан, күрәсең. Чичәннәрнең беренче Президенты Җәүһәр Дудаев та очучы иде бит. Лачын йөрәкле чичән халкы бу сугышта күп халкын югалтса да, рухын саклап кала алды, чичән анасы баласын "лачыным, син, бөркетем" дип сөя, "бүре кебек көчле бул, барс кебек җитез бул" дип теләкләр тели.

Без фестивальгә алып барган фильм "Белая дорога в черный сад" дип исемләнгән триптихның икенче кисәге. Беренчесе "Дети Карабаха" дип атала, өченчесе Татарстанның дәүләт мөстәкыйльлегенә багышланачак.

Рәсимә СИБГАТУЛЛИНА.

● *Нәфисә һәм Руслан Умаровлар.*

А й-һай!..

Бишектә... сөннәтләнү

Мин кечкенә чакта җәй көннәрендә читтән, ерактан безнең авылга кунакка малайлар кайткалый иде. Әлбәттә, ул малайлар татарча сөйләшә белмиләр һәм сөннәткә дә утыртылмаган булалар иде. Чөнки аларның йә әниләре марҗа, йә әтиләре урыс була. Һәм шул малайлар су коенган җирдә безне, "чаплашки", "обрезанные", дип мыскыллыйлар иде. Һәм без, шул "урыслар"ның мыскыл итүләреннән оялып, көннәр буе су коенырга интегеп йөри торган идек!..

Аннары, миңа унике яшь тулгач, Казан мунчаларының берсендә, урыслардан оялып, чишенми утыруым хәтеремдә калган. Чишенсәм, алар мине уратып алып, "Эй, чаплашка, обрезанный", дип мыскылларлар сыман иде. Мәгәр шулай да, чишенеп, ниһаять, мин эчкә кердем. Кердем дә шаккаттым: мунчада юынучы урысларның күпчелеге сөннәткә утыртылган иде!

Бу хәлнең серен мин ул чакта белмәдем дә, аңламадым да. Мондый тамаша минем өчен алга таба да байтак еллар буена сер булып саклапды.

* * *

Егерме өч яшьтә мин Югары Ослан районындагы Коргуза дигән чиркәүле урыс авылында кибеттә сатучы булып эшләдем. Бу төбәккә килеп чыгуымның тарихын сөйләп тормыйм, аның өчен аерым бер мәкалә язарга кирәк.

Мин менә Коргузада, Иван агай өендә кичкене ашагач, бик бирелеп отчет төзеп утырам. Күз алдымда – көндез кибеттә булган хәлләр, колагымда – урыс, марҗаларның гөрләшкән тавышлары, ә күңелем исә Казанда, дусларым, туганнарым янында!.. Әнә, күрше кызы Валя тәрәзәгә чиртә, мине клубка чакыра – баш тартам, чөнки анда мөселман кызлары юк шул! Ә болар... Мин бит әле, ни әйтсәң дә, теге "чаплашка", "обрезанный", дигән сүзләрне онытмадым: чыгаммы соң, Алла сакласын!.. Аннары әле иртәгә таңнан торып, совхоз директоры янына трактор сорарга барасы бар. Чөнки рабкооб урнашкан Мәйдан авылына, отчет илтү өчен, 18 чакрым билдән кар ерып барып булмый лабаса! Ә кайтканда, билгеле инде, тауар-фәләннәр дә төяргә кирәк булачак. Кыскасы, мин бу мизгелдә муеннан эшкә чумган, мине хуҗаларның тынычта калдырулары хәерле. Аһ, шулай булса икән ул! Ләкин юк шул. Әнә, хуҗаның Кильдеево авылыннан кунакка килгән кызы күрше бүлмәдә яңа гына елап уянган баласын, "Вон, татарин идет, не плачь!" дип куркыта. Бала, мескен, "татарин" дигән сүзне ишеткәч, шундук тынды. Ә мин, киресенчә, эчемнән генә аптырашта калдым. Чынлап та, мин туган татар авылында да, бишектә бала елый башласа, баланы куркытып, елавыннан туктатыр өчен, "Ай, харап, әнә, урыс килә", дип әйтә торганнар иде ич! Һәм яши торгач, мин бу авыл кешеләре холкында үзебезнең татар-мөселман авылында яшәүчеләр холкының чагылышын да көзгедәгедәй ачык күрдем. Барысы да шулай, тик телләре генә менә...

Аннары тагын бер кызык хәл: мондагы урыслар Майдан, Кильдеево, Макулово, Сеитово, Куралово һ.б. татар исемле авылларда яшәп яталар. Ә бер авылның тавында моннан биш йөз ел элек салынган агач мәчет тә басып тора әле. Хәер, мин үзем дә Лаеш районында, халкының күпчелеге саф мөселман булган чиркәүле авылда мәктәп тәмамлаган идем бит!..

Мин менә шундый хисләр кичереп, отчет төзеп утырганда, өйгә шактый гына кызмача бер урыс килеп керде. Башында иске мутон бүрек, өстендә ямаулы бушлат, аякларында кирза итекләр, тапланып беткән сырлаган чалбарының бер кесәсеннән ак чалмалы "урыс малае" да карап тора.

Кунак исәнләште дә, аягын да салып тормаган килеш, мич янәшәсендәге урындыкка урнашты. Аны инде кибеттә күргәләгән бар. Ул, үзенең әйтүе буенча, Казан университетында ике факультет тәмамлаган, икесендә дә көндез укыган, уку алдынгысы булган, аннары кайсыдыр районда – юрист, туган авылында мәктәп директоры, совхоз җитәкчесе булып эшләгән. Һәм... менә, ниһаять, ул бүген фермада кул көче таләп итә торган хезмәттән дә азат ителгән, ягъни аны эштән куганнар. Чөнки аның аек чагы юк. Әнә, бу юлы да кесәсенә хәмер тыгып кергән ич.

Хуҗа белән хуҗабикә, аның ни әйтәсен чамалагандай, читкәрәк китеп утырдылар. Күзләре тонган Владимир (кунакның исеме шундый) турыдан-туры миңа эндәште:

– Әйдә... бүген өйләнәбез, дядя Ванядан ат җиктерәбез дә, Борындыкка барып, ике татар кызы урлап алып кайтабыз... – Аннары ул кесәсенә сугып куйды. – Менә... аракы да бар!..

Сүзгә Нюра түти кушылды:

– Татар егетләре куып тотса, кыйнап үтерәләр ич сезне...

Мин исә, Володяга:

– Син бит христиан кешесе! Нәрсәгә сиңа мөселман кызы? – дидем.

Володя урыныннан сикереп торып:

– Я тоже мусульманин – обрезанный – значит, мусульманин! – дип күкрәк сугарга кереште.

Мин, әлбәттә, аңа ышанмадым, шыттыра бу борчакны, дип уйладым. Ә Ваня агай, киресенчә, Володяны яклап:

– Да, да, он обрезанный! И я тоже... – дип җөпләп куйды.

Мин аларга сынап карадым: әйе, алар шаяртмыйлар төсле, йөзләре үтә җитди иде. Һәм, ниһаять, Нюра түти минем шикләремне тәмам таратып ташлады:

– Вообще-то, у нас половина деревни обрезанные! – диде ул бу хәлгә бер дә исе китмәгәндәй.

Шулай итеп, минем күңелем иләсләнеп китте, җанымны үтә зур кызыксыну биләп алды. Һәм мин аларга бер-бер артлы сораулар бирергә керештем. Ниһаять, сөйләшә-аңлаша торгач, шул ачыкланды: бу авылга бернинди дә сөннәтче бабайлар килми, һәм андый бабайларны алар чакырмыйлар да, мәгәр ир балалар бишектә ятканда, имеш, үзләреннән-үзләре сөннәтләнәләр икән! Бу хикмәтле хәл турында миңа хуҗабикә ул чакта, "фәрештәләр эше", дип аңлатты. Ә бүген исә имам-хатыйплар андый хикмәтле хәлләр турында, "Бу – Аллаһы Тәгаләбезнең эше, башка беркемнеке дә түгел", дип кенә җибәрәләр...

Мансур ШАҺИМӘРДӘН.

1998 елда орлыкларны чәчү һәм үсемлекләр утырту өчен ай-кояш календаре

Орлыкларны чәчү һәм үсемлекләрне утырту, күчереп утырту өчен тыелган көннәр	Гыйнвар	Февраль	Март	Апрель	Май	Июнь	Июль	Август	Сентябрь	Октябрь	Ноябрь	Декабрь
	28; 29	24–27	23–25; 28	20; 21; 26	17; 18; 25	13–15; 24	11; 12; 23	7; 8; 22	3–5; 20	20; 28; 29	19; 24–26	18; 22; 23
Орлыкларны чәчү һәм үсемлекләрне утырту, күчереп утырту өчен уңай көннәр												
Карбыз, кавын	3; 11; 12; 30	7; 8; 27	7; 8	3; 10; 30	1; 7–9;8;29	4; 5; 25	3; 4; 30	1; 25–28	6; 21–23	3; 4; 21; 31	3; 27; 28	1; 2; 24;28; 29
Баклажан, кабак, ташкабак, патиссон	11; 12	7; 8	7; 8	3; 4; 12; 30	1; 7; 8; 28; 29	4; 5; 25	1–4; 29–31	1; 25–29	21–25	3; 4; 20–22	27–28	24; 25
Бакча борчагы	3; 4; 11; 31	3; 4; 8	2; 3; 7; 31	3; 4; 27; 30	1;7;8;28; 29	4; 5; 25	1–4; 28–31	1; 25–29	21–25	3; 4; 30; 31	3; 4; 27; 28	1; 2; 28; 29
Борчак, фасоль	7; 11; 12	7; 8	3–7; 30	1–4; 27–30	1;7;8;26–29	4–7; 25	1–5; 28–31	1; 25–29	21–25	3;4; 21;22;30	3; 27; 28	1–3; 24; 25
Ак һәм төсле кәбестә	3; 30; 31	7; 8	3; 7; 30; 31	3; 4; 27	1;7; 28; 29	4–9; 25	3; 4; 9; 29	1;5;6;25–28	26; 28–30	3; 4; 26; 27	3; 22; 23; 28	1; 2; 20; 21
Кызыл һәм брюссель кәбестәсе	7; 8	7; 8	17–22	3; 4; 30	1; 28; 29	9; 25	6; 7; 30	2–4; 29–31	5; 6; 26; 27	23–25;30; 31	20; 21;27; 28	24; 25
Кукуруз	7; 11	7; 8	2; 3; 8; 30	3; 4; 30	1;10; 28;29	6–8; 25	3; 4; 31	1; 28; 29	23–25	3; 22; 31	27; 28	1; 2; 24; 25
Кыяр	3; 30; 31	7–9	7; 8	3; 4; 30	1; 28; 29	6–8; 25	3–5; 31	1; 27–29	5; 23–25	3; 4; 21	27–28	24; 25
Татлы борыч	11; 12	7; 8	7; 8	3; 4; 30	1; 28; 29	9; 25	6; 7	2–4; 30; 31	26; 27	23; 30; 31	21; 27; 28	24; 25
Ачы борыч	5; 6	1; 28	1; 29	5; 6	10	6–8	3; 4; 31	1; 27–29	23–25	21–23	1; 2; 22	20; 26
Петрушка	3; 30; 31	3; 4; 7	3; 7; 30; 31	3; 4; 9; 30	1; 8; 9; 29	9; 25	1–4; 29–31	1; 26–29	6; 23–25	3; 30; 31	3; 27; 28	1; 28; 29
Көнбагыш	3; 30	10; 11	9; 10	4–7	1–4	25–27	24; 25	27; 28	24; 25	22; 23	21; 28	24; 25
Рәваҗ, җир җиләге	12; 21	17–19	14–17	12–14; 22; 23	11;20;23; 24	16;17;20;21	13;14;21; 22	10;18;	19	7; 14; 15	7; 8; 11; 12	8;9;15;5; 6; 15
Салат, шпинат	3–6; 30; 31	1–4; 28	1–3; 29; 30	3; 4; 10; 30	1; 7–10; 28	4–8	1–5; 29–31	25–29	21–25	3; 4; 30; 31	1; 2; 28–30	1; 2; 24–28
Томатлар (помидор һ.б.)	3–8	1–4; 8	1–3; 7; 8	3; 4; 30	1; 7–10	4–6; 25	1–4; 29; 30	1; 25–28	21–25	3; 4; 21; 22	1–3; 27; 28	1; 2; 24; 25
Суган	21	17–20	17–22	13–18	11–16	11;12;18;19	9; 10;15; 16	11; 12	8; 9	5; 6; 20	17; 18	14–16
Бәрәңге	12; 18–22	15–18	14–18; 21	13–18	15;16;23; 24	11;12;20–23	9;10;17;18;22	13;14;18; 19	10;11;14;15	7;8;11;12;18	7–9; 15; 16	5; 6; 12–15
Кишер	18–21	15–18	14–18	11–14	19; 20; 24	16;17;20; 21	13;14;17;18	10; 18; 19	7;10;11;14	7; 8; 11; 12	7–9; 15–17	5; 6; 12–16
Төче торма	18–22	15–18	14–20	12–17	12–16	11;12;20; 21	13;14;17;18	13; 14.18;19	10;11;14;15	7; 8;11; 12	7–9	14–17
Ачы торма	18–22	15–18	14–18	12–14	15;16;19; 20	16–20	13–17	10–14	8–11	6–8; 11; 12	7–9; 15	5; 6; 14–16
Чөгендер	19–22; 26; 27	15; 18; 22; 23	14; 17; 21; 22	12–14; 18; 19	15;16;19;20	11;12;17; 20	9; 14; 21;22	9;10;18; 19	10;11;14;15	11; 12; 19	7–9; 17; 18	5; 6; 14–16
Сарымсак	21–24	17–20	17–20	13–17	12–14;21–23	18–19	15;16	11; 12	8; 9	6–8	17; 18	14–17

Искәрмә

Календарь Мәскәү вакытыннан 3 сәгатькә кадәр аерма булган төбәкләрнә истә тотып эшләнгән. Әгәр вакыт аермасы аннан күбрәк икән, саннарның урта өлеше алына. Мәсәлән, 25тән 28енә кадәр, дип әйтелә икән, 26сы һәм 27се уңай көннәр.

Календарь теплица хуҗалыклары һәм тәрәзә төбендә ел дәвамында яшелчә үстерүчеләр өчен бик уңайлы.

Агач үсемлекләр, үсентеләр өчен календарь туры килми.

Тормыштан туйган балалар

Соңгы вакытта Мәскәүдә мордар китүче балалар саны арта бара. Бер тәүлек эчендә генә дә башкаланың көнчыгыш регионында өч мәктәптә укучы малай үз фатирларының тәрәзәсеннән урамга ташланып үлделәр. Беренче шундый очрак Щелково автотрассасы тирәсендәге бер өйдә булды. 14 яшьлек малай 18 нче каттагы үз фатирлары балконыннан түбәнгә ташланды. Сәбәбе – билгесез калды. Малай бай гаиләдән, иптәшләре белән дә, өйдә дә конфликт булмаган. Соңыннан малайның дәрес әзерли торган өстәленнән язу табыла. Соңгы сүзендә малай туганнары белән саубуллаша, тормыштан туюы һәм инде яшисе килмәве турында яза.

Уставтан тыш җинаятьләр

Хәрби прокуратура армиядәге уставтан тыш мөнәсәбәтләрне (дедовщина) бетерү максатыннан җитди чаралар кулланырга ниятли. Чөнки соңгы 9 ай эчендә генә дә, 1996 елның шул чоры белән чагыштырганда, РФ кораллы көчләрендә "уставтан тыш" җинаятьләр 22,9 процентка үсте, шул исәптән тимер юл гаскәрләрендә – 40 процентка, гражданнар оборонасы гаскәрләрендә 2 мәртәбәгә артты.

Ә иң югары күрсәткечләрне һавадесант гаскәрләре куйды: биредә 1997 елда үзара канлы бәрелешләр 8 мәртәбәгә артты. Бу саннарны бик үк дөрес тә түгелдер, диләр. Чөнки гаскәр җитәкчеләре үз кул астындагы гаскәрләрдәге "дедовщина" җинаятьләрен яшереп калдырырга тырыша. Ләкин алар да шөбһәгә төште: җинаять ачыла калса, командирлар да җәзасыз калмаячак. Өстәвенә, РФ Оборона министрлыгына караган хастаханәләргә "дедовщина" корбаннары китерелгән очракта, бу факт турында прокурорларга хәбәр итү мәҗбүри. Кем белә, бәлки, армиядә тәртип урнашыр...

ОМОН әгъзасын үтергән өчен

Үткән атнада Мәскәүдә милиция хезмәткәрләре һәм бандитлар арасында атыш булды. Ниндидер "текә егет" түй үткәргән ашханәгә чит егет кереп бер шешә аракы алырга теле. Егетне кыйнап чыгаралар. Төнлә кыйналган егет дусты белән "үч алырга" килә. Бу юлы да аларны "текә"ләр кыйный, аннары машинага утыртып, М.Җәлил урамындагы чокырга ташлап китәләр. Чокырга ташланганнарның берсе ОМОН әгъзасы була. Егетләрнең берсе кыйналудан үлә, икенчесе авыр хәлдә хастаханәгә озатыла. Икенче көнне милиция хәбәр ала: бандитлар исән калган "шаһит"не юк итәргә килүселәр икән. "Шаһит" йорты янында атыш була. Милиция бандитлар утырган машинаны утка тота, андагы Филиппов һәм Соколов дигән башкисәрләр үтерелә. Тентегәндә алардан тагын ике пистолет һәм махсус пычаклар табыла. Бу – Орехово төркеме бандитлары булып чыга. Хәзер тикшерү бара. ("МК").

Импотентка бәхет елмайды

Русия Сәламәтлек саклау министрлыгы каршындагы кеше әгъзаларын яңадан торгызу үзәге белгечләре җенси орган функцияләрен кайтару буенча моңа кадәр булмаган катлаулы операция ясадылар. Соңгы вакытта узган операциядән соң сугышларда катнашкан бер ветеран моннан соң үзен гаярь ир итеп тоячак. Бу 32 яшьлек ир Үзәккә бик авыр тән җәрәхәте белән керә. Ул Әфганстанда, Карабахта, Югославиядә сугышып йөреп, 69 тән ярасы ала. Туган шәһәре Псковка – гаиләсенә кайткач, үзенең ир һәм ата була алмаячагын аңлап, кара кайгыга төшә. Ул үзбелдеге белән дәвалана башлый, хәле тагын да начарая, җирле табиблар, җенси органны бөтенләй алып ташларга туры килмәгәе, диләр. Үзәктә ветеранның кан юлларына операция ясала, аларны ясалма материалдан эшлиләр. Пациентка эрекция ясатырга сәләтле махсус протез куялар. Белгечләр әйтүенчә, мондый уникаль операцияләр әле дөньяда бер генә илдә дә ясалмаган, хәтта Русиядә дә беренче тапкыр эшләнгән. Дәвалау уңышлы үткән. Киләчәктә ветеран чын егетләрчә яши һәм актив җенси тормыш алып бара алачак. ("МК").

Банданың җитәкчесе – әни кеше

Алтайда йорт басучы бандитлар төркеме өстеннән суд башланды. 40 карактан торган төркем башында хатын-кыз тора. Төркемдә аның өч улы да бар.

Русия бюрократларының иҗаты... 500 ел сакланачак

Мәскәүдә күптән түгел эш кәгазьләренең саклау срогын озынайтуга багышланган конференция булды. XX гасырда басыла торган кәгазьнең гомере нибары 30-40 ел, шуннан соң кәгазь... искерә, тетелә башлый. Чит илдә бу проблема чишелгән.

1989 елда Америкада чыга торган китапларның беренче тиражлары "озын гомерле" кәгазьдә басыла. Бу – мәҗбүри. Дәүләт архивы өчен эш кәгазьләре дә анда 500 ел бозылмый саклана торган кәгазьдә басыла башлады. Мондый кәгазь гадәти кәгазьдән артык аерылып тормый, ләкин аларда кислота юк, шуңа кәгазь бозылмый.

Конференциядә дәүләт, парламент, президент аппараты һ.б. эш кәгазьләре, җитди фәнни хезмәтләрнең беренче тиражларын озын гомерле кәгазьдә бастырырга дигән карар кабул ителде.

Яман шештән яңа дару

Русия онкологлары, моңа кадәр дәвалауга бирешмәгән плевра яман шешеннән дару уйлап таптылар. Күптән көтелгән бу даруны эшләп чыгаруда Русиянең Курнаков исемендәге гомуми һәм органик булмаган химия институты галимнәре ярдәм итте. Алар күптән түгел химия белән дәвалауда "циклоплатам" исемле яңа чара таптылар. Хәзер бу дару хастаханәләрдә сынау үтә. Ул яман шеш күзәнәкләре үсешен туктатырга сәләтле. Хастаханәдә дәваланган авыруларның икесендә плеврадагы яман шеш бөтенләй беткән. Сидек куыгында яман шеш булган 3 кеше, күкәйлекләрендә шеш булган 6 кеше шулай ук тәмам терелгәннәр. Әлеге бу циклоплатам кечкенә партияләр белән сатуга чыгарыла. Русиянең төрле регионнарындагы хастаханәләрдә кабат-кабат сыналгач, аны күпләп чыгара башлаячаклар. ("ОГ").

Бала ызгыш аркасында һәлак булды

Мәскәүдә Көньяк Бутов урамында бер яшь гаиләдә юк кына нәрсә өчен ызгыш чыга. 19 яшьлек әни 2 ай элек кенә Никита исемле бәбиен бала табу йортыннан алып кайта. Ир белән хатын ызгышкан тавышка бала уянып елый башлый. Ачуы чыккан хатын баласын диванга ташлый. Бала идәнгә килеп төшә. "Ашыгыч ярдәм" машинасы килә, тик бала инде җан тәслим кылган була – баш сөяге һәм мие зарарланудан үлә. Ата белән ана хәзер суд каршына басачак. ("КП").

Суд тикшерүчесе – ришвәтче

Мәскәүнең Төньяк-Көнчыгыш округында элекке суд тикшерүчесен ришвәт алганы өчен, суд 2,5 елга ирегеннән мәхрүм итте. Вадим Павлов дигән бу кешенең ришвәт алуын суд бик тиз раслады.

Егет кайсына була

Мәскәү янындагы бер бистәдә ике бертуган кыз йөргән егетләрен бүлешә алмаганнар, чөнки икесе дә бер үк кешене яратканнар. 20 яшьлек егетне канализация торбасыннан милиция табып ала. Егетне сентябрьдән бирле эзләү барган. Милиция 17 һәм 18 яшьлек ике бертуган кыздан шикләнгән. Әлбәттә, егет тә гаепле. Ул апасына да, сеңелесенә дә "яратам", "үлгәнче бергә булырбыз" дип вәгъдә биргән, икесе янына да йөргән. Кызлар арасында талаш чыккан. Бер кичне алар мәсьәләне ачыклар өчен егетне чакырганнар. Хәлнең асылына төшенгәч, егетнең балта белән башына сугып үтергәннәр дә, одеалга төреп, канализация чокырына ташлаганнар. ("МК").

В.ШИЛОВ рәсеме ("Век").

ТЭ Татар энциклопедиясе битләреннән

АРСЛАНОВ Госман Вәли улы *(1897–1941), график, театр рәссамы, 1922 елдан Казанда, 1920–30 елларда "Азат хатын", 1923–41 елларда "Чаян" журналларында, 1923 елда "Принцесса Турандот" спектакленә декорация эскизлары ясый, 1926 елда Г.Тукай әсәрләренә иллюстрация, плакатлар әзерли..*

АРСЛАНОВ Леонид Францевич *(1935 елда туган), тренер, баскетбол уены судьясы. 1973 елда РСФСРның атказанган тренеры, 1971–78 елларда Казан университетында эшли. 1977 елдан халыкара категорияле судья. Олимпия уеннарында катнаша.*

АРСЛАНОВ Леонид Шәйхелсолтан улы *(1932 елда туган), тел белгече, 1983 елдан филология фәннәре докторы, профессор. Алабуга педагогия институтында укыта, 1986 елдан татар филологиясе кафедрасы мөдире.*

АРСЛАНОВ Мөхәммәтгали Гыйлемгали улы *(1947 елда туган), театр белгече, 1979 елдан Тел, әдәбият, тарих институты фәнни хезмәткәре, 1993 елдан сәнгать фәннәре докторы, 1994 елдан бүлек мөдире. 1986 елда татар театры тарихына багышланган "Хәсәен Уразиков", 1992 елда "Татар режиссерлык сәнгате" монографияләре дөнья күрә.*

АРСЛАНОВ Нури Газиз улы *(1912–1991), күренекле шагыйрь. 1950 елда "Ай Хян белән Ли", 1954 елда "Давыл кызы" поэма-легендалары, 1961 елда "Без кояшка күтәрелдек", 1967 елда "Ак таңнар" дигән шигырьләр китабы дөнья күрә.*

Көнчыгышның классик поэзиясе тәэсирендә 1960 елларны Н.Арсланов иҗатында фәлсәфи лирика зур урын ала. Гарәп-фарсы поэзиясенең классикларын оригиналдан тәрҗемә итә. 1982 елда Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була. 1987 елда "Сөмбеләрем", 1992 елда "Сайланма әсәрләр"е басыла.

АРСЛАНОВ Рифкат Мөхәммәт улы *(1946 елда туган), театр рәссамы, нәкышче, 1989 елдан БАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе. Башкорт опера һәм балет театры баш рәссамы. Портретлар, табигать күренешләре, театр декорацияләре эскизлары ясый. Уфада яши.*

АРСЛАНОВЛАР, *Казан сәүдәгәрләре, эшмәкәрләр.*
1. Арсланов Гобәйдулла *(туган-үлгән еллары билгесез, сәүдәгәрләр нәселе башы, шәм заводы хуҗасы.*
2. Арсланов Исхак Габделмәҗит улы *(1852–1901), "И.Арсланов ширкәте" хуҗасы. Арслановлар 1909 елда сәүдә йорты оештыралар. Әхмәтҗан Арсланов Казан губернасының Кече Киратман авылында мәчет төзетә (1910).*

Дүшәмбе
19 ГЫЙНВАР
"ТАТАРСТАН"
7.00-8.00 "Чулпан" информацион программасы.
17.35 Мультфильмнар.
17.55 Балалар өчен: "Тамчы".
18.10 "Эшмәкәрлек телевидениесе".
18.45, 20.45 "Җиһан". Хәбәрләр.
19.00 "Замандаш" циклыннан. "Хөрмәт нигезе хезмәт". Б.Гафуров.
19.45 "Яңалыклар".
20.00 В.Муравьев. "Дуслар һәм җырлар".
20.40 "Әлли-бәлли-бәү".
21.00 "ВЕЧЕР НАКАНУНЕ ИВАНА КУПАЛЫ". (Тәнәфестә – 21.45 – "Яңалыклар").
22.25 "Һәркем өчен хоккей".
22.55 Ралли "Париж-Гранада-Дакар-98".

"ЭФИР"
6.00, 10.25, 11.30, 13.50, 2.35 "Музыкага чикләр юк".
6.15 "Динле кешенең тантаналы тавышы".
6.45, 5.15 "Республика". Информацион-аналитик программа.
8.45 "ПРИНЦЕССА-НЕВЕСТА".
10.40 "ВАВИЛОН-5".
11.45, 14.45 Даруханә.
12.00, 15.00 "ТСН-6".
12.10 "КОШКА НА РАСКАЛЕННОЙ КРЫШЕ".
13.20 "Тамаша залы".
14.05 Яратсаң – кара.
14.30 Мультфильм.
15.10 "МАСКАРАД".
17.05, 19.30, 22.00, 3.20 "Шәһәр". Информацион программа.
17.20 И.Демидовның "Музыка кузәтүе".
18.20 "ВАВИЛОН-5".
19.10 Мультфильм.
20.00 "ДЖОННИ МНЕМОНИК".
21.40 Мультфильм.
22.30 Юл патруле.
22.50 "ПРОВАЛ ВО ВРЕМЕНИ".
0.35 Атна спорты.
1.05 ОСП студиясе.
1.45 Бенни Хилл шоуы.
2.05 Атна һәлакәтләре.
3.00 Мультфильмнар.
3.40 Нәфис фильм.

1 НЧЕ КАНАЛ
15.00, 18.00, 23.40 Яңалыклар.
15.20 Мультсериал: "Насекомусы".
15.45 "Марафон-15".
16.05 "Йолдызлар сәгате".
16.40 "ПОХИЩЕННЫЙ".
17.10 "...16га кадәргеләр һәм өлкәнрәкләр өчен".
17.30 "Дөнья тирәли".
18.20 "РОКОВОЕ НАСЛЕДСТВО".
19.05 "Җавап тотар чак".
19.30 Телеуен: "Бу көйне беләсеңме?"
20.45 "Тыныч йокы, нәниләр".
21.00 "Вакыт".
21.40 "ИВАН ГРОЗНЫЙ". 1 нче серия.
23.55 "ИВАН ГРОЗНЫЙ". 2 нче серия.

"РУСИЯ"
16.05 Мультфильм.
16.30 "МАЛЕНЬКИЙ БРОДЯГА".
17.00, 20.00, 23.30 Хәбәрләр.
17.30 Кроссворд.
18.05 "Бер вакыйга тарихы".
18.20 Баскетбол. Йолдызлар матчы.
20.30 "Нечкәлекләр".
20.45 "САНТА-БАРБАРА".
21.50 Довгань-шоу. "Серле лабиринт".
22.20 "ГРАФИНЯ ДЕ МОНСОРО".
23.55 Милли мәнфәгать.
0.25 Кизү бүлеге.
0.40 Авто-шоу.

"КУЛЬТУРА"
8.00, 0.20 Музыкаль экспромт.
8.15, 14.00, 0.00 Мәдәният яңалыклары.
8.35 "Яшәү рәвеше".
9.05 "Питербургтан музыка". И.Богачева җырлый.
9.45 Китап уязинәсе.
10.00, 12.00, 16.00, 18.00 Яңалыклар.
10.05 Спектакль: "Жизнь Клима Самгина".
11.45 А.Кузнецов аккорды.
12.05 Атаклы кешеләр портретлы.
12.35 "УБИЙСТВО НА УЛИЦЕ ЛУРСИН".
14.20 "Дөнья шәһәрләре мәдәнияте".
14.35 Рәссам Илья Глазунов.
15.15 Мандельштам архивы серләре.
15.30 Авиация дөньясы.
16.05 "ЧЕЛЛЕНДЖЕРС".
16.30 "Вакыт буенча сәяхәт".
17.25 "Лукоморье".
17.45 Кибермәдәният.
23.15 "Бер рәссам театры".
23.40 Төнге кунак.

"НТВ"
8.00, 10.00 Бүген иртән.
9.05 "ПРИВИДЕНИЯ". 1 нче серия. "Я БУДУ ЗА ТОБОЙ СЛЕДИТЬ".
10.10 Кичә "Йомгаклар"да.
11.10 Йомгаклар. Спорт.
11.40 В.Шендерович белән "Җәмгысе".
12.00, 14.00, 16.00 Бүген көндез.
12.20 "Иске телевизор".
14.20 "ПОЩЕЧИНА".
16.20 "Сезам урамы".
16.50 "ЛЮБОВЬ И ТАЙНЫ САНСЕТ БИЧ".
17.40 Документаль сериал: "Дом мастера". 1 нче серия.
18.10 "Файда өчен".
18.20 Криминал.
18.35 Футбол клубы.
19.00, 22.00 Бүген кич.
19.40 "Көн каһарманы".
20.00 Хоккей. НХЛ йолдызлары матчы. "Аурупа" – "Төньяк Америка".
22.50 "ШЕРИФ ИЗ ПРЕИСПОДНЕЙ".
23.40 "Көн яңалыклары".
0.15 "Бүген төн уртасында".
0.40 "Синемания".

Сишәмбе
20 ГЫЙНВАР
"ТАТАРСТАН"
7.00-8.00 "Чулпан". Информацион программа.
17.35 Мультфильмнар.
17.50 "Гөлләр бәйләме". "Айгөл" ансамбле.
18.45, 20.45 "Җиһан". Хәбәрләр.
19.20 "Здравствуй, Феникс".
19.45, 21.45 "Яңалыклар".
20.00 "Карт-бланш".
20.30 "Әлли-бәлли-бәү".
21.00 "Без барыбыз да адәм балалары". Татарстан Президенты М.Шәймиев турында документаль фильм.
22.00 "Туган ягым моңнары". Концерт.
22.55 Ралли "Париж-Гранада-Дакар-98".

"ЭФИР"
6.00, 10.25, 11.30, 14.25, 2.30 "Музыкага чикләр юк".
6.15 "Динле кешенең тантаналы тавышы".
6.45, 17.00, 19.30, 22.10, 3.00 "Шәһәр". Информацион программа.
7.10 "Уян һәм җырла".
8.45 "ДЖОННИ МНЕМОНИК".
10.40 "ВАВИЛОН-5".
11.45, 14.45 Даруханә.
12.00, 15.00 "ТСН-6".
